PRESSA.RU

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН



2018 МАЙ № 5

СӨЮМБИКӘ

ISSN 0869-1398

ФӘРИТ БИКЧӘНТӘЕВ
тормыш кагыйдәләре

КИЛӘБЕЗ ДӘ КИТЕП ЮГАЛАБЫЗ...
бездән соң ни кала

ЧУЛПАН ЙОСЫПОВА СЫЙЛЫЙ
өмеҗе бәлеше

Гөлнара НАСЫЙБУЛЛОВА:

ЯРТЫ ЮЛДА ТУКТАЛМАСКА ӨЙРӘТТЕЛӘР МИНЕ

PRESSA.RU

Минем өчен син һаман да – 17дә!..

Минем өчен син һаман да – 17 дә!..

Бу фотосурәтләр еракта калган кабатланмас мизгелләргә – Яшьлеккә алып китә... ...Шундый зур галәмдә меңнәр арасыннан бер-береңне эзләп табу – үзе үк могҗиза! Аны күргәч кабынган хисләр – иң саф, иң ихлас, иң садә... Йөрәктәге сагышы да – якты, татлы, моңлы... Беренче очрашу... Аның кебек башка берәү дә юктыр! Дөнья – матур, яшәү шундый рәхәт! Очар өчен канатлар кирәкми дә!.. Ярату, йөрәккә генә сыялмыйча, җанда шигырь булып бөреләнә... Һәм мәңгегә Син – Шагыйрь, Ул Илһамчың булып кала...



Ренат ХАРИС

СИНЕҢ ЯШЬЛЕК СУРӘТЕҢ

Җан өрәсем килә сурәтеңә...
Әйтеп бетерәсе сүзеңне
бераз гына чамаларлык иткән
аскы иреннәрең йөземе.

Алардагы татлы кайнарлыкны
көнләр иде хәтта ачы бал...
Кемгә, нәрсә әйтергә җыенып,
иреннәрең шулай ачылган?

Син ул чакта мине белмәгәнсең...
Мин дә белмәгәнмен син барын...
Ләкин никтер гомер агышында
ялгандылар язмыш юллары.

Син һичшиксез мине чакыргансың,
сине эзләвемне сизенеп.
Инде менә ничә еллар татыйм
аскы иреннәрең йөземен...

Рәсемдә: шагыйрьнең хатыны Лилия ханым. 1960 ел.
Быел алар зөбәрҗәт туйларын билгеләп үтте.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2018

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

5'2018



Фото: Ксения Богданова

Җитәкче-баш мөхәррир
Гөлнара Ильяс кызы САБИРОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Гөлнара Насыйбуллова
Фото: Ксения Богданова

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова
Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Фәнзилә Мостафина
Ландыш Әбүдәрова
Фотокорреспондент
Ксения Богданова
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Равил Газизов

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 28.04.2018 ел
Заказ Е-995
Тираж 5367



PRESSA.RU

9 МАЙ — БӨЕК ҖИҢҮ КӨНЕ

Лена ШАГЫЙРЬҖАН

Җиңү бәйрәме

Үзе бәйрәм, үзе моңсу –
Җиңү көне гел шулай.
Ахры, җиңүләр халыкка
Корбансыз килми бугай.

Җиңү белән гел янәшә
Үкенеч-югалтулар.
Кайнар котлаулар артында
Әрнүле юатулар.

Данлы бөек тантанага
Кушылган күз яшьләре.
Уйландыра ул картларны,
Уйланамы яшьләре?..

Җиңү белән җитәкләшеп
Атлый яралы Хәтер.
Бу көннең ничек килгәнен
Сугыш күргәннәр әйтер.

Җиңү көне – бөек көн ул,
Җиңә кайгы-сагышны.
Юк, туктатып булмый аны –
Тормыш дигән агышны!

Әбиләр һәм бабайларны,
Агайлар, җиңгиләрне
Котлаганда телик хәзер
Сугышсыз җиңүләрне –

Киләчәк көннәребездә,
Васыять итик яшьләргә:
Акыл, Хезмәт, Намус белән
Язсын җиңеп яшәргә!..




Фото: Анна Арахамия



PRESSA.RU





БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА





БЕР УНГАН КЫЗ ҖИДЕ УЛГА ТОРА
Гөлнур Сафиуллина

10

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ





6

БАЛАДАН «КОТЫЛУ»
Мәдинә Авзалова



18

«ТЕАТРЛАР КҮП БУЛСЫН»
Фәрит Бикчәнтәев



14

ЗУР СУГЫШ БЕТСӘ ДӘ, ҮТМӘДЕ
Лилия Гәрәева

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ





28

КИЛӘБЕЗ ДӘ КИТЕП ЮГАЛАБЫЗ
Гөлнур Сафиуллина

ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ 



34


БӨЕКЛӘР ҺӘМ БӘЕТЛӘР
Роза Камалетдинова

40



БӘРЕЛЕШ
Кәрим Кара

ЯШӘЕШ 



48

ГАШЫЙК БУЛДЫК! ГОАГА!
Камилә Димөхәммәтова

ШУЛАЙ УК: 

22

БӘХЕТЛЕ ТӘРБИЯЧЕ
Ризидә Гасыймова

24

«ӨЙ ҖЫЕШТЫРАСЫМ БАР...»
Гөлнур Хәсәншина

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 

61



ГӨЛНАЗ СӘФӘРОВА КИҢӘШЛӘРЕ

КИЛӘСЕ САННАРЫБЫЗДА: 

ҖӘҮҺӘР. ТӨРЕКЛӘР АНЫ ШУЛАЙ АТАГАН. МИЛЛӘТТӘШ.

ӘНИСЕЗ ДӨНЬЯ ЯТИМ. КҮҢЕЛЕҢӘ ҖЫЙМА.

«АХИРӘТЛӘР». НУРАНИЯ ТӨХБӘТУЛЛИНА. ХИКӘЯ.

ЭЛЬМИРА КӘЛИМУЛЛИНАДАН МАСТЕР-КЛАСС



PRESSA.RU



БАЛАДАН «КОТЫЛУ»

АНАНЫҢ БАЛАГА КАРАТА ХИСЕ БАРЫ БЕР ГЕНӘ ТӨРЛЕ: УЛ АНЫ ЯРАТА, ҮЛЕП ЯРАТА, ҮТЕРГӘНЧЕ ТҮГЕЛ...



Мәдинә
АВЗАЛОВА

Сүземне нидән башларга да белмим. Ни дип әйтергә мондый вәхшилеккә? Мәче дә баласын ташламый, дибез. Көндәлек әйтелә торган сүзләр бит бу. Кочакка керергә дә өлгермәгән сабыйларын хастаханәләрдә, урамнарда, балалар йортларының ишек төпләрендә калдырырга остарып киткән әниләр, нәниләрен үтереп, чүплеккә ташлаучылар янында, гафу итәсез, фәрештә булып күренә хәзер.

Юныйсә ел башында гына Россия Президенты, бала табучы әниләрне кайгыртып, илнең демографиясе турында уйлап, махсус программа да тәкъдим иткән иде. Ул хәзер тулы көчендә гамәлдә. Күп балалы әниләр өчен бурычласы түгел, дәүләт үстерешә, дип куанган көннәрнең берсендә менә шундый хәбәр. Бер селтәнүдә үзенең тормышны да, балаларның язмышын да сызып ташлау өчен рәхимсез бер адым җитә икән. Россия Федерациясе Җинаятьләр кодексының 106 нчы маддәсендә дә (ананың яңа туган баласын үтерүе) шулай әйтелгән. Димәк, андый хәлләр булгалап тора. Димәк, җан әрнеткеч андый закон тиктомалдан кабул ителмәгән. Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Тикшерү Комитетының Татарстан буенча Тикшерү идарәсе матбугат үзәкләреннән алынган мәгълүматларга караганда, бүгенге вазгыять безнең файдага эшләми. Чөнки җинаятьчә әниләр (болай дип әйтергә тел әйләнми) бөтенесе бер сүздән бу хәлгә барып җитүнең сәбәпләре итеп, тормыш авырлыгын, акча юклыкны, ир белән мөнәсәбәтләрнең киеренкелеген китерәләр. Гомерлек сабак, гыйбрәт булырдай күңел тетрәткеч мондый вакыйгалар әледән-әле кабатланып тора. Без дә бу хакта беренче мәртәбә генә язмыйбыз инде. Кызганыч, тиешле нәтиҗә генә ясый алмыйбыз. Гөнаһсыз сабый гомеренә бәрабәр ни-нәрсә бар соң бу дөньяда?!

Абортка акчасы булмаган

Чатнама салкын көннәрнең берсендә Чаллы шәһәрендә яшәүче егетләр, урамда сыра эчкәннән соң, шешәләрен ташларга дип чүп савыты янына килгәч, контейнердагы калдыклар арасында полиэтилен пакетка салган яшь бала гәүдәсен күреп алалар. Бу хакта шундук полициягә хәбәр ителәр.

Әни кешене икенче көнне үк табып алалар. Аңа 24 яшь, ике ирдән ике кечкенә баласы бар. Кияүдә түгел. Әтисе белән яши. Беркайда да эшләми. Өченче балага узуын белгәч, әтисенә әйтмичә генә тугыз ай күтәрә. Төшертергә акчасы булмый. Баласын төнлә таба да, «суламый, үлгән» дип, чүпрәккә төреп, ишек төбендәге чүп савытына китереп куя. Ә бәлкем, табиблар аны коткарып та калган булырлар иде. Ә бәлкем, ул балага чыннан да ярдәм кирәк булгандыр. Пакет шунда тәүлек буе ята. Әтисе дә аны чүп дип уйлый. Икенче көнне генә хатын баласының үле гәүдәсен икенче подъезд төбендәге чүплеккә чыгарып ташлый.

Учетка куймаганнар

Әлмәт районының Колшәрип авылы янындагы чүп эшкәртү контейнерыннан табып алынган бәбинең үле гәүдәсен тикшереп караган суд-медицина экспертизасы хезмәткәрләре: «Бала туганда исән булган», – дигән фикергә килә. Мәгълүм маддә буенча җинаять эше кузгатыла. Баласын үтерүче 29 яшьлек хатын гаебен тулысынча таный. Тугач та, баланы балконга чыгарып куюы, ике-өч көннән соң контейнерда калдырып китүе турында сөйли. Йөкле хатын авылның фельдшерлык пунктына мөрәҗәгать итүе, аннан юллама алып, Әлмәткә хатын-кызлар консультациясенә баруы, анда аны, медицина полисы булмау сәбәпле, учетка куюдан баш тартулары хакында сөйли. «Аннан соң мин инде беркая да мөрәҗәгать итмәдем», – ди ул. Ни өчен табиблар йөкле хатынны кире борганнар?! Бу сорауга җавап әлегәчә ачык кала. Ә бит фаҗигане булдырмый калдырырга да мөмкин иде.

Чүплектән табып алынган бәбиләрнең бик сирәге генә исән кала. Күбесен үтереп ташлыйлар.

Дүрт елга хөкем ителгән

Быелның февралендә яңа туган баласын, йөзе белән мендәргә каплап, томалап үтергәне өчен 29 яшьлек хатынга хөкем карары чыгарылды. Ул дүрт елга ирегеннән мәхрүм ителде. Хәзер ул колониядә. Һаман да шул бер хәл: пакетка салынган бала... чүп савыты... «Гаебен таныды, үкенә...» – дип әйтә тикшерүчеләр аның турында. Ләкин эш узган, дөньядагы кичереп булмый торган иң зур, иң рәхимсез җинаять кылынган. Үкенүдән хәзер ни файда?

«Чүп»не улыннан чыгарткан

Инде менә тагын бер җан әрнеткеч хәл. Әле күптән түгел генә Аксубай төбәгендә яшәүче 36 яшьлек өч бала анасы бала таба. Баласының сулавын күреп, шундук пакетка төрә һәм чиләккә салып, өйалдына чыгарып куя. Нәтиҗәдә, бала туңып үлә. Ә дүрт көннән соң (шул гомер ул күз алдында, чиләктә ята!), олы улына төргәкне «мусорка»га чыгарып ыргытырга куша. Белсә икән малай шул чагында чүплеккә кемне ташлаганын?! Эш моның белән генә бетми. Хатын чирләп китә һәм ярдәм сорап хастаханәгә мөрәҗәгать итә. Шунда гына аның кыңгыр эше беленә. Бу хатынга карата җинаять эше кузгатыла.

Кемдер бала булмаудан интегә, ә кемдер әнә шулай... Имеш, кирәк булмаган ул бала аңа, артык булган. Йөккә узган хатын-кыз һәр адымын уйлап, кайда һәм кемгә мөрәҗәгать итәргә кирәклеген белеп яши. Баланы, кирәк дип тапмый икән, төшертә ала. Моның өчен хатын-кызлар консультациясенә барып күренергә генә кирәк. Ә нигә төшертү өчен акча кирәк? Бүген медицина ярдәме шул дәрәҗәгә җитте ки, һәркайда үзеңнән алда акча йөри. Шуңа күрә адым саен, атлаган саен без Ходайдан исәнлек-саулык сорыйбыз. Инде әнә аборт та проблемага әйләнә бара. Ә проблеманың нәтиҗәсе – күз алдында.

Әлмәттәге вакыйгаларга әйләнеп кайтыйк әле. Хатын фельдшерлык пунктына барган бит. Хатын-кызлар консультациясендә дә булган. Ә аңа нәрсә дип җавап

Фото: www.pixabay

PRESSA.RU

биргәннәр?! «Медицина полисың, иминлек таныкнамәң юк. Сине исәпкә куя алмыйбыз», – дигәннәр. Ул кайтып киткән дә, башка инде табибларга күренмәгән. Исәпкә куйган булсалар шунда… Игътибарсызлык, бигрәк тә йөкле хатын-кызның мәшәкать-борчуларына җитди карамау җинаять кылган әниләрне генә түгел, биредә катнашы булган күпләрне намус суды алдына бастыра.

Нинди генә авыр хәлдә калганда да бизмәндә бала гомере торырга тиеш түгел.

Берничә еллар элек «Ана даны» медаленә лаек булган күп балалы ана турында язганым истә. Берберсен яратышып яшәгән матур, җитеш гаиләдә дә шундый хәл булыр икән. Хатын йөкле булуын иреннән ничек яшергән? Мөмкин эшме бу? Бик гаҗәпләнгән идем шул чагында. Аксубайда булган вакыйга да бермә-бер шуны кабатлый. Ничек инде ир кеше хатынының авырга узганын белми?! Бәлкем, иргә шулай уңайлыдыр? Бәлкем, ул махсус күрмәмешкә салышадыр? Кайчак башка шундый уйлар да кергәли. Әллә инде ирләр шулкадәр ваемсыз, битарафка әйләндеме? Хәер, ире белгән-сизенгән хәлдә дә ул ике арада сер булып калачак. Моңа минем иманым камил. Чөнки тормышның бөтен авырлыгын җилкәбездә күтәрергә күнеккән без – хатыннар, хәтта закон каршына басып, хөкем эскәмиясенә утырган очракта да ирләрне сатмыйбыз. Шулай бит?! Ләкин биредә шунысы бар: хатынның ни өчен консультациядә исәпкә куелмавы турында сораштыра башлагач, Аксубай районы үзәк хастаханәсенең баш табиб урынбасары: «Безнең табиблар хәтта аның өенә бардылар. Үзе теләмәде, рөхсәт бирмәде», – дип куйды. Әйе, пациент теләми икән, берни эшли алмыйсың. Россия Федерациясенең 323 нче законындагы 19 нчы маддәсендә бәян ителгәнчә, һәркемнең медицина ярдәменнән баш тарту хокукы бар. Ә бит, бер уйласаң, исәпкә куелмый икән, баланың барлыгын-юклыгын берәү дә белми. Медицина хезмәткәрләре, дип әйтүем. Бу вакыйгага карата без конкрет берни дә әйтә алмыйбыз. Тикшерү нәтиҗәләре ни күрсәтер?

«Өмет бишеге»

Ташландык балалар өчен уйлап тапкан бәби-боксларны кайда ничек – төрлечә атыйлар. Бүген безнең илнең дистәдән артык регионында эшли алар. Краснодар өлкәсеннән юл алган бу башлангыч Татарстанга да килеп җитте. Моннан өч ел чамасы элек Чаллы шәһәрендә ачылган «тормыш тәрәзәләре» – бәби-бокслар, Кама балалар медицина үзәгенең матбугат җитәкчесе Диләрә Эстринаның әйтүенә караганда, үлемгә дучар ителгән бала өчен икенче тормыш бүләк итә.

…Төн уртасында бәби-бокстан одеялга төрелгән ике айлык кызчыкны алалар. Янында сумка, ә сумкада бала өчен кирәкле әйберләр. Һәм записка… баласын калдыручы әни үзенең ни эшләгәнен белгән. Әйе, бик начар эшли ул. Әмма баласына кирәклетиешле тәрбия бирә алмаячагын да бик яхшы аңлый. Мохтаҗлык аны соңгы адымга барырга мәҗбүр иткән, имеш.

– Бәби-бокс – баладан аноним баш тарту өчен эшләнгән махсус җайланма, – ди Диләрә Эстрина. – Баланы бокска куюга, ишек ябыла. Шундук сигнал килә башлый. Аннан инде баланы урам ягыннан беркем дә ала алмый. Хастаханәдәге хезмәткәрләр бокста бала барлыгын шул рәвешле белә. Бәби-бокс янында видеокамера да, сакчылар да юк.

Дөрес, баласын бәби-бокста калдырган әни, бәбиенә физик зыян килмәгән очракта, җинаять җаваплылыгына тартылмый. Балага «ташландык» статусы бирелә, һәм ул алга таба уллыкка-кызлыкка алынырга тиешлеләр исемлегенә кертелә.

Исегезгә төшерәбез, узган елның сентябрь аенда сенатор Елена Мизулина мондый «өмет бишекләрен» тыю турындагы закон проектын хуплавы турында белдергән иде. «Тормыш кыенлыкларын сылтау итеп, баладан баш тартуны туктатырга, тыярга кирәк», – дигән иде ул. Бер караганда, бала үзенең әти-әнисенең кем икәнлеген белергә тиеш. Ә болай аның хокуклары бозыла. Икенче караганда, бәби-бокста бер генә баланың тормышы саклап калынса да, ул инде үзен аклый. Чүплеккә ташланган балаларга әти-әниләренең кем булуы кирәкми дә кирәкми. Чынында, мондый җайланмалар баладан котылырга карар кылган хатыннарга кирәк. Ә «котылу» дигән яман сүзнең ни икәнен беләсез инде: йә ул бәбиен, мәче баласыдай, урамда ыргытып калдыра, йә чүплеккә ташлый. Үтереп котыламы, бәби-бокска куеп котыламы… Монысы аның өчен әһәмиятле түгел. Тик котылсын гына…

Кеше тормышы – бәһасез. Ул безнең Конституциядә дә шулай дип әйтелгән. Шунысы да бар: баладан мондый җиңел юл белән «котылу» – ул яшь әниләрне бөтенләй иркенлеккә чыгармасмы? Болай да юк дәрәҗәсендәге җаваплылыктан бөтенләйгә азат итмәсме? Әйе, таяк ике башлы. Иң куркынычы: баланы бәбибокскамы, йә булмаса башка бер җайланмагамы калдырып китү гадәти күренешкә әверелмәсме?! Аз гына авырлыктан да сыгылып төшәргә әзер торган әниләргә «яшел урам» ачып, тагын да аздырмабызмы үзләрен? Сораулар күп…

Баладан котылуга акчасызлык та, юклык та, мохтаҗлык та сәбәп була алмый. Хатын-кызның котылгысыз күренгән хәлдән чыгу өчен соңгы адымны («Нинди гөнаһ сәбәпле үтерелдең?» Коръәннең «Тәквир» сүрәсе, 29 нчы аять) сайлавы үзе үк бик күп нәрсә турында сөйли. Аклап та, яклап та әйтүем түгел. Һич түгел. Кабергә кадәр озата барган иң зур гөнаһларның берсе шулдыр. Кызганыч, «баладан котылу» дигәнебез бүген әнә шундый куркыныч мәгънә ала бара.

ГАИЛӘ АКЧАСЫ КЕМ КУЛЫНДА БУЛЫРГА ТИЕШ?



Марат КӘБИРОВ

Бу сорауны еш бирәләр инде. Ара-тирә бәхәсләшеп тә китәләр. Тик бер нәтиҗәгә килүче генә табылмый. Чөнки гаилә акчасы дигән нәрсә бик абстракт төшенчә. Нәрсә ул гаилә акчасы, ул күпме булырга тиеш, кайлардан җыелырга тиеш? Моны беркем дә төгәл белми бугай. Әйтик, менә ир кеше дуслары белән очрашып, матур гына пирәшләп, аларны да сыйлап кайта. Хатыны пыр туза: «Гаилә акчасына эчеп йөри, юньсез!» – ди. Тагын әллә нинди «матур» сүзләр өсти. Бер карасаң, хатыны дөрес әйтә кебек инде. Салып кайткан иренә нәрсә әйтсә дә хатын хаклы булып кала. Ә ир үзенең хезмәт хакын эчеп кайтмаган. Премиясен дә түгел. Тапкан ул бу акчаны. Юлдан тапканмы анда, лотереяга откanмы – мөһим түгел. Вәт, уйлаган инде шуннан, әйдә, бер рәхәтен күреп калыйм әле. Югыйсә бөтен нәрсәне гаиләгә ташыдым, артык рәхмәт тә әйтүче булмады, дип... Бер карасаң, хатыны хаклы инде. Икенче карасаң, ире хаклы.

НӘРСӘ УЛ ГАИЛӘ АКЧАСЫ?

Гаилә бюджеты дигән термин бар. Без барыбыз да аптырыйбыз бит инде, кайда югала бу акча шулкадәр зур тизлек белән, дип. Менә шулай аптырап туйгач, акыллы кешеләр моны тикшерергә булганнар, һәм акчаның кайда югалуын тиенен кадәр чутлап, яшерен дәфтәрләренә язып барганнар. «Көн саен бер икмәк – фәлән сум, сөт – фәлән сум, сагыз – фәлән тиен, теш чоку чырасы – фәлән тиен...» – шул рәвешләрәк. Нәрсәнең чынлап та кирәк, ә нәрсәнең артык булуы ачыкланган. Әйтик, ирең тәмәке тарта икән, көн саен йөз тәңкәдән генә дә бу өч мең тирәсенә төшә. Үзе бер кредит түләгән кебек. Хатыны моны белгәч: «Урра! Ир кисәгенең башын катырырга тагын бер сәбәп табылды!» – дип, шатлыгыннан күккә сикерә язган. Тик аягындагы кичә генә кибеттән алып кайткан биек үкчәле танкеткасын җәлләп, сикермичә калган. Үкчәсен сындырсаң – фәлән мең ич! Ирең ел буе тәмәке тарткан кебек... Әле аның иннек-кершәннәрен, креммазьларын, бергә эшләгән хатынның ахирәте алдап саткан «затлы хушбуй»ларын да өстәсәң... Карале, бу акчаның әллә күпмесе бөтенләй кирәкмәгән нәрсәләргә китә икән ич!

Менә шул рәвешле, «гаилә бюджеты» дигән термин килеп чыккан. Барлы-юклы акчаның аерым бер вакыт эчендә каян килеп, кая китүен өйрәнүче фән.

Шушы фән буенча, чыгымнарны дүрт төргә бүләләр икән: мәҗбүри чыгымнар (квартплата, кредит, утка-газга түләү һ. б.), балалар өчен (аларга кием-салым, уку әсбаплары, төрле чараларга йөрү һ. б.), гаилә чыгымнары (фатир ремонтлау, мебель алу, азык-төлек, кием-салым һ. б.), шәхси чыгымнар (һәр гаилә әгъзасының үз кирәге өчен тотыла торган акча). Кайберәүләр акчаның бер өлешен көтелмәгән очраклар килеп чыкса дип тә җыеп бара. Ә керемнәр, гадәттә, ике генә төргә бүленә: ирнең хезмәт хакы һәм хатынныкы. Гаилә акчасы дигән нәрсә – шушы чыгымнарны алдан чамалап, алынган яки алыначак керемнәрдән бүлеп куелган акча булып чыга.

АКЧА ТОТУНЫҢ ӨЧ ЫСУЛЫ

Гаилә бюджетын алып баруның, нигездә, өч ысулы бар. Әлбәттә, аларның тагын әллә ничәшәр вариантын табарга мөмкин. Ләкин нигезе – шушы өч юл.

Демократик (аерым) ысул. Монда һәркем үзе тапкан акчаны үзе теләгәнчә тота. Әгәр ниндидер эре әйбер сатып алырга кирәк икән – кушылалар, яки бу вакытта кемнең акчасы бар – шул ала. Ә икенче юлы икенчесе алырга мөмкин.

Бу ысул иң әйбәте кебек. Ике арада килешүчәнлек, үзара хөрмәт булган чакта, әлбәттә. Әгәр хөрмәт юк икән, ул бер гаилә әгъзасын саву сыманрак төс алырга да мөмкин. Әйтик, теге юлы да синең акчаңа, бу юлы да... Кием-салым да, азык-төлек тә синнән...

Бергәләшеп. Бу очракта һәр гаилә әгъзасы, кесәсен әйләндереп, үз хезмәт хакын чыгарып сала. Уртак касса рәвешендәге бер нәрсә хасил була. Барлык нәрсәне дә үзара килешеп сатып алалар. Беркем дә уртак кассага рөхсәтсез якын килми.

Монысы – ир дә, хатын да бер чама акча алганда отышлы. Әгәр берәрсе күбрәк ала икән, кайчан да бер тавыш чыгачагы көн кебек. Мин шулкадәр акча алам, мин яшәтәм сине, мин ашатам... Әлбәттә, үзара татулык булмаса инде...

Кушылган. Бу очракта гаиләнең айлык чыгымы икегә бүленә, һәм һәр гаилә әгъзасы үз өлешен кертә. Уртак чыгымнардан артып калган акчасын һәркем үзе теләгәнчә тота.

Идеаль вариант: гаилә өчен дә өлешен кертә, үз хасиятләренә дә кала. Ләкин теләге булган кеше бу очракта да тавыш чыгарырга мөмкин. Мәсәлән, хезмәт хакы тигез булмаган очракта: «Ә мин өйдә күпме эшне эшлим. Синең кебек әзергә-бәзер генә булсам, мин дә шулкадәр хезмәт хакы алган булыр идем. Өстәвенә, бөтен акчамны гаилә өчен чыгарып салам...»

Күренгәнчә, һәр очракның үз өстенлеге, үз кимчелеге бар. Нинди генә ысулны сайласаң да, үзара хөрмәт, гаделлек юк икән – гауга чыкмый калмаячак. Һәм эш монда хәтта акчаның күләмендә дә түгел. Акча беркемгә дә җитми, чөнки керем арткан саен, ихтыяҗлар да, чыгымнар да күбәя. Әйтик, син гади генә хезмәт хакы алып эшлисең икән, гади генә киемгә дә канәгать буласың. Ә инде миллиардерлар арасында кайнашасың икән, кигән киемең дә затлы һәм кыйммәтле булырга тиеш. Шунсыз – эшең бармый. Акчаның кем кулында булуы артык мөһим дә түгел. Иң мөһиме – булсын ул. Һәм гаиләгә хезмәт итсен.

Фото: ТИ

PRESSA.RU

БЕР УҢГАН КЫЗ ҖИДЕ УЛГА ТОРА

«Сәхнәгә чыгасың була – матур киенеп бар», дигәч, киенгән идем инде. Бизәнгән дә идем... «Сез фермермы? Чынлап та шулаймы?» – ди министр. Аннан залга таба борылып, тагын шул соравын кабатлады: «Сез чынлап та Югары Осланнар фермерны алып килгән дип уйлыйсызмы?» Халык көлешә башлады... Барысы да диярлек ир-атлар утыра бит. Арада хатын-кызлар сирәк, минем кебек яшьләр юк диярлек иде...



Министрлык уздырган республика бәйгесендә, 2016 ел нәтиҗәләре буенча, «Иң яхшы шәхси ярдәмче хуҗалык» номинациясендә җиңү яулый Гөлнара Насыйбуллова. Дипломны һәм бүләкне аңа Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов үзе тапшыра. Министрның, гаҗәпләнеп, сокланып шулай дип әйтүе ул көнне залда бер дулкын кузгатып җибәрә – Югары Ослан районы авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы Рәшит Гобәйдуллин янына килеп сорау яудыручылар байтак була: «Бу кызыгыз кәгазьдә генә фермер дип саналамы, әллә...», «Ә ул чынлап та терлекләр асрыймы?», «Ничә баш сыер сава ул?»... Кемдер хәтта килеп кызның үзенә үк шул сорауларны бирә.

Гөлнара бу хакта сөйли дә, без икәү рәхәтләнеп көлешәбез.

– Кем ышансын инде синең көн саен ун сыер сауганыңа? – дим. – Тырнакларың ул чакта да шулай буялган булгандыр...

– Маникюрсыз йөргәнем юк минем, – дип елмая ул. – Гел кеше арасында бит: әле районга барырга туры килә, әле Казанга. Фермер икәнемне белүгә, барысы да иң элек кулларыма карый... Үзләре сизми дә кала бугай. Сыерларны перчатка киеп савам. Терлекләр арасына яланкул чыкканым юк. Кәрәк-сәнәк кулдан төшми – перчаткасыз эшләсәң, шунда ук сөялләр чыгачак...

...Гөлнараның мең төрле хыялы арасында: «Ишегалды тутырып терлек-туар асрарга телим!» – дигәне булмый, әлбәттә. Кыз баланың күбесе үзен затлы күлмәкләрдән подиумда күрә инде ул – сәхнәдә, тамашачылар алдында... Тормыш кына кырысрак. Ул сине гел көтмәгән, уйламаган сукмаклардан ала да кереп китә.

Тугызынчы сыйныфны тәмамлагач, Гөлнара Казанга, төзелеш техникумына укырга китеп бара. «Ул чакта кая керә алдым – шунда кердем», – ди. Әмма үзеннән штукатур-буяучы чыкмаячагын бик тиз аңлый – I курсны тәмамлауга бухгалтер-икътисадчылар әзерләүче бүлеккә күчә. (Күңеленә ятмаган, үзенә ошамаган нәрсәләр өчен гомер уздыручы түгел ул!) Аны тәмамлауга, Казан дәүләт аграр университетының читтән торып уку бүлегенә имтиханнар тапшыра. Эшкә урнаша.

«Туган авылым» күңел-ачу үзәгендә хуҗалар алышынмаса, эшләр гел бертөрле җайлы-көйле генә барса, Гөлнара бүген дә шунда администратор булып эшләп йөрер идеме икән? Ярты елга якын хезмәт хакы түләмиләр ул чакта. Авылга бер кайтуында Гөлнара әти-әнисенә:

– Булды, җитте, хуҗаларга моннан ары баш иеп йөрмим – үз эшемне башлыйм! – ди.

Беренче сыерын 30 меңгә сатып ала ул. Районның мәшгульлек үзәге аша 58 мең финанс ярдәме алуга ирешә. 2011 ел була бу. Гөлнарага ул вакытта әле 20 яшь тә юк! Шуннан башлана...

Әтисе исән чагында, киңәш сорар, таяныр кешесе булганда хуҗалыкта эшләр ничек барганы турында сөйләшмибез диярлек. Гөлнара үзе дә күбрәк шәһәр белән ике арада йөри әле: Казандагы эшен алып барырга да өлгерә, авылда булышырга да җитешә. Өч ел элек исә язмыш бөтен җаваплылыкны яшь кызның үз җилкәсенә сала.

– Май ахыры иде. Малларны көтүгә үзем алып чыктым ул көнне. Кояштан качып, агач ышыгында утырам. Башка сыерлар яшел сусыл үләннән баш күтәрми ашап йөри, ә Дочка гел минем янда. Бер ята, бер тора – нигәдер тынычсызлана... Ул гел шулай сизенә. «Нәрсә булды соң сиңа?» – дим. Үземнең дә эчем поша. Әтинең йөрәгенә операция буласы көн бит. Берне ясаганнар иде инде, өйгә кайтып озак та үтмәде, хәле авыраеп китте. Тагын пычак астына керергә тиеш менә... Берзаманны карыйм – кырдан миңа таба апа йөгерә. Күлмәктән, туфлидән... Улы бездә укыды аның. Мәктәпкә, соңгы кыңгырау бәйрәменә дип кайткан иде. Шунда ук аңладым... Әтигә нибары 62 яшь иде...

Хөкүмәт ярдәм итә – бик әйбәт. Әмма үзең дә тырышырга тиешсең.

Ул көннәрне авыл урамында кем очраса да, кайгыларын уртаклашуга: «Йортыгыз тулы терлек – бетерерсез инде», – диләр. Ир-атсыз бу кадәр хуҗалыкны алып бара алырлар дип берсе дә күз алдына китерми, билгеле. Сигез сыер, бозаулар...

– Малларны тарату, бетерү уе ялгыш та башыбызга кермәде. Безнең беребез дә башлаган эшне ярты юлда калдыручылар түгел: бу яктан әнигә охшаганбыз. Утырып сөйләштек, киңәшләштек. «Әни, безгә хәсрәт килде дип кенә тормыш бит туктамый, елап утырып булмый – яшәргә кирәк», – дим. Дөрес, әни әле бер ел буе көн саен елады да елады... «Болай булгач, мин инде бөтенләйгә күченеп кайтам», – дидем. Үзегез беләсез, авылда эш юк хәзер. Минем бер генә юлым бар иде – маллар тоту, маллар үстерү белән шөгыльләнүне дәвам итү. Инде моны төп эшемә әйләндерү... Иң төп ярдәмчем – әни. Аннан – Фирдәвес апа. Әмма күмәк эшләр булганда җизниләр дә, бөтен туганнар да булыша безгә.

Бакча-Сарай авылы Иделнең уң як ярында урнашкан. Җәйләрен монда җәннәт, диләр! Шимбә-ял көннәрендә кала халкы, палаткалар куеп, куна-төнә ял итәргә килә икән. Ә авыл... шәһәргә якын салалар язмышын кичерергә мәҗбүр – күпләр кул сузымында гына булган Иннополиска яки Казанга китеп эшли. Матюшинода урнашкан «Дивный берег» балык эшкәртү компаниясе барлык теләүчеләрне эш белән тәэмин итә алмый. Известь чыгару белән шөгыльләнүче «Матюшино карьеры» да элеккеге кебек бар куәтенә эшләми инде. Гөлнараның әти-әнисе Фәһим абый белән Зөлфия апа да 1981 елны Чүпрәле районы Чынлы авылыннан шушы карьерга эшкә килеп урнашкан булган.

Фото: Ксения Богданова

PRESSA.RU

Бакча-Сарай авылында бүген нибары өч хуҗалык сыер асрый. Шуларның берсе – Насыйбулловалар.

– 12 баш савым сыер, 4 үгез, калганнары – бозаулар. Һәммәсе бергә – 22 баш. Тагын 7 баш сарык... Казлар, үрдәкләр... Тавыклар... 7 мәче белән 3 этебезне дә саныйбызмы?

Тагын көлешәбез. Ничек санамыйсың? Терлек абзарлары Идел ярында үскән куе урманга терәлеп тора – төлкеләрнең тавык кетәклегенә кереп зыян салганы булган инде. Тау-тау печән, салам өеме торган җирдә тычкан-күседән мәчеләрсез ничек сакланып бетәсең?

Сөт ризыкларының сыйфаты өчен үзебез җавап бирәбез.

Узган ел Гөлнара мини-ферма төзү өчен бирелә торган программа нигезендә дәүләттән кире кайтарылмый торган 200 мең сум акча алган һәм шуңа терлек абзарлары төзеп куйган. (Дөресрәге, узган елны ул төзелеш аңа 600 мең сумга төшкән.) Төзеп куйган... Әйтергә генә җиңел! Алар кайчандыр «Матюшино карьер»ы биргән йортта яшиләр (Чүпрәледән Матюшинога күчереп салган өйләрен, юл, су юк, мәктәпкә дә ерак дип, сатарга туры килгән.) Бер түбә астында – өч гаилә. Абзарлары – йорт артындагы бакча урынында. Тау битенә урнашкан ул киртләч-киртләч бакчаны бүгенге хәленә китерү – тигезләү өчен аларга, беләсезме, күпме туфрак ташырга туры килгән? 1500 тонна! Иске абзарларны өч хатын-кыз – әнисе, апасы, Гөлнара – үзләре сүтә, нигезен үзләре казый. Бетон алып килгән машина аска, бакча урынына кадәр керә алмый: тау башыннан бетонны ул көнне аска чиләк белән ташыйлар... Кулларың өзелер дәрәҗәгә җиткән авыр эшкә чыдап була ла ул! Урынсыз бәйләнүләргә, нахак сүзгә түзү кыенрак. Күршеләрнең берсе: «Мин сиңа монда терлек асратып, акча эшләтеп ятмыйм!» – дип, Гөлнара өстеннән кая гына шикаять язмый! Тикшерү арты тикшерү китеп тормый. Бернинди дә закон бозулар, кагыйдәләрдән чыгулар тапмыйлар. «Терлекләрне өй янынннан күчерергә кирәк», – дигән карарга шул ыгы-зыгылар вакытында килә бугай. Район җитәкчелеге ярдәме белән тау өстендә – авылдан аз гына читтәрәк 2,5 гектар җир алуга ирешкән. (Гөлнара бигрәк тә районның авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы Рәшит Гобәйдуллинга рәхмәтле: нинди сорау белән барса да ярдәм итә, киңәшен бирә, юлын күрсәтә). Инде крестьян-фермер хуҗалыгы булып теркәлеп, 50 баш сыерга исәпләнгән ферма төзү турында хыяллана. Хөкүмәттән быел грант алырга өметләнә (сүз уңаеннан, Югары Ослан районында соңгы биш елда бу грантны алучылар, аңа дәгъва белдерүчеләр булмаган. Гөлнара Насыйбуллова хуҗалыгында эшләр әйбәт бара, күрсәткечләре яхшы – грант отарга мөмкинлекләре зур, диләр).

– Сыймыйбыз инде без монда... Узган җәй, мәсәлән, 300 баш каз үстердек, үрдәкләр дә 300 иде, бройлер тавыклар бераз гына азрак – 250 баш. Йомырка сала торган тавыкларыбыз 70 иде...

Без Гөлнара белән саннарга-цифрларга күчәбез.

Узган ел терлекләр өчен 15-20 тонна икмәк сатып алганнар. Җәй көне үрдәкләргә, сугым үгезләргә ашату өчен һәр көнне берәр капчык бодай пешергәннәр (бер капчыкка 5 чиләк бодай керә, пешкәч, ул 10 чиләккә әйләнә).

Былтыр көз 6 үгез суеп сатканнар. Иң зур үгезләре 450 килограммлы булган (аның янына сарайга Гөлнараның үзеннән башка беркем керә алмаган. «Ят кешене аяк тавышыннан таный, шунда ук җирне казый башлый иде», – ди. Чалганда, бу үгезне җиргә 6 кеше еккан).


Кышлыкка һәрберсен 1100 сумнан 300 тюк печән сатып алганнар. (Узган ел 200 не генә алган булганнар – җитмәгән. Быелгысы җәй ашатырга да калачак әле. Печән белән район да булыша, узган ел: «Кырдан күпме алып чыга аласың – ал», – дип, бер көн биргәннәр.)

Җәен көтүче ялласаң, бер көнгә сыер башына 100 сум түлисең. Гөлнараның көтүгә 10 сыеры чыга.

Бүген ул 8 сыер сава: таналары көнгә – 15 әр, сыерлар 22 әр литр сөт бирә. Ә җәен сөтле сыерлардан 30-35 әр литр сөт савып ала. («Мин үзем сөт яратучы түгел, – ди Гөлнара. – Яңа сауганына да исем китми.







Кайнатканны гына эчкәлим. Каймагын исә ашыйм».) Сөт ризыкларын апасы Фирдәвес белән алар шимбә көнне Казанда, Адоратский урамында урнашкан базарда – авыл хуҗалыгы ярминкәсендә саталар. Инде дүрт ел дәвамында атна кич көнне почмак якта эш кайный башлый: чиләк тә тула, иләк тә. (Җомга кичкә барысы да әзер булырга тиеш: төнге икедә юлга кузгалалар – иртәрәк бармасаң, урын калмый.) Атна саен 120 килограмм эремчек әзерлиләр, 5 килограмм май, 30-35 килограмм корт (гөбәдиягә диган 20-25 килограммы аерым әзерләнә: анысын сөзгәннән соң, ике тәүлек өстенә авыр әйбер бастырып калдыралар. Суы тәмам сыгылып беткәч, иттарткыч аша чыгаралар. «Киптергән корт гөбәдия өчен каты була», – ди Зөлфия апа.) Тагын – каймак, катык, сөзмә, кайнаткан сөт... Җаен сөтне, әлбәттә, күбрәк «дачник»лар ала. Дөрес, анысын да һәркемнең бакчасына үзең илтеп бирәсе («Камал театры артистлары аллеясына һаман барып җитә алмыйм, – ди Гөлнара. – Аларга җиткәнче, сөтемне алып бетерәләр».)

– Һәр сыерның – үз холкы. Кешеләрнеке кебек, – ди Гөлнара. – Кәефең юклыкны, ачулныганыңны да беләләр. Үпкәлиләр! Андый чакта сиңа борылып та карамыйлар, карасалар да күрсәтмиләр! Дочка белән Люська – иң беренче алган сыерларыбыз. Алар берберсеннән башка тора алмый: берсен өйдә калдырып, икенчесен көтүгә җибәрсәң, тегесе барыбер бераздан качып кайта. Кайта да янына кереп ята. Алардан туган бозаулар да шулай бер-берсен эзли. Совхоздан бер сыер сатып алган идек. Аны әллә гел кыйнап торганнар – сыйпарга үрелсәң дә курка иде, ике ел дигәндә генә тынычланды. Көтүгә мин барсам гына чыга ул, мин булмасам, артымнан ук капка төбенә кайтып баса. Җиләк җыярга, урманда йөрергә яратам – шул сыерым гел артымнан ияреп йөри.

Авырып китсәләр, малларның күзләре шундый моңсуга әйләнә... Кулны бик сизәләр, әни савамы, минме икәнен бик тиз аералар. Беребез ул сыерны озаграк сауса, ияләшәләр, икенчебезгә сөтләрен төшертмиләр.

Сыер сауганда музыка куеп җибәрәм – шунда ук тынычланалар, тибенмиләр дә. Күп вакыт алар янында үзем дә җырлап йөрим...

Гөлнараның телендә – гел тау башында төзеләсе ферма. Анда, әлбәттә, иркен булачак! Малларның баш санын курыкмыйча арттырырга мөмкин. Сыерларны инде кул белән саумас (әлегә ул саву аппараты алмаган, «Чиләккә савам да, күтәрәм дә кереп китәм, миңа болай җайлырак», – ди)... Шунда ук сөтне эшкәртергә мини-завод, бәлки әле колбаса цехы да булыр. Бу фермада, беләсезме, тагын кемнәр яшәячәк? Ат һәм дөя! «Фермада атсыз булмый», – ди Гөлнара. «Ә дөя нәрсәгә?» – дим, аптырабрак. «Бездә бит балалар күп, – ди ул. – Бер апамда – өчәү, икенчесендә – дүртәү. Алар барысы да хайваннар ярата. Песиләрне кулдан да төшермиләр. Җидесе дә җәй буе бездә – Бакча-Сарайда алар. Көтүгә дә чыгалар, печән дә өяләр, ишегалды да себерәләр... Дөяне алар өчен аласы килә».

Кулларны сакларга тырышам – үләннәрдән ванна ясыйм.

– Барысын да ташлап чыгып китәсе килгән чаклар булмыймы соң?

Болай соравыма аның исе дә китми – беренче генә ишетми бугай.

– Мин бит өйдә, терлекләр арасында гына бикләнеп яшәмим. Уңайлы вакыт көтеп ятучы да түгелмен. Күңел алгысынган көнне, малларны тиз генә карыйм да, шәһәрне әйләнеп кайтам. Дус кызларым белән очрашам. Быел диплом елым – университетка да еш барырга туры килә.

Язмамның башында, кыз бала подиум, сәхнә турында хыяллана инде ул, дигән идем. Һәркем хыяллана, әмма тормышка ашыручылар гына сирәк. Гөлнара андый түгел! Модельләр әзерләүче студиягә йөргән – подиумнан атлап караган ул. Ә сәхнә... Сәхнә әле аны алда көтә! Узган ел Казан федераль университетына укырга кергән – бүген ул Лидия Әхмәтовада вокал дәресләре ала. (Сүз уңаеннан, остазыннан кала, группа-дашларның берсе дә аның фермер икәнен белми! «Сөембикә»нең бу саны чыккач, сер ачылыр инде... Укытучыларының Гөлнарага: «Авызыңны җырлаганда үрдәк кебек ач!» – дигәнен шуңа берсе дә аңламый. «Нигә сиңа алай әйтә ул?» – диләр, аптырап. «Ишегалдым тулы үрдәк булганын белгәнгә», – дия алмый бит...) Сыер сауганда гел җырлыйм, дигән иде бит. Караокэ куеп җибәрә дә алдагы дәрескә яңа җырлар өйрәнә.

Галиябану («Галиябану»), Мәйсәрә («Зәңгәр шәл») арияләрен тыңлый-тыңлый күшәгән сыерлар биргән сөтнең тәмен белергә теләсәгез, ярминкәдә Югары Ослан кызы Гөлнараны эзләгез.

Гөлнур САФИУЛЛИНА



PRESSA.RU

ЗУР СУГЫШ БЕТСӘ ДӘ, ҮТМӘДЕ

БЫЕЛ КЕШЕЛЕК БӨЕК ҖИҢҮНЕҢ 73 ЕЛЛЫГЫН БӘЙРӘМ ИТӘ.

Миллион корбаннар биреп, миллионнарны ятим һәм тол иткән ул сугыш турында язасы да язасы, сөйлисе дә сөйлисе әле... Сугышның чын йөзе, халкыбыз биргән корбаннар саны яңа документларда ачыла бара. Илебез архивларында сугыш чынбарлыгын сөйләүче хатлар, көндәлекләр, шикаятьләр, Указлар, эш кәгазьләре саклана. Саннар теле белән, ул елларда халыкның ниләр кичергәнен сөйли бу документлар...





Лилия
ГӘРӘЕВА

Ирләрсез һәм атларсыз авыл

Бөек Ватан сугышын авыллар шактый талкынган хәлдә каршылый. Авылларда эшче кулларга инде утызынчы еллар ахырында ук кытлык күзәтелә. Колхозлардагы хокуксызлыктан качып та, халыкларны күчерүгә корылган сәясәт нигезендә дә сугышка чаклы ук республика авылларыннан 133426 кешенең читкә чыгып китүе мәгълүм. 1939 елгы җан исәбен алу нәтиҗәләре буенча, республикада 2915277 кеше исәпләнә. Аның 1555542 се – хатын-кызлар. Халыкның 78 процентган күбрәге – авылныкылар. 1937 елга республикада 3847 колхоз һәм 51 совхоз булуы мәгълүм.

Сугышның беренче көненнән үк Татарстан 560 мең кешесен фронтка озата. Моннан тыш, 140 мең ир-егет сугышны Кызыл Армия сафларында каршылый. Авыл ирләрсез кала. Чәчү төгәлләнеп, инде печәнгә төшәргә торган көннәр бу. Эшнең иң кызган чагы. Бөтен эш хатын-кыз, бала-чага һәм картлар җилкәсенә күчә. Эшкә ярардай техника да тиз арада фронтка озатыла. СССР Югары Советының 1941 елның 23 июнендә чыккан Указы нигезендә, Татарстан фронтка өч көн эчендә 380 трактор, 209 трактор арбасы, 149 җиңел машина бирергә тиеш була. Дүрт ел эчендә республиканың автотранспорт паркы 80 процентка кими. Калганнарында да эшли белүче юк. Шуңа да 1941 елның көзендә хатын-кызларны трактор йөртергә өйрәтү курслары ачыла.

Минем дәү әнием Хәдичәбикә дә сугыш елларында тракторчы була. Ул сөйләгәннәр гел күз алдында. Төн уртасында җир сөрүләре, трактор артына ач бүреләр тагылып йөрүе, шул чакта «тракторым гына сүнмәсә ярар иде», дип теләүләре, йоклап китеп, трактор астында калмас өчен, үзен бау белән утыргычка бәйләп куюлары...

«Бер грамм ипи бирмәделәр!»

Сугыш елларында комбайнчы булып эшләгән Тамара Филиппованың архивта көндәлекләре саклана. 1924 елны Лаешта туа ул. Сугыш башланган елны Казан дәүләт химия-технология институтына укырга керә. Сугыштан соң Казан стоматология институтын тәмамлап, 44 елын медицинага багышлый.

«**1942 елның 11 феврале.** Хәзер автошколада комбайнерлар курсында укыйм. Әнинең, тамагыбыз ипигә туяр иде, дигәнен тыңлап кына бардым. Әлегә тракторны өйрәнәбез, комбайнны соңрак өйрәтәчәкләр.

26 февраль. Әтидән ике открытка алдым. Укуыңны ташлый күрмә, укы, дип яза. Ә мин... Мин бит инде инженер-механик урынына комбайнерлыкка укыйм.

...Тизрәк бетсен иде бу сугыш, әти дә исән булсын иде, мин дә кабаттан укый башласам иде, ләкин комбайнчы булырга түгел, ә инженер-химик яки шуның ише башка бер һөнәргә.

Әни кайтмады (Алексеевскийга ипигә дип киткән иде). Ялгызыма кыен. Кайтасың, ә өйдә салкын, ашарга бернәсә дә юк. Тизрәк кайтсын иде инде.

7 июнь. Менә инде бер атна МТСта эшлим. Бүген ялга өйгә кайттым. Эш авыр, барыбыз да җенгә охшап калдык – киемнәр пычранып, керосинга, автолга, солидолга батып бетте.

14 июнь. Хәзер бригадалап эшлибез. Мин Светлов бригадасында, ул МТСта иң яхшы комбайнер санала, көн саен 300 гектар иген ура. Әлегә моторлар рәтлибез, инде икесе әзер. Бригадада без дүртәү. Эш – иртәнге җидедән кичке алтыга кадәр.

8 сентябрь. Көндәлекләремә күптән язганым юк. Чөнки моңарчы өйдә булмадым. Астраханкада комбайнда эшләдем. 71 гектар ашлык урдык. Шуңа өстәп, тагын 96 центнер ашлык суктырдык. Барысы бергә 95 гектар. Шулай да тиеннәр генә түләделәр, бер грамм ашлык эләкмәде. Әни мине комбайнга укырга шул ипи булыр дип кенә үгетләгән иде. Икмәк – комбайнер ярдәмчесенә, ә сезгә эш өчен акча түләнә, дип, бер грамм ипи бирмәделәр.

Анда чиккән азапларыбыз! Пычрак, тузан шулкадәр туйдырды. Ашау ягы такы-токы. Гомумән, эш шартлары бик начар иде».

Дәүләт авыл алдына яңа бурычлар куя, чәчүлек басу мәйданнары ел саен арттырыла. 1941 елда игенне 9,6 мең гектарга артыграк чәчәләр, әмма колхозлар дәүләткә 656 мең тонна гына бөртек тапшыра ала. Дәүләт планының нибары 73,6 проценты гына була бу. Ул елны җәй ахыры, көз башы бик яңгырлы килә, хатын-кызлар кул көче белән генә аның кадәр игенне урып өлгертә алмый. 100 гектар басу урылмыйча кала.

1943 елның июненә хатын-кызлардан торган 123 тракторчылар бригадасы оеша. Анда 11554 хатын-кыз эшли.

Таяк хакы

Дәүләт фронт өчен икмәк, сөт, ит, йомырка, май, йон, җылы кием-салым таләп итә. Ничек, нинди көч бәрабәренә эшлисе моны?

1942 елның 13 апрелендә СССРның Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты Карары белән хезмәт көне нормасы арттырыла. Бер колхозчы елына кимендә 120 хезмәт көне эшләргә тиеш була. 12-16 яшьлекләр өчен норма 50 көн итеп куела. Хезмәт көне бер көн эшләүне белдерми, ул эш күләмен исәпләү берәмлеге булып кына тора. Мәсәлән, 2 гектар чөгендер утау бер хезмәт көне булып санала. Балаларга исә, яшенә карап, 0,15 гектардан алып, ярты гектарга кадәр норма кертелә. Яңгыр явамы, кармы – норманы үтәргә кирәк. Үтәмәсәң – җәза көтә.

Норма колхозчыларга гына түгел, хәтта сыерларга да билгеләнә. Алар өчен махсус дирбияләр әзерләнә. 1944 елда чәчүне атна-ун көндә тәмамлау өчен, тиз арада 10 мең сыерны җигәргә өйрәтү бурычы куела. Сугыш елларында авыл

Тракторчы А. Ганиева. 1941-1945 еллар. ТР Милли музей фондыннан.

PRESSA.RU



Икмәк җибәрү пунктында ашлык тапшыру. Биектау районы, 1943 ел. ТР Милли музее фондыннан.



Комбайнер хатын-кызлар комбайнны рәтләп бетергән. Биектау МТСы. 1942 ел. ТР Милли музее фондыннан.



Икмәк төялгән Кызыл олаулар. 1944 ел. Буа районының «Коминтерн» колхозы. ТР Милли музее фондыннан.

хуҗалыгы эшләрендә 36 мең баш сыер кулланыла. Бер сыер белән көненә 2-3 гектар җир сөрү яхшы күрсәткеч санала.

Кешеләр никадәр генә тырышмасын, нормаларны ничек кенә арттырмасын, моның өчен аларга берни дә бирелми. 1940 елда бер колхозчыга елына 12 сум 13 тиен түләнгән. Аена 1 сум дигән сүз бу. Югыйсә 1940 елда СССРда минималь хезмәт хакы 33 сум итеп билгеләнгән була. Колхоз хезмәт көннәре өчен натуралата түли. Бер хезмәт көненә якынча 400-700 грамм ашлык бирелә.

Күтәрә алмаслык салымнар

1940 елдан колхозчылар үз хуҗалыкларында җитештерелгән һәрнәрсәдән салым түли: сөт, ит, йомырка, йон, бәрәңге, яшелчә, бал... Ашарыңа каламы, юкмы, өй тулы балаң ачка тилмереп утырамы – анда берәүнең дә эше юк. Азык-төлек салымыннан тыш, акчалата да салым түлиләр әле. Еллык кереме 700 сумга кадәр булганнар һәр сумының 8 тиенен дәүләткә бирә. Керемең 700 сумнан 1 мең сумга кадәр булса, салым күләме 56 сум, һәм шуңа өстәп, һәр сумның 9 тиене күләмендә түләргә тиеш буласың. Салымнар, чынлыкта, колхозчының фактик керемендә карап түгел, финанс органнары үзбелдекләнеп куйган тарифлардан чыгып билгеләнә.

1942 елның июнендә Татарстанда авыл хуҗалыгы салымы ике тапкырга арттырыла. Әле бу хакта союз күләмендә постановление дә чыгып өлгерми. 15 көн эчендә Татарстанның бер Октябрь районында гына да салым 6-7 тапкырга күбрәк җыела. Чынлыкта, бу авыл халкын чын-чынлап талау, ач үлемгә дучар итү була. Салым түли алмаучыларның сыерлары тартып алына. Шул Октябрь районында ике атна эчендә колхозчылардан 50 баш сыер конфискацияләнә. Конфискацияләр әйбере булмаганнарның өй түбәсе сүтеп алына. Мәсәлән, Чүпрәле районы Каракитә авылында авыл хуҗалыгы салымы түләмәгән өчен 55 йортның түбәсе сүтелә (ТР Дәүләт архивы ф. Р-3610 оп. 1).

Авыл халкы болай да көч-хәл белән түләгән салымнарга займнар өстәлә. 1940–1944 елларда Татарстанда 1067038 сумлык займ сатыла. Аның ничек сатылганы сүзсез дә аңлашыладыр инде...

Алдымда Красный Бор районы (хәзерге Әгерҗе) Барҗы-Умга авылыннан фронттагы Әхмәтгәрәй Гарифуллинга гаиләсе язган хат. Ул капитан Б. Салеев тарафыннан рус теленә тәрҗемә ителгән булган. Бәлки, шуңамы, хат авторының исеме Шура дип бирелә.

«Исәнме, кадерле әткәем! Бу хатны кызың Шура яза. Әнкәйдән, Рәистән, Рәхимҗаннан күп сәлам. Сине белгәннәр дә сәлам тапшырырга кушты.

Әткәй! Хатыңны алдык, рәхмәт. Синең исән-сау икәнеңне белеп, бик шатландык. Үзебезгә килгәндә, безнең тормыш итү бик авырлашты. Барысын да язып бетерүе дә бик авыр. Галимҗан энемне җирләдек, ачтан үлде. Өч көндә бик каты шешенде, саклап кала алмадык, өйгә керерлек тә түгел иде, бик яман ис чыкты. Әткәй! Шәмсикамал апа да унбиш көн инде урыннан тора алмый. Башта ашарга сорый иде, хәзер инде сорамый да. Өйдә ашарга яраклы бер әйбер дә калмады. Сатарлык әйбер дә юк. Әткәй, мунчаны сатарга рөхсәт итче? Сыерны инде суеп ашадык.

Әткәй, безнең хәлләр менә шулайрак. Нишләргә дә белмибез. Әни тәмам бетереште. Безгә нишләргә икәнен әйтеп хат яз.

Әлегә менә шушылар. Хәзергә сау бул, исән-сау йөр.

Кайнар сәламнәр белән, хатының һәм кызың Ш. Гарифуллина».

Сугыш өзгән балачак

Бөек Ватан сугышы елларында Татарстан – иң эре тыл регионнарының берсе. Фронт сызыгындагы шәһәрләрдән эвакуацияләнүчеләрнең беренче эшелоннары Юдино станциясенә 1941 елның июлендә үк кайта. Аларны урнаштыру эше Совнаркомның эвакуация советына йөкләнә. Шәһәрләрдә эшчеләр һәм

җитәкче состав гаиләләре генә калдырыла, калганнарның барысы да авылларга җибәрелә. 1942 елның язына республикабызга 276438 кеше эвакуацияләнсә, 1943 елга тагын 278943 кеше кайта.

Болардан тыш, Татарстанның шәһәр һәм районнарына алгы сызыктан бик күп балалар оешмалары күчеп килә. 1941 елның 1 декабренә республиканың 30 районына 67798 бала урнаштырыла.

Балаларының бакча, ясле, лагерь белән эвакуацияләнүен кайчагында әти-әниләре белми дә кала. Юлда барганда еш кына балалар төркемнәрен бергә кушалар, алар адаша, үлә... Бик кечкенәләре үзләренең исемнәрен әйтә алмый. Шуңа да алар арасында «Неизвестный» «Неизвестная» фамилияләре күп.

Архивта әти-әниләрнең үз балаларын эзләп, республиканың төрле районнарына өзгәләнеп язган хатлары саклана.

А. И. Малейко Минск шәһәренең 12 нче балалар яслесеннән эвакуацияләнгән 3 һәм 2 яшьлек балаларын сугыш беткәнче эзли. Аның ТАССРның мәгариф комитетына язган хатыннан юллар: «Мин бик күп шәһәрләргә хатлар юлладым. Әмма бар җирдән дә тискәре җавап килде. Балаларны юлда башка шәһәрнекеләр белән кушканнардыр дип уйлыйм. Үтенеп сорыйм: үзегездә булган барлык исемлекләрне җентекләп карап чыксагыз иде. Сездән икенче тапкыр тискәре җавап алганнан соң, мин аларны үлгән дип санаячакмын». Кызганыч, Татарстанда аның балалары табылмый. Бәлки, ниндидер бер сәбәп белән, яследә булмый калганнардыр яки, кечкенә булганлыктан, үз исемнәрен әйтә алмаганнардыр...

Үзләре дә көчкә җан асраган, ягарга утыны, киярргә киеме булмаган авыллар җилкәсенә эвакуацияләнүчеләрне кайгырту да өстәлә. Читтән килгәннәргә тиешле шартлар тудыруда кыенлыклар чыга. Латвиянең Халык мәгарифе комиссариаты П. Валескалнның һәм Латвиянең ТАССР буенча вәкиле Стипнекның ТАССРның Халык Комиссарлары Советы председателе С. Х. Гафиатуллинга Латвиядән ТАССРның Олы Мәңгәр авылына эвакуацияләнгән пионерлар лагереның торышы турындагы запискадан өзек:

«...Хәзерге вакытта интернатта 9 яшьтән 17 яшькәчә 235 бала бар. Бина каралмаган, стенадагы ярыклардан бүлмә эченә җил өрә, кар керә. Күп кенә бүлмәләрдә тәрәзәләрнең хәтта рамнары да юк, рамы булганнарының пыялалары ватык. Мичләрнең берише җимерек. Әлегә кадәр интернат кирәкле җиһазлар да, кием-салымнар да алмаган. Балаларның үз өстендә булган киемнәре тетелеп беткән, ботинка, тапочкалары тузган. Салкын көннәрдә балалар көнне дә, төнне дә юрган астында уздыра. Ул юрганнарны шушы балалар йөз чакрымнан үзләре күтәреп алып кайткан. Алары да җитешми. Бер юрган астында, асларына бер кат капчык җәеп, өчәр-дүртәр бала йоклый. Балаларның алмашка эчке киемнәре дә юк.

Күп балалар җәй көне елгада юынганнан бирле юынмаган, су ташырга чиләкләре юк. Интернатта җыештыручылар җитми, кер юучыны бөтенләй дә алмаганнар. Нәтиҗәдә, балалар бетләгән. Шушы ялангач балалар кар өстеннән яланаяк килеш ишегалдындагы бәдрәфкә йөриләр. Күбесенә салкын тигән. Өч баланы җирләгәннәр. Алты бала бик авыр хәлдә хастаханәдә ята. Интернатта да авырып ятучы балалар күп. Аларга медицина ярдәме күрсәтелми. Киемнәре булмагач, балалар укырга йөри алмый.

Балаларны ашату бик начар оештырылган. Әлегә кадәр аларга бер тапкыр да сөт бирелмәгән. Менә инде ике атнага якын плитәләрен рәтләп бетерә алмыйлар, шуңа балаларны көнгә бер тапкыр гына ашаталар. Иртә-кичен ипи белән май янына хәтта чәй дә бирелми. Интернаттагы балаларның барысына бергә нибары 40 тәлинкә-кашык бар. Хуҗалыкта кирәк булган беренчел кораллар: көрәк, чиләк, кул югычлар юк».

Әти-әниләреннән аерылган, тел белмәгән, чит-ят кешеләр арасына, коточкыч шартларга килеп эләккән ул балаларга сугыш елларында ниләр генә кичерергә туры килми.

Буа районына эвакуацияләнгән Нина Горюнованың әнисенә язган хаты (тәрҗемәдә бирелә): «Исәнме, ягымлы, кадерле әнием минем Зоечка һәм сөекле Валюся! Ничек яшисез? Без сезне бик сагындык, Валечканы уйлап, гел елыйбыз. Әтине инде хезмәт итәргә алдылар. Әнием, безнең киярргә киемнәребез бетте, юрган, мендәр тышлары, җәймәләр дә калмады, сезне бик сагынабыз. Әнием, минем бик тә йөрәгем авырта. Тын ала алмыйм, шуңа гел елыйм. Әнием, минем артымнан тизрәк кил, минем киез итегем юк, бернәрсәм дә юк. Мин синсез үләм. Әнием, кил. Көтәм сине, өзелеп сорыйм. Мин сине 25 августтан бирле көтәм».

Көтеп җиткерә алдымы икән бу бала әнисен?..

Сугышка кадәр 19 балалар йорты эшләсә, 1945 елның 1 июленә 108 балалар йорты исәпләнә.

...Бөек Җиңү көнендә күккә салютның аллы-гөлле чаткылары сибелгәндә, алар миңа шушы миллионнарча корбаннарның җаннарыдыр кебек тоела. Бер мизгелгә генә кабынырга өлгереп, нибары бер мизгелгә балкыган җаннар... Вакытсыз өзелгән гомерләр, толларның, аналарның газизләре кайтыр юлларга сеңгән күз нуры, ятимнәрнең канлы күз яше, алар күргән михнәт, газап, ачлык, югалтулар... Кешелеккә гыйбрәт алырлыктыр бит инде, шәт?..

Материалны әзерләүдә ярдәм иткәннәре өчен Татарстан Республикасы Дәүләт архивына, Татарстан Республикасының Милли музеена, «Гасырлар авазы» журналы редакциясенә рәхмәт белдерәбез.

PRESSA.RU

Фәрит
БИКЧӘНТӘЕВнең
тормыш
кагыйдәләре



«ТЕАТРЛАР КҮП БУЛСЫН»

СПЕКТАКЛЬ ЧЫГАРУ МИНЕМ ӨЧЕН – КЕЧКЕНӘ ГЕНӘ ҮЛЕМ. Тупланган фикерләрне, җыелган хисләрне артистлар белән бергә спектакль аша дөньяга чыгарасың һәм бушанып каласың. Шуннан әкренләп-әкренләп туасың һәм яңа бер нәрсә тудыра башлыйсың.

Спектакль үз тормышы белән яши башлый. Режиссер нәрсәдер үзгәртсә дә, артыгын үзгәртә алмый. Артистлар, мәсәлән, тамашачылар белән очраша, ә **РЕЖИССЕР БУ ОЧРАКТА ЧИТТӘ КАЛА**.

ИҖАТ КЕШЕСЕ АЧ БУЛЫРГА ТИЕШ ДИГӘН СҮЗ ДӨРЕС ТҮГЕЛ. Дөресрәге, ул тук булырга тиеш түгел.

ХӘЕРЧЕЛЕК ШЕДЕВР ТУДЫРА АЛМЫЙ. Теләнергә калган иҗатчы, билгеле, шедевр турында түгел, тамагын кайгырту турында күбрәк уйларга мәҗбүр. Һәрхәлдә, бүген бөтен нәрсә акча белән үлчәнгән заманда иҗат кешеләренә шартлар тудырылырга тиеш. Без бит рухи байлык тудырабыз, нәрсәдер эшләп чыгармыйбыз. Иҗат кешеләренә хөкүмәт тарафыннан зур игътибар кирәк.

Күптән түгел Мәскәүдә бер фестиваль вакытында Норвегия язучысы Юн Фоссе белән онлайн әңгәмә булды. Бүгенге көндә ул иң популяр авторларның берсе. Әңгәмә вакытында аның матди хәленә кагылышлы сораулар да бирделәр. **НОРВЕГИЯ КОРОЛЕ АНЫҢ ӨЧЕН ҮЗЕНЕҢ САРАЕНДА АЕРЫМ АПАРТАМЕНТЛАР ТОТА.** Альпларда йорты бар, ягъни тормышның матди ягы турында кайгыртудан азат. Аның нәрсә икәнен дә белми. Ул бары тик иҗат итә. Гәрчә тарихта Модильяни, Ван Гог кебек рәссамнарны хәерче булган, диләр.

Иҗатны халык кына бәяли ала. **ХАЛЫККА ҖИТКЕРҮ ӨЧЕН ИҖАТ КЕШЕСЕНӘ ЯРДӘМ ИТӘРГӘ КИРӘК.** Мәсәлән, бүгенге көндә талантлы яшь композитор Эльмир Низамов талантына күрә дөрес бәяләнми. Әйтик, ул Норвегиядә туган булса?

Иҗат кешесендә фикер хөрлеге булырга тиеш. **ХӨКҮМӘТ АНЫҢ ИРЕГЕН КЫСАРГА ТИЕШ ТҮГЕЛ.** Ә бит фикерен кычкырып әйткән кешеләрне «психушка»га япкан, төрмәләргә утырткан чаклар да бар иде. Кызганыч, бүген дә иҗат кешеләрен кысрыклау очрый.

КОРЪӘН БЕЛӘН ИНҖИЛДӘ БАРЫСЫ ДА ЯЗЫЛГАН. Укы да шуның буенча яшә генә бит инде. Юк. Кешелек дөньясы шундый китаплардан да сабак ала алмагач, кая таба барадыр ул?

Кешелек дөньясы барлыкка килгәннән алып «Ничек яшәргә?», «Ничек дөрес?» дигән сорауларга җавап эзли, вакыт-вакыт безгә пәйгамбәрләр җибәрәләр. Ә кешелек һаман эзли. Шуңа да **МИН КЕШЕЛЕК ДӨНЬЯСЫНА ПЕССИМИСТЛАРЧА КАРАШТА.**

Кемдер: «Оптимист – булып җитмәгән пессимист ул», – дип әйткән. Һәм киресенчә. **МИН ОПТИМИСТ БУЛСАМ ДА, ПЕССИМИСТ БУЛСАМ ДА, АНЫҢ ҺӘРВАКЫТ ИКЕНЧЕ ЯГЫ БАРЛЫГЫН ОНЫТМЫЙМ.**

МИН УСАЛ ТҮГЕЛ, кайчак чыннан да кәефсез чагым була.

Элегрәк кәеф кешесе идем. **СОҢГЫ ВАКЫТТА ҮЗҮЗЕМНЕ «ИЯРЛӘРГӘ» ӨЙРӘНДЕМ.**

ГЕЛ ЕЛМАЕРГА КИРӘК. Ләкин гел елмаеп йөрсәң, тиле дип тә уйларга мөмкиннәр.

Юморсыз кешегә сәнгатьтә урын юк. **РӘХӘТЛӘНЕП, КЫЧКЫРЫП КӨЛӘРГӘ ЯРАТАМ.** Көлү – сәламәтлек билгесе ул.

РУСЧАСЫН ДА, ТАТАРЧАСЫН ДА КУШЫП, КАТЛЫ-КАТЛЫ ИТЕП СҮГЕНӘ БЕЛӘМ. Эмоцияләрне дөньяга чыгаруның бер ысулы ул.

Үзем канәгать калмаган эшем юк. Шул ук вакытта **КАНӘГАТЬСЕЗЛЕК ТӘ, КҮЛӘГӘ КЕБЕК, ЯНӘШӘ ЙӨРИ.** Һәм шул иҗат итәргә этәрә дә.

ПРЕМЬЕРАЛАРДАН СОҢ, МӘГЪЛҮМАТ ЧАРАЛАРЫНДА НӘРСӘ ЯЗАЛАР, НИЧЕК БӘЯЛИЛӘР – ЭЛЕГРӘК ИГЪТИБАР ИТӘ ИДЕМ, ХӘЗЕР УКЫМЫЙМ ДА, КЫЗЫКСЫНМЫЙМ ДА.

Интернет адәм баласының фикерләү сәләтен үтереп бара. Кешенең кешегә, тормышка, вакыйгага карата үз карашы юк. **АДӘМ БАЛАСЫН ФИКЕРЛӘҮ**

Фото: Ксения Богданова

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ

PRESSA.RU

ИХТЫЯҖЫННАН АЗАТ ИТТЕЛӘР. Төп масса шулай итеп деградациягә дучар ителде. Механизмы бик гади аның: интернетта кешегә аноним рәвештә пычрак атып була хәзер. Кеше эчендәге бөтен негативын чыгарып түгә, ә үзе билгесез кала. Мондый пычраклыкны йөрәгенә якын алган кешеләрне беләм. Алай йөрәк өянәге дә алырга була.

Болай дөрес түгел. **БУ ПСЕВДОАЗАТЛЫК ДИП АТАЛА, КЕШЕЛӘР БЕЛӘН МАНИПУЛЯЦИЯ ЯСАУНЫҢ БЕР ТӨРЕ.** Һәм ул кешеләр арасындагы мәхәббәтне, яктылыкны үтерә.

МӘХӘББӘТКӘ УРЫН КАЛМЫЙ ШУЛАЙ ИТЕП. Күптән түгел студентлар белән «Кыйссаи Йосыф»ны укыганда мәхәббәт турында бер кызыклы әңгәмә килеп чыкты. Анда Зөләйханың Йосыфка ничек итеп гашыйк булуы, кая барса, шунда Йосыф сурәтен күрүе турындагы урыннарны өйрәнәбез. Студентлар: «Бу – әкият», – дип көләләр. Бер яшь егеттән: «Синең гашыйк булганың бармы?» – дип сорыйм. Ул: «Ничек була соң ул гашыйк булу?» – ди. «Мин синнән сорыйм», – дим. Белмиләрме? Юкмы ул аларда? Шашып, башны югалтып яратканнарын күргәнем юк хәзер.

МӘХӘББӘТ – КУРКЫНЫЧ ДӘРӘҖӘДӘ ОЛЫ НӘРСӘ УЛ.

Халыкка хезмәт турында Туфан абый Миңнуллин «Миләүшәнең туган көне»ндә гаҗәеп дөрес итеп әйтә. Пьесада Миләүшә «җырлый башлаганда, миңа бөтенесе дә, син халыкка хезмәт итәргә тиеш, дип әйтә иде, мин бу сүзләрнең асылын аңламый идем, **НИНДИ ХАЛЫККА, НИ ӨЧЕН ХЕЗМӘТ ИТӘРГӘ ТИЕШ МИН**, дип уйлый идем. Моның нәрсә икәнен җырлаудан туктагач кына аңладым, чөнки мине тыңламый, танымый башладылар. Халыкка хезмәт итмәсәм, мин, бәлки, җанны телгәләмичә генә, икенче төрлерәк итеп яшәр идем», дигән фикер әйтә.

Иҗат кешесе махсус рәвештә халыкка хезмәт итәм дип кенә яшәсә... **ИҢ МӨҺИМЕ: ХАЛЫКНЫҢ КОЛЫНА ӘЙЛӘНМӘСКӘ.** Тукай халыкка хезмәт итте, ләкин аның колына әйләнмәде.

Театр да бит халыкка хезмәт итә. Ләкин ничек хезмәт итәргә? Менә шунысы мөһим безнең өчен. Хезмәт итәм дип, үз-үзеңне югалтырга ярамый, чөнки **ИҖАТ КЕШЕСЕ ХАЛЫКНЫ ҮЗЕ АРТЫННАН ИЯРТЕРГӘ ТИЕШ.**

ХАЛЫК АРТЫННАН ИЯРӘСЕҢ ИКӘН, МОНДА ИНДЕ БИЗНЕС БАШЛАНА. Сүзне шуны ачыклаудан башларга кирәк. Элек филармониядә Илһам абыйлар, Әлфия апалар хезмәт хакына гына эшләгән. Авылда концерт куйганнан соң, тамашачылар рәхмәт йөзеннән йомырка биргәндер инде... Хәзер бу өлкә бизнеска әйләнде. Шоу-бизнес дип атала да бит инде ул.

Режиссер – фикер тудыручы, аны тамашачыга җиткерүче, зәвык тәрбияләүче кеше. **РЕЖИССЕРНЫҢ ЭШЕ ТАМАШАЧЫНЫ ДА, АРТИСТНЫ ДА, АВТОРНЫ ДА ХӨРМӘТ ИТҮДӘН БАШЛАНА.** Режиссер булу – коточкыч зур җаваплылык.

БҮГЕН ФӘРИТ БИКЧӘНТӘЕВ МӘКТӘБЕ БАР, ДИП ӘЙТӘ АЛАМ. Горурланып. Шәкертләрем Камалда гына түгел, Буа, Әтнә театрларында да эшли.

ТЕАТРЛАР КҮП БУЛСЫН. Аның барыбер бер нәтиҗәсе була. Баштарак, күбәйделәр, дип зарланган идек. Хәзер әнә Әлмәт театры «Алтын битлек»кә дәгъва итә. Минзәләләр «Иблис»не куя. Әтнә, Чаллы театрлары әйбәт премьералары белән шатландыра. Буа театрына элек җитди итеп карамыйлар да иде. Бүген анда зур фестивальләр оештыралар.

ТАТАР ТЕАТРЫ ҮЗЕ БЕР ИНСТИТУТКА ӘЙЛӘНЕП КИЛӘ. «Нәүрүз» төрки театрлар фестиваленең йогынтысы көчле. Театр спектакльләр генә чыгарып калмый, ә эстетика формалаштыра. Мәдәниятләр диалогы нәкъ менә шушында – Казанда, Камал театрында бара. Без пространствоны ачарга тырышабыз. Үзебезне табар, ниндилегебезне ачыклар өчен.

Бүгенге заманда интеллигент кешегә урын да юк дип уйлыйм мин. **ИНТЕЛЛИГЕНТ АРКАСЫНДА КЕМГӘДЕР КЫЕН БУЛА АЛМЫЙ.** Ул беркайчан да моңа юл куймый. Бу үзенә күрә бер әхлакый биеклек. Ләкин интеллигент әүлия булырга тиеш дигән сүз дә түгел әле.

Әти буларак, мин кайчак кырыс, кайчак йомшак. Йосыфка үземнең уй-фикерләремне такмыйм. Аның – үз юлы, минем – үземнеке. Әлбәттә, без сөйләшәбез, фикерләшәбез. **МИН АҢА ДУС БУЛЫРГА ТЫРЫШАМ.** Һәм бу безнең килеп чыга да кебек.

ИР КЕШЕНЕҢ ГАИЛӘДӘ НИНДИ БУЛУЫН ХАТЫННАН СОРАРГА КИРӘК. Мин өйдә сирәк булам бит. Иртән чыгып китәм, кич кайтам. Өйдә театр турында сөйләшмәскә тырышабыз, ләкин сүз барыбер шуңа кайтып кала.

Бу очракта Люциягә рәхмәт әйтәсем килә. Ул мине көндәлек мәшәкатьләрдән саклый, азат итә. **ЧҮП ЧЫГАРУДАН КАЛА, МИН ӨЙДӘ БЕР ЭШ ТӘ ЭШЛӘМИМ.**

Фикерләр тупланмасын Ландыш ӘБҮДӘРОВА теркәде.

ИРЕМНЕҢ ЧИТТӘ БАЛАСЫ БАР...

«Ирем белән машинада барабыз. Берзаман: «Әгәр минем читтә балам булса һәм мин аны безнең өйгә алып килеп йөрергә теләсәм, син моны ничек кабул итәр идең?» – дип сорап куймасынмы! Шаярта дип уйладым, кычкырып көлеп җибәрдем. Тик ирем көлмәде. Аның җитди йөзенә карагач, барысын да аңладым: ул шаяртмый иде. Аның читтә баласы бар! Һәм ул миңа моны өйләнешеп өч ел үткәннән соң гына әйтә! Башта берникадәр вакыт шок хәлендә утырдым, аннары ачуым килде, аннары үпкәләдем. Инде бер атна ирем белән сөйләшми йөрим. Көйсез кыз булып кыланудан түгел бу, нәрсә әйтергә белмәгәннән. Иремне яратам, аны югалтудан куркам. Шуңа күрә «йә мин, йә балаң» дигән сайлау алдына куясым килми. Тик йөрәгем читтә баласы булуын да кабул итә алмый. Өстәвенә, аны безнең өйгә алып килеп йөрергә тели бит әле. Ул баланы ничек кабул итәсемне, аңа нәрсә әйтәсемне уйлый да, күз алдына китерә дә алмыйм. Баланың әнисе кем, ирем хәзер аның белән нинди мөнәсәбәттә дигән сораулар да борчый. Нәрсә эшләргә белмим...»

Исемем редакция өчен генә.
Чаллы шәһәре.

♀

Камилә ХӘЙРУЛЛИНА, 27 яшь:

Менә хәзер ирем миңа «читтә балам бар» дип әйтте ди... Күз алдыма китереп карадым да, тәннәрем чемердәп китте. Беренче хис – көнләшү. Көнләшер идем, әлбәттә, җаны булган бөтен хатын-кыз да көнләшер иде дип уйлыйм. Ә йөрәкне «сүндереп» куеп торып, акыл белән уйлап карагач, баланың ни гаебе бар инде, дигән уй килә. Аның да әтисе белән аралашырга, аның янында булырга хакы бар бит. Чынлап торып яраткан кешеңнең якыннарын да яратасың дигән сүз дә бар әле. Бәлки, миңа моны үзем шул ситуациядә калмаганга гына әйтү җиңелдер. Шулай да мин ачуымны һәм үпкәмне онытырга, ирне кичерергә, баласын кабул итәргә тырышыр идем. Баланы бөтенләйгә яшәргә алып килми, кунакка гына алып килергә тели бит ул – үземне шулай дип тынычландырыр идем. Шунысы да бар: ирнең баласын гаиләгә алып килеп йөрергә теләве дә юкка гына түгелдер. Димәк, ул хатынының яратуына, үзен аңлавына, теләсә нинди очракта да терәк булачагына ышана. Ул көткәннең киресе булса, хатынына карашы да үзгәрергә мөмкин бит.

♂

Рамил САТТАРОВ, 39 яшь:

Ир хатынына читтә баласы барлыгын әйтергә булган икән, моның ике сәбәбе булырга мөмкин. Беренчесе – ул элеккеге мөнәсәбәтләренә (беренче никах булсынмы ул, әллә никахсыз гына мөнәсәбәтме) кире кайтырга тели. Ул мөнәсәбәттән туган баланы өйгә алып кайтырга теләве дә – хатынын әзерли тору. Ләкин мин бу вариант турында бик бирелеп уйланмас идем. Без, ирләр, эшлисе эшебезне читләтеп әйтергә яратмыйбыз (әйтә дә белмибез), шуңа күрә гаиләдән китәргә уйлаган ир дә, баласын өйгә алып килеп йөреп, шул рәвешле хатынын «әзерләп» мәшәкатьләнмәс – тотар да китәр иде.

Ә икенче сәбәп – ир хатынына бөтен барлыгы белән ышана, арада сер булмавын тели, шуңа күрә читтә туган баласын да өйгә алып килеп йөрергә теләк белдерә. Хатыным мине яратса, миннән туган баланы да яратыр, дип уйлый. Бала турында әйтүе дә – хатынына ышаныч күрсәтүе.



Ләлә БӘҺРАМШИНА, психолог

Өч фикер

– Хатын-кыз ирен балага түгел, ул баланың анасына көнли. Бала безгә кунакка килеп йөри башласа, ирем миннән читләшер, дип уйлый. Көнләшү һәрвакыт «ул миннән яхшырак», «аны миңа караганда ныграк яраталар» дип уйлаудан барлыкка килә. Шуңа күрә көнләшүче хатын-кызлар үз-үзләренә ышанмый, үзбәясе түбән, дибез. Үз-үзенә ышанса, ул ире белән мөнәсәбәтләренең ныклыгына шикләнми. Ире нәрсәдер эшли икән (бу очракта читтә туган баланы гаиләгә алып кайту), димәк, шулай яхшырак, һәм аның фикерен хөрмәт итәргә кирәк, дип саный, иренә терәк була.

Баланың гаебе юк. Хатын иренең яратуына, назына мохтаҗ булган кебек, бала да әтисенең мәхәббәтенә, аның белән аралашуга, аңлашуга мохтаҗ. Болар – табигый ихтыяҗ. Димәк, баланы аннан мәхрүм итәргә ярамый.

Мондый очракта хатын-кыз нәрсә эшли ала соң? Һәр уйның юнәлеше, фокус ноктасы бар. Әгәр хатынның игътибар фокусы «ирем гаиләдә барысы да яхшы булсын өчен тырыша» дигән фикердә тормый, ул уенда шикләнә башлый икән, үз-үзенә сорау бирсен: ирем бу баланың анасы белән араларын җайларга телиме? Һәм сорауга җавап биргәндә өч факторны күздә тотсын: ире белән мөнәсәбәтләре яхшы, ул хатынын хөрмәт итә, ул гаиләне саклау өчен кулыннан килгәнне эшли. Бу арада ир дә күзәтә: ул яраткан, аңа кадерле булган кешеләрне яраткан хатыны ничек кабул итә, алар белән үзен ничек тота? Ә бала аның өчен кадерле, ул аның нәселен дәвам итүче. Хатыны баласы белән аралашырга бөтен мөмкинлекне тудырса, комачауламаса, киресенчә, ярдәм итеп торса, андый хатын ире каршында тагын да үсәчәк кенә. Без кешене яратабыз икән, ул бәхетле булсын өчен кулдан килгәнне эшлибез бит. Әгәр инде яратам дип йөреп тә, күбрәк үзебез турында уйлыйбыз, беренче урынга «мин»не куябыз икән, бу – «дефицит ярату». Ул невротик мөнәсәбәт тудыра. Андый гаиләдә ярату яши алмый – үлә.

PRESSA.RU



ҮЗЕНӘ ӨСТӘМӘ ЭШ УЙЛАП ТАБЫП ТОРГАН ТЫНГЫСЫЗ КҮҢЕЛЛЕ КЕШЕЛӘРГӘ СОКЛАНАМ МИН.

Югыйсә бар бит ул шул бер хөкүмәт эшендә эшләп, буш вакытын җитәкчеләрдән, акчасызлыктан, гаделсезлектән зарланып үткәрүчеләр дә. Һәм менә Нурзия ханым кебекләр дә бар. Үз вазыйфасын күңел биреп башкару өстенә: «Юк, бу гына аз әле ул, болай гына яшәргә тиеш түгел мин», – дип, һәрвакыт тагын бер адым алга омтылучылар.

Ризидә ГАСЫЙМОВА

БӘХЕТЛЕ ТӘРБИЯЧЕ

Без Нурзия Мирхазованың эш бүлмәсендә – Түбән Кама шәһәренең 39 нчы балалар бакчасында сөйләшеп утырабыз. Стена тулы дипломнар, альбомнар, күргәзмәләр, китап-журналлар... Дипломнар, дигәннән, «Атказанган укытучы» исемен дә алырга өлгергән икән бит инде ул! Нурзия ханым аяз күк йөзедәй җете зәңгәр күзләре белән балкып елмая да, бу уңайдан бер кызыклы тарих сөйләп китә.

– Бездән бит өйдә: «Дәрес әзерләдегезме?» – дип сораган кеше юк иде, – ди. – Мәктәптән кайтуга, өстәлдә әнинең безгә ниләр эшләргә кирәген язып калдырган запискасы тора... Сәгать тугызда, җитмәсә, авылда ут сүнә. Шуңа карамастан, дәрес әзерләмичә мәктәпкә бармаганбыз, «дүртле»гә, «бишле»гә укыганбыз, ә!

Шулай да бер мәртәбә дәрес әзерләмичә мәктәпкә барганым булды минем. Абый армиядән кайткан көнне сөенечтән аның белән клубка төшеп, физикадан дәрес әзерли алмадым. Ә физика укытучыбыз Хәмит абый (Нурзия Мамадыш районы Түбән Козгынчы авылыннан, мәктәпне Олыяз авылында тәмамлаган. – *Р. Г.*) шулкадәр таләпчән, кырыс кеше иде. Бүген әзерләнә алмадым әле мин, дип әйтергә дә кыен иде аңа. Кыскасы, бөтен класс алдында кызарып басып торырга туры килде.

Өйгә кайтуга, беренче эш итеп физиканы укырмын дигән идем, кая ул, абый янына иптәшләре җыелган. Аларга өстәл әзерләп, өстәл җыештырып, тагын көн үтте. Ә өченче көнне мәктәптән чыгуга ук, өйгә дә кайтып тормыйча, туры авыл китапханәсенә киттем. Эзләнә торгач, «Кызыклы физика» дигән китап табып алдым, шуннан дәреслектәге темага кагылышлы өстәмә мәгълүматлар табып, дәрескә шәп итеп әзерләндем. Һәм шулай ук җавап та бирдем! Көтеп торам шуннан «бишле»не. Ә Хәмит абый, беләсезме, нишләде?

– Беренче көнне шушылай сөйләгән булсаң, «бишле» куйган булыр идем, бүген инде – «өчле», – диде.

«Татарстанның атказанган укытучысы» исемен алгач, берзаман өйдә телефон шалтырый. Хәмит абый!

– «Ватаным Татарстан»нан исем алуың турында укыдым да, шалтыратып котларга булдым әле, – ди.

– И, Хәмит абый, – мин әйтәм, – ул исемдә сезнең дә өлешегез бар бит. Бүгенге эшне иртәгәгә калдырмаска сез өйрәттегез мине.

Бүгенге эшне иртәгәгә калдырмау... Гомер буе сиңа хезмәт итә торган сыйфат инде бу. Инде киресенә өйрәнсәң – гомер буе зарар китерә торган гадәт. Нурзия ханым татар төркемендә тәрбияче булып эшли башлаган 90 нчы елларда татар телендә методик әдәбият булмаган диярлек. Шөгыль үткәрү өчен, көн саен дигәндәй китапханәгә барып утырып, икешәр-өчәр сәгать материал тупларга туры килгән. Менә шул чакларда әзер кулланмаларын җыйнап барырга өйрәнгән ул. Һәм шушы ук бакчада өлкән тәрбияче-методист булып эшли башлагач, тәрбиячеләр өчен методик җыентыклар әзерли башлаган.

Беренче җыентыгы «Аналарга мәхәббәт тәрбияләү» исеме белән 2008 елда дөнья күргән. Билгеле, үз акчасына чыгарган. Әмма игелекле хезмәт барыбер бушка китмидер, күрәсең – бу хезмәт, «Милли мәгарифне үстерү өчен» шәһәркүләм бәйгесендә катнашып, грантка лаек булган. Бер ел үтүгә, икенче методик кулланма – «Минем Ватаным – Татарстан» җыентыгы нәшриятка тапшырылган. 2015 елда, Бөек Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан, әлеге китап өчен Нурзия ханым Татарстан Республикасы Ветераннар союзының Рәхмәт хаты белән бүләкләнгән. Бүгенге эшне иртәгәгә калдырмау димәктән, «Туган телем – Тукай теле» методик кулланмасы 2010 елда, Тукайның 125 еллык юбилее алдыннан тәрбиячеләр кулына барып ирешкән. Ә «Мин бәхетле гаиләм белән» дип исемләнгән җыентыгы...

– Кулъязманы Казанга министрлыкка илтеп биргән көн хәтеремдә әле, – дип сөйли Нурзия ханым. – Мөдиребезнең көтмәгәндә эштән китеп барган, минем вакытлыча аның вазыйфасын да башкарган чак бу. Бакча мөдирләрен ниндидер бәйрәмгә җыйган көнне мин, бәйрәмне калдырып, Казанга китеп бардым. Бердәнбер йомышым – шул кулъязманы илтү. Ә юлдагы буранны күрсәң! Казан урамында автобуслар рәтләп йөрми. Мәхшәр! Аллага шөкер, исән-имин барып та җиттем, хезмәтемне тапшырып, шул ук көнне Түбән Камага кайтып та кердем мин. Могҗиза дими ни дисең!

Могҗизалар моның белән генә дә бетмәде әле. Азмы-күпме вакыттан министрлыктан гриф бирелү турында хат алдым. Кулъязмам министрлык хисабына 2500 данә итеп бастырылып, республикадагы барлык бакчаларга да таратылачак икән. Сөенүләрем!

Нурзия ханым бүген, үз вазыйфасыннан тыш, милли юнәлештәге методистларны берләштергән шәһәркүләм методик берләшмә җитәкчесе булып та эшли. Шәһәркүләм генә түгел, регионара конференцияләр үткәрәләр, кыскасы, мәш киләләр алар! Менә тагын бер башлангычлары – татар балалар бакчалары арасында «Без – Тукай варислары» бәйгесе үткәрә башлаганнар. Бәйгене нәкъ менә балаларга кызыклы булырлык, ягъни заманча итеп оештырганнар. Катнашучылар Тукай иҗатына багышланган тамаша күрсәткәннәр, Лего конструктор ярдәмендә Тукай геройларын төзегәннәр, Тукай иҗатында чагылган табигать күренешләрен ясап алып килгәннәр. Бәйгене быел да үткәрергә җыеналар.

– Татар теле тирәсендә барган бу ыгы-зыгылар сезнең эшкә, балалар бакчаларындагы милли тәрбиягә зыян салмадымы? – дип кызыксынам мин.

– Беләсеңме, милли тема ул... һәр кешенең үзеннән тора бит, – дип җавап бирә Нурзия ханым. – Теләгәне аның элек тә эшли иде, хәзер дә җаен таба. Безнең бакчада, биш татар һәм биш рус төркеме бар. 90 нчы елларда да нәкъ шулай иде бу.

Әгәр тәрбияче-язучы дигән термин кулланып булса, Нурзия ханымга бу, һичшиксез, туры килер иде!

Теләү-теләмәү дигәннән, Нурзия ханымга берничә мәртәбә бакча мөдире вазыйфасы тәкъдим иткәннәр. Ул баш тартып килгән. Ни өчен дигәндә... Мөдирнең төп вазыйфасы хуҗалык эшләреннән гыйбарәт бит. Ә Нурзия ханымның исә күңелендә ут аның. Әнә бит, тагын бер кызыклы проект – «Сүздән энҗеләр тезеп» – турында сөйли әле ул. «Кама таңнары» әдәби берләшмәсенең 50 еллыгы уңаеннан мәктәпләрдә җирле каләм ияләре белән очрашулар оештыра башлаган икән. Бер карасаң, аның мәктәпләргә дә, әдәби берләшмәгә дә катнашы булмаска тиеш кебек – тик, урыс әйтмешли, не тут-то было! Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы һәм дүрт әдәби китап авторы да (ә методик җыентыкларын да исәпкә алсак, барлыгы – тугыз) ул бүген. «Бүләк» шигырьләр җыентыгы Татарстан Язучылар берлегенең Шәйхи Маннур исемендәге премиясенә лаек булган. Әдәби әсәрләре дә тәрбияви аның!

Нурзия ханымның «Ел тәрбиячесе», «Ел хатын-кызы» бәйгеләрендә катнашып, җиңүләр яулавы, министрлык оештырган «Инновацион технологияләр» номинациясендә I дәрәҗәле диплом белән бүләкләнүе, «Мәгариф» журналында бастырылган мәкаләсе өчен «Иң яхшы мәкалә авторы» дип танылуы, Ризаэтдин Фәхретдиннең юбилеена багышланган бәйгедә җиңүе һәм башка күп кенә җиңүләре турында мин, мөгаен, сөйләп тә тормам. Аның гаиләдә дә бәхетле булуын (күзем тимәсен!), Газизҗаны белән акыллы кызлар үстерүен, инде оныклар тәрбияләвен дә әйтеп торуның кирәге бар микән? Болар ничектер бер-берсенә бәйле кебек тоела миңа. Шәхси тормышы тәртиптә булган кеше, гадәттә, эшеннән дә ямь таба бит. Эшеннән ямь тапкан кеше өенә дә һәрвакыт тормышны (аның хәтта буранлы һәм яңгырлы көннәрен дә!) яраткан хәлдә кайта.


Бәхетең гомерлек булсын, Нурзия!

PRESSA.RU



«ӨЙ ҖЫЕШТЫРАСЫМ БАР...»

ӨЙ ҖЫЕШТЫРУ БУЛГАН, БАР ҺӘМ БУЛАЧАК – МОНЫСЫ ҮЗГӘРМИ, Ә МЕНӘ АНЫ ҖИҢЕЛӘЙТҮ ЮЛЛАРЫ, ЫСУЛЛАРЫ БАР, ДИЛӘР. КЫСКАСЫ, КЫЗЛАР, БЕЗ МОҢАРЧЫ ӨЙ ҖЫЕШТЫРА БЕЛМӘГӘНБЕЗ. КӨЛМӘГЕЗ, ЧЫНЛАП ӘЙТӘМ, ШАЯРТМЫЙМ.



«Өй жыештырасым бар...» Теләсә кайсы хатын-кыз телендә иң еш яңгырый торган җөмлә шушыдыр. (Хәер, юк, беренче урында: «Ашарга пешерәсем бар», – дип әйтү торадыр, монысы – икенче урында, димәк.) Атна арасында урыннан күчкән әйберләрне урнаштырасы, шкафларны тәртипкә саласы, урын-җирне алыштырасы, кер үтүклисе, тузаннарны сөртәсе, идәнне юасы, чәйнекләрне чистартасы, плитәне ялтыратасы, керләрне юарга саласы... Гомумиләштермичә, һәммәсен аерым-аерым тезеп саный башласаң, бу исемлек нинди булыр иде икән?! Әйтерсең лә без бу дөньяны тәртипкә салу – җыештыру өчен генә туган! Киногa бару, урманда йөреп кайту, башлаган китапны укып бетерү, дус кызлар белән очрашу... Өй җыештырмаганың искә төшә дә, күп вакыт боларның барысыннан баш тартасың. Гомер шулай узармы икәнни?!

...1999 елны Америкада яшәүче Марла Силли дигән бер хуҗабикә, үзләре яшәгән зур йортны җыештырырга берничек тә өлгерә алмый башлагач, Флай Леди дигән система уйлап чыгара. («FlyLady» – «очып кына йөрүче хуҗабикә» дигәнне аңлата.) «Буш вакыты калсын дисә, хатын-кыз эшләрен бик уйлап планлаштырырга тиеш», – ди ул. Ике көн ялны өй җыештыруга багышламаска, ә бу эшләрне атна арасындагы биш көнгә тигез итеп бүләргә тәкъдим итә. «Болай иткәндә җыештыруның авырлыгы сизелмәячәк, өйне тәртипкә салу рәхәтлек кенә бирәчәк», – дип ышандыра.

Чын фәнни хезмәт кебек үк, Флай Лединың да үз терминнары, кагыйдәләре бар.

«КАЙНАР НОКТА» – өйдә чүп-чар иң күп җыела торган урыннарны Марла Силли шулай атый. Өстәл, тумбочка өсләре, киштәләр... (Сезнеке ничектер, минем шунда ук улларым бүлмәсе күз алдыма килде. Ноутбук, буяулар, хәрефләр язылган кәгазь битләре, бетергеч, карандашлар, уку китаплары, дәфтәрләр... Мәктәп укучысы һәм каллиграфия белән мавыгучы дизайнер өстәле бу. Алар миңа атна саен беравыздан: «Безнең монда тәртип!» – дип исбатлыйлар. «Син, әнием, кайда нинди тәртипсезлек күрәсең?» – дип, икәүләп мине гаепләргә маташалар әле.) «Кайнар нокта»дан котылу юлы бер генә – кулыңа тоткан һәрнәрсәне соңыннан урынына кую. Моңа ирешү җиңел булмас, әмма аны гадәткә кертү өчен өйдәгеләрнең һәрдаим исләренә төшереп торырга кирәк, ди Марла.

«КӨНДӘЛЕК ЭШ» – Флай Лединың төп термины. Вакытыгыз тыгызмы-түгелмe, кәефегез бармыюкмы, атнаның башымы-ахырымы, урамда яңгырмыкармы – кыскасы, бернигә карамыйча өйдә көн дә башкара торган эшләр бар: урын җыю, чүп чыгару, аяк киемнәрен чистарту, ишек төбен сөртеп алу... Бу исемлеккә керүче эшләр – кичектерелергә дә, иртәгәсе көнгә дә күчәргә тиеш түгел. (Бервакыт бер танышым: «Балалар авылда, каникулда, җәй буе урын җыйганым юк. Нигә җыеп торырга, кич барыбер яңадан җәясе бит», – дигән иде. Алай уйласаң, аны бөтенләй җыеп торасы юк инде – көн дә йокларга ятабыз. Тик җыештырылмаган урын-җиргә кайтып керү бер дә күңелле түгел ләбаса.)

Аяктан егылып туктый торган «генераль уборка»лар башка булмаячак!

ЗОНАЛАР – өйне (фатирны) берничә зонага бүлеп, график буенча көн саен шуларның берсен җыештыру Флай Леди системасының бер кагыйдәсе. Әйтик, бер көнтә балалар бүлмәсен тәртипкә саласыз, икенче көнтә – ваннаны һәм туалетны. Аш бүлмәсен җыештыру минем, мәсәлән, һәрвакыт башкаларга караганда озагракка сузыла – аны, димәк, аерым зона итеп алырга кирәк. Көн саен шулай: әле бер почмакта, әле икенчесендә тәртип салып торгач, өй, гомумән, тузмаска тиеш.

ТАЙМЕР «Кайда инде монда вәгъдә ителгән җиңеллек, киресенчә, көн саен нидер эшләп торырга куша бит», – дип әйтәсегез киләдер инде, әйеме. Ашыкмагыз. Флай Лединың иң хикмәтле урынына җиттек. Марла Силли өй җыештыру белән көн саен 15 (!) минуттан артык шөгыльләнмәскә кирәк ди. Мавыгып китеп, артык эшләмәс өчен ул хәтта таймер-

БЕРНИЧӘ КИҢӘШ

■ өй җыештыруны, әйтик, компьютердан аерылып тору (һәркемнең үз мисалы: укытучы – планнардан, дәфтәрләрдән, бухгалтер – отчетлардан), ял итеп алу дип уйласаң, ул, чыннан да, рәхәт бирә торган бер эшкә әйләнәчәк. Уйларны тәртипкә салу өчен иң яхшы вакыт – шушы!

■ өйдә иң беренче ярдәмчеләр – балалар булырга тиеш. Үз урыннарын үзләре җыю, шкафларын тәртиптә тоту, тузан суырту – боларны алар көндәлек эш дип кабул итсен;

■ кер үтүкләгәндә телевизордан кино карасаң яки аудиокитап тыңласаң, эшең беткәнен сизми дә каласың;

■ аш бүлмәсендә кечкенә радиоалгыч сөйләп (җырлап) тору да, көндәлек эшләрдән армаска, ялыкмаска булыша кебек. Ил-көн вакыйгаларын белеп торырга, дөньядан артта калмаска да ярдәм итә. (Ә телевизордан мин үзем теләп баш тарттым – ул игътибарны читкә юнәлтә дип саныйм.)

■ вакытны күп алмый торган эшләрне, «аннары»га калдырмыйча, шунда ук эшләп куярга гадәтләнергә кирәк.

Фото: www.pixabay

PRESSA.RU

дан файдаланырга киңәш итә. Хәер, вакытны һәркем үзенә-үзе билгеләргә тиештер: кемдер аны ярты сәгатькә кадәр сузса, берәүгә 10 минут та җитәргә мөмкин. Иң мөһиме: үзең өчен шушы вакытны ачыкларга да, аны көндәлек кагыйдә итәргә. Марлага, әлбәттә, җиңелрәк, ул бит хуҗабикә булып өйдә генә тора. Безнең арада исә андыйлар сирәк. Әмма кайда гына эшләсәң дә, кичен 15-20 минутны табарга буладыр инде ул. Теләк кенә кирәк!

Җыештыру, юу, чистарту өчен өйнең тузганын, көнкүреш техникасының пычранганын көтмибез.

РАКОВИНА Төп кагыйдәләрнең тагын берсе – раковина һәрвакыт ялт итеп торырга тиеш. «Аннары юармын әле», – дип, тау-тау савыт-саба җыюны онытыгыз: Флай Леди системасы буенча яши башлагач, без аны хәзер табын яныннан торуга юып куярга, машиналылар машинага салырга тиеш булабыз. (Хәер, монысына безне кечкенәдән өйрәттеләр, «Җыештырылмаган табын өстенә фәрештәләр канатларын җәеп тора – ардырмагыз аларны», – диләр иде.) Савыт-сабаны юып бетергәч, мин, гадәттә, үземнең уйларымда, күңелемдә – бар дөньямда да тәртип урнаштырган кебек тоям. Хәер, күп хатын-кызлар кичерә бугай бу халәтне.

АРТЫК ӘЙБЕРЛӘР Язманың ахырына җиткәч, журналны читкә куеп торып, үзегезнең өй эченә күз салырсыз әле. Һич кирәге булмаган әйберләр сездә дә шулай күпме ул? Өй җыйган саен шуларның тузанын сөртү генә дә никадәр вакытны ала! Кайчандыр бүләк иткән сувенирлар, йөрми торган сәгать, сыңар чынаяк, сервиздан калган тәлинкә... Ә шкаф ишекләрен ачсаң?! Аш бүлмәсенә чыксаң?! (Карагыз әле, пыяла банкаларны без, хатын-кызлар, нигә шулай яратып җыябыз икән ул? Беребез дә консерв заводы ачарга җыенмый югыйсә. Элеккеге кебек кышка салатлар ябу гадәте дә бетте. Ә банкаларның гел кирәге чыгар кебек – ташларга кул бармый. Пыяла савытларны да аерым җыюны оештырмасалар, бу гадәттән котылып булмастыр инде ул.)

Әйбер азрак булган саен, өй чистарак, аны тәртиптә тоту җиңелрәк булачак. Менә шуның өчен дә Марла Силли көн саен өй эчендәге кирәкмәгән 27 (!) әйбердән котылырга кирәк ди. (Кызык өчен генә эзләп карагыз – андый вак-төяк, һичшиксез, табылачак!) Барысын да ташларга димәгән: укыган китапларны таратырга, үзегез инде кимәгән кием-салымны мохтаҗларга бирергә мөмкин.

ЖУРНАЛ Өйдәге бөтен эшләр исемлеге язылган махсус дәфтәр дә алып барырга куша Марла – эшне, вакытны тигез бүлү өчен кирәк бу. Җыештыру графигы, аласы әйберләр исемлеге дә шушында языла, кирәкле телефоннар да. («Тагын бер өстәмә эш нәрсәгә – алар болай да башта бит инде», – диючеләргә бу журналның, мөгаен, кирәге дә булмаска мөмкин.)

ҮЗЕҢНЕ ОНЫТМА! Үзеңне ярату, үзең өчен вакыт табу, үзеңне сөендерү... Флай Лединың төп законнарының берсе бу. Иң элек үзеңне кара, үзеңне тәртипкә сал! Прическа, макияж, маникюр... Син өйдә һәрвакыт берничә минуттан кунаклар килеп керүен көткән кебек киенеп йөрергә тиеш, ди ул.

Гөлнур ХӘСӘНШИНА

КИҢӘШ

«Соңгы тапкыр җыештырган кебек җыештыру». Исеме, әлбәттә, сәеррәк, хәтта куркынычрак яңгырый. Бу ысулны безгә шведлар тәкъдим итә. Дөресрәге, швед рәссамы Маргарет Магнуссен. Сиксән яшен тутырган бу ханым: «Күбебез тирә-юнебезгә, өебезгә – үзебезне чорнап алган әйберләргә игътибар да итмичә яши. Өсте-өстенә һаман нидер ала, җыя... Ә кинәт – менә бүген бөтенләйгә күзебезне йомсак, безнең бу әйберләребез белән ни буласын беребез дә уйламый, – ди ул. – Бездән соң калучыларга алар кирәк булырмы? Чүпкә генә чыгарып ташларлармы, яндырырлармы – нишләтерләр? Өй эче вак-төяк, иске-москы белән тулып торганда, алар арасыннан безнең хатирә, истәлек булып сакларлыгын аерып ала алырлармы?» «Соңгы тапкыр җыештырган кебек җыештыру»ның кагыйдәләре нибары җидәү.

1. Бу концепция 50 яшьтән яшьрәкләргә дә туры килә. Кайсы әйбернең безнең күңелдә рәхәт хатирәләр уятканын, ә кайсысының ташларга кызганыч булган өчен генә торганын аңлау өчен чәчләргә чал кергән булуы мәҗбүри түгел бит.

2. Мондый җыештыру гадәти тузан сөртүдән, шкафларны тәртипкә салудан аерыла – ул бөтен тормышыңны күз алдыннан уздыру кебек. Шуңа күрә аны ашыкмый, кабаланмый эшләргә кирәк.

3. Әйтегез – якыннарыгыз нинди эш белән шөгыльләнгәнегезне белсен: бу сезгә ярты юлда туктап калмаска ярдәм итәчәк.

4. Кайчандыр сез бу әйберләрне (китаплар, уенчыклар) кирәккә сатып алгансыз: кемдер өчен алар хәзер дә кирәк булырга мөмкин – таратыгыз. Аларны бүләк итү сезгә шатлык бирәчәк.

5. Җыештыруны шкафлардан башлагыз: кием-салымнан без җиңелрәк аерылабыз ди Магнуссен.

6. Тормышка нокта кую түгел бу җыештыру – үзең өчен нәрсәләр мөһимрәк булуын ачыклау гына.

7. Өйнең бер өлешен тәртипкә салган саен, үзегезгә бүләк ясарга онытмагыз: матур маникюр ясатырга, театр-концертка барып кайтырга, кафега кереп утырырга...

КӨНБАГЫШ – УЛ...

Көнбагыш ул – балачак тәме, капка төбендә утырулар, ил-көн яңалыклары турында сөйләшүләр. Шуңа бәйле рәвештә, туганнар һәм дуслар арасындагы дустанә мөнәсәбәтләр балачак хатирәләре турындагы кыскаметражлы фильмдагы кебек чагыла. Ни гаҗәп, көнбагыш әнә шулай өй, җылылык символы булып тора.

Шактый еллар инде Европада яшәүче классташым белән күрешеп, яшьлек елларын искә төшереп утырдык берчак. «Көнбагыш чиертеп утыруларны сагындым. Монда кабыгыннан чистартылганнарын гына саталар бит. Бер тәме, бер ләззәте юк. Кайту белән көнбагыш сатып алачакмын», – ди.

Кышкы озын кичләрдә өйдә утырганда йә җәйләрен табигатькә чыкканда, дус-иш җыелган җирдә йә берүзебез генә калгач та и көнбагыш чиертеп утырырга яратабыз соң! Аның телләрне йотарлык тәме һаман тел очында. Тикмәгә генә Россия көнбагыш үстерү буенча иң алга киткән ил исәпләнми шул. Бу кыйммәтле продуктның ни өчен популяр булуы да аңлашыла. Эре, әйбәтләп кыздырылган, хуш ис аңкып торган көнбагыш теләсә кайчан теләсә кемгә ошый. Өйдә рәхәт бер мохиттә көнбагыш чиртә-чиртә сериаллар, яңалыклар, мультфильмнар карыйсың. Кәеф күтәрелә, тормыш мәшәкатьләрен дә тынычрак, җиңелрәк уткәрәсең.

Көнбагыш төшендә организм өчен кыйммәт булган кирәкле элементлар күп. Һәр төштәге 80 процент майның нибары 20 проценты гына туендырылган. Көнбагыш төше составында матурлык һәм яшьлек өчен мөһим компонентлар тупланган. 100 грамм продуктта тире, чәчләр, йөрәк һәм кан тамырлары өчен кирәк булган бар матдәләр дә җитәрлек. Болардан тыш, көнбагыш төшендә эчәкләр эшчәнлеген яхшырта торган үсемлек күзәнәкләре (клетчатка) бар.

КӨНБАГЫШКА РЕКЛАМА КИРӘКМИ!

Безнең бабаларыбызга көнбагыш XVIII гасырдан ук таныш. Ул заманнарда теләсә кайчан, теләсә кайда көнбагыш ашау гадәте булган. Ял иткәндә, кичке уеннарда, су буенда, көнбагыш чиертә-чиертә, кызлар егет сайлаган. Шул чорлардан сынамышлар да калган. Мәсәлән, ялгыш чәчелеп киткән көнбагышны көтелмәгән керемгә йә бәхетле мәхәббәткә юраганнар. Нидерландның атаклы рәссамы Винсент Ван Гог көнбагышны хәтта культ дәрәҗәсенә күтәргән. Көнбагыш темасы иҗатта бүген дә актуаль.

«Лакомка» компаниясе кыздырылган һәм чи көнбагыш төшләрен төргәкләп җитештерү белән шөгыльләнә.

Бүген «Лакомка» көнбагышлары Россия Федерациясенең күп төбәкләрендә уңышлы сатыла. Компания киләчәктә үз продукциясен чит илләр базарына да чыгарырга планлаштыра.

Тәмле көнбагышны ничек сатып алырга? Моңарчы аның сыйфатлысын табу бер дә җиңел түгел иде. Матур капларга кайчак ачы, күгәргән, бурсыганы да эләгә, чүп-чарлы була. Андый көнбагыштан куллар пычрана. Шуңа күрә сыйфатлы көнбагышны белгән җитештерүчеләрдән сатып алырга кирәк. «Лакомка» белгечләре Россиянең төрле төбәкләрендәге әлеге төр авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүчеләр янына үзләре барып, таләпләргә җавап бирерлек көнбагышның сыйфаты, уңышның ни дәрәҗәдә буласы турында алдан ук мәгълүмат алалар. «Лакомка» көнбагышлары югары сыйфаты һәм алыштыргысыз тәме белән аерылып тора. Чималны кайтартканнан соң, сатып алучы кулына кергәнче, көнбагыш Германия һәм Италиядә җитештерелгән җиһазларда безнең сыйфат стандартларына җавап бирерлек дәрәҗәдә күп тапкырлар чистартыла, сортларга аерыла. Аннары Россиядә җитештерелгән электр һәм газ мичләрендә көнбагышны кыздыралар. Кыздырылганнан соң көнбагыш, чистарту процедурасы аша узып, «Русская трапеза» аппаратлары белән җиһазланган фасовкалау линиясенә күчә. Искиткеч тәмле һәм сыйфатлы көнбагыш менә шулай безнең өстәлләргә килеп керә.

Без, гадәттә, көнбагышның 40-42+ фракцияле «Лакомка» һәм «Посейдон» сортларын, ә «Лакомка Элитная» өчен 45+ ны файдаланабыз. Гади көнбагыш белән беррәттән, кыздырылган көнбагышның арахис белән кушылганын капларда тәкъдим итәбез. Аңа кадәр әле «Лакомка» продукциясе өчен көнбагыш бик җентекле экологик һәм технологик контроль аша уза: калибрлана, юыла һәм аппараттан уздырыла.

Өч катламлы полимер пленкага төрелгән продуктка әйләнә-тирә мохит берничек тә тәэсир итә алмый, куллану вакыты чыкканчы көнбагыш тәмен һәм хуш исен югалтмый саклый.

Озак еллар хезмәттәшлек иткән партнерлар «Лакомка» көнбагышын югары бәяли. Сатып алучылар фикере безнең өчен кыйммәт, без алар куйган таләпләргә туры килерлек продукция чыгарырга тырышабыз.

СЕМЕЧКИ «ЛАКОМКА»

ЛАКОМКА

ЮРИДИЧЕСКИЙ АДРЕС: 430030, РЕСПУБЛИКА МОРДОВИЯ,
Г. САРАНСК, УЛ. БОЛДИНА, Д. 25
АДРЕС ПРОИЗВОДСТВА: 431614, РЕСПУБЛИКА МОРДОВИЯ,
РОМОДАНОВСКИЙ РАЙОН, С. БЕЛОЗЕРЬЕ, УЛ.МАСТЕРСКАЯ, Д. 1Д
www.lakomo4ka.ru
e-mail: mail@lakomo4ka.ru

РЕКЛАМА

PRESSA.RU

– «Нигә нәкъ менә ул, башка якыннарың түгел?» – дип кызыксынучыларга, «Хатынымны бик яраттым, шуңа мәчеткә аның исемен кушам», – дим... «Мөслимә» исемле булачак ул... Әңгәмәбез әледән-әле, нәрсәгәдер килеп төртелгәндәй, туктап кала. Икебезгә дә бик читен: миңа – сораулар бирергә, аңа – ул сорауларга җавап кайтарырга. Яралары әле шундый яңа бит...



Фото: Ксения Богданова

КИЛӘБЕЗ ДӘ КИТЕП ЮГАЛАБЫЗ...

«Чәйне җиләк кайнатмасы белән эчегез... Мөслимә кайнаткан кура җиләкләре... Тагын бар әле...»

Аның кулы кагылган әйберләр, ул кигән киемнәр, ул утырткан гөлләр... Хәер, ул үзе дә каядыр шушында гына кебек – күп бүлмәле иркен йортларының кайсыдыр бер бүлмәсеннән килеп чыгар сыман. Килеп чыгар да сүзебезгә кушылыр... Әллә елмаеп, иренең сүзен генә җөпләп утырыр идеме икән? «Хатыным күп сөйләшми иде», – ди бит Мирсәет.

...Мирсәет аңа сигезенче сыйныфта укыганда ук гашыйк була. Ул – аның беренче мәхәббәте. Егет тә кызның беренче якын иткән, күңел түренә үткәргән кешесе. Тәүге яраткан ярлар белән гомерлеккә сирәкләр генә кавыша – алар исә менә шундый бәхетле парлардан.

Биш параллель сыйныф була ул чакта Шыгырдан урта мәктәбендә. Һәрберсендә утыздан артык укучы! Берсендә ике сыйныфның танышу, дуслашу кичәсен үткәрәләр. Тугызынчыда укыган чаклары. Ниһаять, чынлап торып танышырга, Мөслимәнең янына барып сүз дәшәргә җай чыга. Шул көннән соң алар очраша башлыйлар. Очрашу дип... Авылның язылмаган үз кагыйдәләре инде аның: мәктәптә бер-береңә сиздер-

мичә генә күз салып йөрисең, атнага бер тапкыр клубтан озата кайтасың. Егетнең кинәт үзгәреп, җитдиләнеп киткән елы ул: яраткан кызың булгач, мәктәптә элеккечә шукланып йөри алмыйсың шул инде...

Мәктәпне тәмамлагач, юллар беразга аерылып тора: Мөслимә – Чабаксар политехника институтына укырга керә, Мирсәет – Казан дәүләт педагогика институтына имтиханнар тапшыра. Юллар аерыла, тик күңелләр түгел!

– Мин башка бер кыз артыннан да бармадым...

Ике араны ул чакта хатлар бәйләп тора, аннан инде – авылга кайткан чакларда булган сирәк кенә очрашулар. Физкультура факультетында укыган Мирсәетнең студент еллары спорт секцияләрендә уза. (Көрәшче егет бит ул! Ике тапкыр Россия чемпионатында җиңү яулаган, бер тапкыр Татарстанда узган бәйгедә җиңүче булып калган. Көрәш буенча спорт мастеры дигән мактаулы исеме бар.)

Яшь белгечләр икесе дә Татарстанның Чүпрәле районына эшкә кайталар. Берсе – Чынлы элеваторына бухгалтер, икенчесе Чынлы урта мәктәбенә физкультура укытучысы булып. Мирсәет мәктәптә өч ел гына эшләп калырга өлгерә. Миңзифа һәм Миңтаһир Купкеновлар гаиләсенә бер-бер артлы ике зур хәсрәт килә ул чакта: башта юл фаҗигасенә очрап төпчек уллары Фәритнең гомере вакытсыз өзелә, аннары бала тапканда кызлары Миндания үлеп китә. Мирсәеткә шулай итеп Шыгырданга – әтиәнисе янына кайтырга туры килә.

– Өйләнгәч, туйлар уздыргач, үз эшемә тотындым... Безнең монда тәртип шулай инде – мин дә базарда ит саттым.

Әнә аларның туй фотолары: икесе дә шундый бәхетлеләр! Очрашып йөрүләренең азагы кавышу белән тәмамланачагы күптән көн кебек билгеле була, әлбәттә. Туй үткәрергә дигән акчаны үзләре эшләп туплыйлар. 1990 елның 30 декабрендә Мирсәет төп нигезгә килен төшерә.

Күпләр беләдер: Шыгырдан хатыннарының язмышлары үзгә аларның. Бу авылда гомер-гомергә ирләр акчаны читкә китеп эшли, ә йорт-җирне, көнкүрешне алып бару, балалар үстерү – хатыннар өстендә. Читтән караганда алып кайткан малны урнаштырып яшәү генә булып тоелса да, җиңел тормыш түгел бу. «Безнекеләр шуңа да күбрәк үзебезнең авылларга өйләнергә тырыша», – дип юкка гына әйтми Мирсәет тә. Шыгырданда үскән кызлар өчен әниләре узган юлны узу бу. Сабыр булырга, күңелгә шикләр кертмәскә, кеше сүзенә колак салмаска, көтә белергә алар яшьтән өйрәнеп үсә.

Мирсәет белән Мөслимә егерме дүрт ел бергә яшәп калганнар. «Читкә китеп эшли башлаганыгызга ничә ел?» – дигән сорауга да гаилә башлыгы: «Егерме дүрт ел», – дип җавап бирә. Туйлар узуга, абыйсы белән икәү акча эшләргә дип чыгып китә алар. Хатыннары, әлбәттә, төп йортта, кайната-кайнана янында яши.

– Аннары йорт салыр өчен җир алдык, – дип сөйли Мирсәет. – Бу урамга иң беренче без күчендек. Килә идек тә Мөслимә белән төнгә чаклы шушында казына идек: йортның нигезләрен икәү салдык, күтәрүен – өмә белән инде... Кадак та, такта да, кирпеч тә юк заманнар бит әле. Ел ярым дигәндә башка чыктык. Икенче кызыбызны көтә идек инде. Бала тудыру йорты юл аша гына бит. Вакыты җиткәч: «Ярый, мин киттем», – дип, Мөслимә үзе кереп китә иде. Тагын ике елдан кереп, улыбызны да шулай гына алып чыкты.

Ландыш, Ләйсән, Илназ... Дөнья шулай түгәрәкләнә. Балалар тугач, ире Мөслимәне башка эшләтми инде. «Хатын-кызның мәшәкате йорт эчендә дә җитәрлек», – дип саный Шыгырдан ирләре.

– Матур яшәдек без... Көнгә биш-алты тапкыр сөйләшеп ала идек. Мөслимә минем кая барганымны, кайчан кайтканымны белеп торды. Әлмәттә эш килеп чыккач та, башта аның белән киңәштем. «Әйбәт эш икән, барырга кирәк», – диде ул. Егерме елдан артык Татарстанда мин хәзер, Әлмәттә төзелеш эшләре белән шөгыльләнәм. Районның «Урсала» хуҗалыгында җирләрем дә бар. Кул астымда кырыктан артык кеше. Игътибар иткән булсагыз, Шыгырданда күпләрнең капка төбендә торган машиналарында Татарстан номерлары – без барыбыз да анда эшлибез. Миңнехановны да үзебезнең Президент дип саныйбыз. Әйе, читтә эшлибез, әмма авылны, нигезләрне дә ташламыйбыз. Әлмәт белән ике араны инде күптән ерак-ка санамыйм – гомер буе атна саен диярлек кайтып йөрим бит. Комсомольскига җиткәч, Мөслимәгә шалтырата идем: «Чәеңне куй, тиздән кайтам!..»

Без беркайчан сүзгә килмәдек – ачуланышырга сәбәп тә булмады.

Ике ел элек, операция ясатырга дип, Мирсәет хатынын Әлмәткә алып китә. Операция, әлбәттә, катлаулы – йөрәккә ясалырга тиеш, әмма борчылыр өчен сәбәпләр юк шикелле: Мөслимәне иң яхшы хирурглар кулына тапшыра ул. Әмма соңгы әзерлекләр барганда көтелмәгән хәл килеп чыга. Мирсәетне сырхауханәгә чакыртып алалар һәм шушы хәбәрне җиткерәләр: «Хатыныгызның башында яман шеш. Соңгы стадия...»

– Өеңә алып кайт инде син аны, – ди таныш табибы. – Тагын ике атна гомере бар...

Мөслимәнең соңгы вакытта кинәт ябыгуы, тамакка нәзберекләнүенең сәбәбе шулай ачыла. Ә ул аны пычак астына ятасы булганга шулай борчыла дип белә.

Ике атна... Бик-бик кыска һәм өметнең үзе кебек озын ике атна була ул. Бер карасаң, шушы санаулы көннәр эчендә Мирсәет әллә ниләр эшләргә өлгерә: Германиядә, Израильдә шушындый яман шешләрне дәвалаучы клиникаларны эзләп таба, алар белән элемтәгә керә, хатынының кәгазьләрен юллый һәм... «Юк, кабул итә алмыйбыз, соңга калгансыз», – дигән җаваплар ала. Мөслимәне Чуашстандагы

PRESSA.RU



онкология үзәгенең иң яхшы табибына күрсәтә, ул да: «Җылы сүз әйтеп куандыра алмыйм сезне», – ди. Күңел барыбер ышанырга теләми! Суга батучы саламга ябышкандай, багучылар ишеген кага: «И-и, улым, – дип елый үзбәк апасы, – минем ярдәмнән узган – үлем күрәм... Матур яшәвегездән, малыңнан көнләшүчеләр булган шул...»

Безне: «Кеше малына тимәгез, урламагыз», – дип үстерделәр.

Ике атна Мирсәет хатыны янынннан бер адымга да китми.

– Шылт иткән тавыш булса да, сикереп торып, янына барам... Сулыймы икән дип тыңлыйм. Эчем – ут, тышым – ут... Урамга бер чыгам, бер керәм. «Минем хатыным үлә», – дип кешеләргә әйтеп булмый бит... Ничә сорасам да: «Юк, бер җирем дә авыртмый», – диде ул. Сызланмасын дип, уколларны гел салып тордык. Минем үзе өчен ничек тырышканымны күреп ятты бит, шуңа күрә, «бу миңа ярдәм итә инде, терелләм», дип уйлады. Үзенә куелган диагнозны белмәде. Илле яшен яңа үткәргән идек. Юбилей уздырырга да теләмәде – күбрәк мин тырыштым. Котлаулар кабул итәргә, игътибар үзәгендә булырга яратмый иде ул. Кешегә кушылып кеше сөйләмәде, гайбәтләрдән ерак торды. Балаларны тәрбияләде. Өй, балалар дип яшәде. Мин аны диңгезгә ялга барырга да бер тапкыр ризалата алмадым. Мөслимә өстендә күпме мәшәкать булганлыгын хәзер барысы да үземә калгач кына аңладым...

Ике атна дигән табиблар бер көнгә дә ялгышмыйлар...

Хатынын гүргә иңдергәннең икенче көнендә үк Мирсәет хәзрәт янына бара: «Авылда мәчет төзергә телим». Мондый уе күптән була аның – сәгате генә хәзер суга. Шыгырданның халык телендә «Рублевка» дип йөрткән очыннан мәчет салыр өчен урын бирәләр аңа. Шунда ук төзелеш башлана...

Төп-төз наратлардан салынган ике катлы бу агач мәчет инде әзер диярлек. Янында шундый ук нараттан тәһарәтханә салынган, шунда ук мәет юу бүлмәсе дә бар (анысы – туганнарын читтән алып кайтып җирләүчеләр өчен). Мәчеткә килүчеләр «Фәрит» капкасы аша керәчәк, «Миңтаһир кое»сы яныннан узачак, никахка җыелучылар «Миндания» кунакханәсендә чәй табыны кора алачак, ә мәчет үзе, әйткәнемчә, «Мөслимә» исемен йөртәчәк... Мирсәетнең иң-иң якын кешеләре – энесе, әтисе, апасы, хатыны...

– Ике ел инде шушы мәчет белән генә яшим... Бирегә килсәм, җаныма бер юаныч, тынычлык табам. Бер ел дигәндә аен куйдык. Бик күп итеп агачлар утырттык. Янәшәдәге мәчетне күрәсезме? Йөз егерме ел аңа. Батырдан күчереп салганнар иде. Башта мәчет булып торды, аннан – мәдрәсә. Шушында ишегалдына урнаштырып, анда музей оештырырга җыенам.

Мәчет салырга керешкәннән бирле барлык эшләрем җайлы бара, көтмәгән җирдән акчалар керә. Әнинең туган көнендә – быел аңа сиксән тула – бирегә беренче азан яңгырар дип торам. Авылның остабикәсе безнең әни. Хаҗия ул – Ходайга мең шөкер, биш ел элек аңа шундый бүләк ясый алдым... Төзеп бетерәм дә, мәчетнең ачкычын мәхәллә кулына тапшырам – мулланы алар сайлар. Аллаһ йорты минеке була алмый – мин аны төзүдә сәбәпче генә... Материалларның иң яхшыларын алырга тырыштым. Күпмегә төшкәнен санаганым юк – зәкятем булсын дим. Барыбыз да Аллаһы Тәгалә юлында йөрибез, «мин булдырдым, мин таптым», дия алмыйбыз – ул бирсә генә булдырабыз, табабыз. Шөкер, уразаны мәктәптә укыганда ук тота идем инде, намазга күптән өйрәндем. Малны эшләп табам. Хөкүмәттән бер тапкыр да кредит алганым булмады. Гомер буе эчмәдем, тартмадым. Кем ярдәм сорап килсә дә, булышырга тырыштым...

...Көтелмәгәндә килгән югалту белән килешер өчен ике ел бик аз вакыт әле. (Хәер, йөрәккә кадалган соңгы чыра биш елдан, ун елдан соң да шулай ук әрнер инде ул.) Бикле ишеккә кайтып керү авыр. Киткәндә озатып чыгучы булмавы – аннан да авыррак. Балалар күзендә яшь кипмәвен күрү... Гомернең кыскалыгын тою... Сагыну... Аның кебек башка берәү инде табылмаячагын аңлау...

– Моңарчы бит гел дөнья кудык, тын алырга вакыт булмады... Хәзер менә уйландыра. Якыннар, туганнар, дуслар кадере турында. Шөкер, дусларым күп минем. Азнакай районы башлыгы Марсель Зөфәр улы Шәйдуллин белән күп еллардан бирле бер-беребезне беләбез. Бу авыр көннәрдә, рәхмәт, ул һәм аның гаиләсе иң зур таянычым булды... Миңа хәзер балаларымны башлы-күзле итү, урнаштыру кирәк – иң зур бурычым шул. Үзем турында уйламыйм...

Юлда йөргәндә кайчак, онытылып китеп, элеккегә гадәт буенча: «Хатынга шалтыратып алыйм әле», – дип телефонга үреләм. Аның инде юклыгы исемә төшә дә туктап калам. Телефонын сүндергәнем юк... Безнең тәкъдир шулай булган инде...

...Әйе, тәкъдирләргә шулай язылган: киләбез дә, аннан бер көн китеп югалабыз. Үзебездән соң җирдә ниләр калдырабыз? Игелекле гамәлләр, якты хатирәләр, матур эзләр... «Мөслимә» мәчетеннән Шыгырдан өстендә көнгә биш тапкыр яңгыраячак азан тавышы шушылар хакында да сөйләр, мөгаен.

Гөлнур САФИУЛЛИНА

СЕРЕҢӘ ХУҖА БУЛ



Илнар хәзрәт ЗИННӘТУЛЛИН, «Туган авылым» мәчете имам-хатыйбы

Илаһи ният кылдым

Нинди серләреңне, гомумән, берәүгә дә сөйләргә ярамый?

– Шундый мәкаль бар: «Әгәр берәр сүзне үзеңдә тотсаң, ул сүзгә – син хуҗа. Ә аны кемгәдер әйтү белән, ул сүз – сиңа хуҗа». Шуның өчен, мөмкин булганча, азрак сөйләшергә кирәк, бу – ислам динендәге кагыйдәләрнең берсе. Пәйгамбәребез әйтә: «Кеше Аллаһы Тәгаләгә иман китерсә, ул яхшы сүз генә сөйләр, яхшы сүз булмаса, бөтенләй сөйләмәс», – ди.

Яхшы сүзгә нәрсә керә? Кешене яхшылыкка чакыру, начарлыктан тыю, Аллаһы Тәгаләне искә алу, аралары бозылган ике кешене дуслаштырырга тырышу.

Инде нинди серләрне сөйләргә ярый, кайсын ярамый дигән сорауга кайтыйк. Гомумән алганда, бер серне дә сөйләргә ярамый. Киңәш кирәк булган очракта гына, кем янынадыр килеп, бу хакта сүз башлый аласың. Әмма киңәшне дә теләсә кемнән түгел, бары акыллы кешедән сорарга кирәк. (Әгәр ул сиңа киңәш бирә алмый икән, аңа сөйләүдән ни мәгънә?) Бигрәк тә гайбәтчедән, сүз йөртүчедән сакланырга кирәк. Кайвакыт киңәшне чит кешедән сорау хәерлерәк тә: ул синең кем икәнеңне белми, шуңа күрә зыян сала алмый.

Күңел бушату дигән нәрсә бар. Моның өчен бер якын дустыңны сайларга кирәк. Сез инде бергә ниндидер сынаулар аша үткән ышанычлы кешең булырга тиеш ул. Аңа күңелне бушатырга ярыймы-юкмы дип сынап карыйсың килсә, башта мөһим булмаган бер сүзеңне әйтеп кара. Әгәр ул сүз кешегә чыга икән, димәк, бу дуска ышанып булмый – бүтән аңа сереңне сөйләп йөрмә.

Ә «ахирәт дус» диюнең мәгънәсе киңрәк аның. Бу дөньяда да, теге дөньяда да дус булу дигән сүз ул. Бүген якын булган бөтен кеше анда баргач та дус булачак дип әйтеп булмый. Мәсәлән, бу дөньяда ике кеше бик дус, ди. Алар бер-берсенә кунакка йөриләр, яхшысын да бергә эшлиләр, начарын да... Теге дөньяга баргач, берсеннән: «Син бу эшне нәрсәгә эшләдең?» – дип сорыйлар. «Әнә теге дустым кушканга», – ди ул. Ә тегесе: «Нишләп кушыйм инде мин сиңа? Үзең мине ияртеп бардың», – ди. Шулай итеп, алар дошманга әйләнә. Бергә гөнаһ кылган кешеләр теге дөньяда дус булмыйлар. Хәтта, тәмугка кергәч, бер-берсенә күбрәк җәза сорыйлар.

Динне белгән, Аллаһыны таныган кеше генә синең сереңне саклый, бернәрсә өмет итмичә, ул гына сиңа булыша. Пәйгамбәребез әйтә, дустыңның риясыз кешеме-түгелме икәнен сынар өчен аңа акча биреп тор, ди. Йә булмаса, аның белән берәр кая сәфәргә чык, күрше булып яшәп кара. Ә бер хикмәтле кеше болай дип киңәш бирә. Дустыңны сыныйсың килсә, аш үткәр, мәҗлес җый, әмма аны чакырма, ди. Әгәр ул сиңа үпкәләмәсә, бер сүз дә әйтмәсә, тагын бер тапкыр аш үткәр – күршесен чакыр, үзен чакырма. Әгәр шуннан соң да һаман бер сүз әйтмәсә, дустың булып калса – ул чын дус, аннан аерылма, ди. Дөрес бит, без хәзер күпләрне кунакка, чакырасы килеп түгел, үпкәләмәсен дип дәшәбез. Хуҗа Насретдинның: «Казаның кайнап торганда, табының тулы кеше булыр», – дигәнен онытабыз.

Әйе, чын дус ул синнән бернәрсә өмет итми. Шуңа да аңа күңелеңне бушатырга була. Әгәр андый дустың юк икән, күңелеңне Аллага гына бушат. Пәйгамбәребез: «Әгәр дә синең берәр борчумәшәкатең килеп чыгып, аны беркемгә әйтмичә, Аллаһы Тәгаләгә генә сөйләсәң, ул сиңа булышачак», – ди.

– Кеше серен саклау савапмы?

– Сиңа берәү серен сөйләгән икән – бу сүзне оныт. Бу синең сүзең дә, синең сереңдә түгел һәм ул бары тик синең үзеңә генә әйтелгән, шуңа күрә аны беркемгә сөйләргә хакың юк. Пәйгамбәребез: «Әгәр бер кеше сүзен сөйләгәндә, як-ягына каранып: «Әйдә әле читкәрәк», – дип сине алып китсә, аның сөйләгән бу сүзе – әманәт», – ди. (Әманәт – ул сиңа ышанып тапшырылган эш, гамәл һәм аны ахырга кадәр үтәргә тиешсең.) Ә бөтен кеше янында, башкалар да ишетерлек итеп әйтелсә, димәк, бу сүз инде сер түгел – аны сөйләсәң дә зыяны булмый.

Кешенең серен саклау – башкаларның малын саклау кебек үк җаваплы гамәл.

– Ә үзеңә ышанып тапшырылган серне түзмичә кемгәдер чишсәң?

– Кешегә кагыла торган сүз булса, ул, гомумән, гайбәткә керә, һәм аны Аллаһы Тәгалә гафу итми. Дөресрәге, теге кешедән, барып, кичерү сорамыйча, ул сине гафу итми. Кайвакыт кеше турында нидер сөйлибез – ул моны үзе белми дә кала, ләкин бу гөнаһ кичерелсен өчен син ул кеше янына барып гафу үтенергә, аның каршында гаебеңне танырга тиешсең. Алайса без җиңел юл таптык – сөйлибез-сөйлибез дә: «И-и, Аллаһы гафу итсен инде», – дип куябыз. Гөнаһларның Аллаһы Тәгалә гафу итә торганнары һәм гафу итми торганнары бар. Әгәр гөнаһың кеше белән бәйле икән, ул аны гафу итми. Мәсәлән, бурычка акча алып тордың – кайтармадың, гайбәт сөйләдең, кешене рәнҗеттең, кемгәдер карата ниндидер гаделсезлек кылдың, урладың... Кеше: «Картайгач тәүбә итәрмен», – дип хыялланып яши, әмма ул картайганчы рәнҗеткән кешеләр үлеп китәргә, һәм ул гафу сорарга өлгерми калырга мөмкин. Бу очракта, күпме генә тәүбә итсәң дә, гөнаһ инде кичерелмәячәк.

Аллаһы Тәгалә үзе каршында кылган гөнаһны гына кичерә. Әгәр син Аллаһы Тәгаләгә гөнаһ эшлисең икән, бу синең белән аның арасындагы гөнаһ була. Әгәр аны кемгәдер сөйлисең икән – кешегә чыгарган өчен тагын гөнаһ өстәлә. Мактанып сөйләсәң – ул гафу ителми торганга әйләнә. (Киңәш сорап барганда үкенеп сөйләү – анысы башка.)

PRESSA.RU

ТМТВ ПРЕМИЯЛӘРЕН ТАПШЫРУ ТАНТАНАСЫ

ЯКИ ТАТАР ШОУ-БИЗНЕСЫНЫҢ «ӨЧЕНЧЕ БИЕКЛЕГЕ»





























Апрель. Казан. «Пирамида». «ТатМузТВ» каналы өченче тапкыр музыкаль премияләрен тапшыра. ТМТВ премиясен, «Татар җыры» фестивальләрен, шоу-бизнесның хисап концерты буларак, узган елга йомгак, киләсе елга үсеш перспективаларын билгели торган тамашалар итеп кабул итәргә кирәк. «Татар җыры»ның күпмедер дәрәҗәдә социаль йөкләмәсе булса да (исеме үк моңа ишарә), музыкаль телеканал премиясе исә татар телендәге күңел ачу индустриясенең үсешен күрсәтә торган тамаша.

Тамаша төп бурычын үтәде. Шоу-бизнес концерты тамашачыны шаккаттырырга, күз явын алырга, хәйран калдырырга тиеш бит, шулай булды да: тамашачылар вакыт-вакыт «Ah!» итте, вакыт-вакыт «драйв» алды, урыны белән кушылып биеде дә. Сәхнәдәге 13 экран, андагы соклангыч кадрлар һәм бәйрәм рухы бирә торган башка визуаль эффектлар, көчле тавыш, җырчыларның төрле һәм төсле киемнәре, экстравагант образлар, берьюлы алты алып баручы, үзенчәлекле сценарий... Болар барысы да сценарий авторы һәм алып баручы Гөлназ Сәфәрова белән режиссер Максим Скалозубовның табышы. Беренче өлештәге зәвыклы күлмәген пижама стилендәге костюмга алыштырып чыккан Гөлназ Сәфәрованың эпатажлыгы да урынлы булып күренде: 2016 елда Dolche&-Gabbana тәкъдим иткән пижама стилен иң беренче шоу-бизнес вәкилләре үз итте. Голливуд йолдызлары аны кайда, ничек итеп кияргә өйрәттеләр. «Беренче канал»да бу стильне «Пусть говорят» тапшыруында Ксения Бородина алып кергән иде. Татар сәхнәсенә исә Сәфәрова белән «Иң стильле башкаручы» Ландыш Нигъмәтҗанова алып менде. Быелгы тантананың тагын бер үзенчәлеге: ул стереотипларны җимереп кенә калмады, ә пафостан да арынган иде. Гап-гади, кайчак ирониясе юмор, алып баручылар белән җырчылар, җырчылар белән тамашачылар арасының якынаюы, номинацияләрне игълан итәргә чыккан кунакларның чиста татар телендә аралашуы – болар берсе дә чыгышларның сыйфатын киметмәде, киресенчә, бизәде генә.

Премия номинацияләре бик күп иде (барлыгы – 41 номинация, АКШның 60 тапкыр үткәрелгән атаклы «Грэмми»енда, мәсәлән – 78), шул ук вакытта алар жанрларга бәйле түгел. Димәк, татарның поп-мәдәниятендә әле жанрларга бүленеш юк дигән сүз. Совет чорындагы масса-күләм мәдәният оеткысында күпергән шоу-бизнес үз товарын (бу очракта җыр дип укырга) базар икътисады шартларында җитештерә башлады. Ә бездә ул озын көйгә нигезләнгән лирик җыр да такмакчарак шаян җыр. Иҗатын үзенчәлекле рок стилендә башлаган Илсөя Бәдретдинова да «ТМТВ продакшн тәкъдим иткән иң яхшы клип» номинациясендә Илсөяр Иксанова шигыренә иҗат ителгән лирик җыры белән җиңә. «Халыкчан җырчы» (бу номинациядә «Музыкаль биеклекне» Илдар Әхмәтов белән Эльмира Сөләйманова алды), «Халык мәхәббәте» (Айдар Галимов), «Тамашачы мәхәббәте» (Әнвәр Нургалиев) кебек номинацияләр булса да, халык җырларына аерым бер номинация дә бирелмәгән. Гомумән, бүген тамашачыга җырчының нәрсә турында җырлавы мөһимме соң ул? Дөресрәге, җырның эчтәлеге кызыксындырган тамашачы бүген рок тыңлый дип беләм. Күңелләрне кытыкларга сәләтле лирик җырлар исә күбрәк хис хәтере калдыруга йөз тота. Кайбер номинация җырчы өчен махсус уйлап чыгарылганмы әллә, дигән тәэсир калдыра. Мәсәлән, «Эстраданың поп-принцессасы» номинациясе (Азалия Зиннәт алды). Шул ук вакытта әлеге номинацияләрнең татар поп-сәнгатендәге соңгы тенденцияләрнең йогынтысы буларак формалашуын да аңлыйсың. Мәсәлән, шундый тенденцияләрнең берсе – ирле-хатынлы дуэтлар. Моңа кадәр җыр сәнгатебездә Зөлфия һәм Җәвит Шакировлар белән Динә һәм Рафаэль Латыйповлар дуэтлары гына бар иде. Хәзер дистәдән артып китә. Аларга номинацияләр дә күп: «Җырлы гаилә» (Динә һәм Рафаэль Латыйповлар), «Иң яхшы дуэт» (Зинира һәм Ризат Рамазановлар), «Иң стильле дуэт» (Салават Миңнеханов һәм Гүзәлем), «Иң яхшы иҗади тандем» (Гүзәлия-Хәким).

Татар эстрадасындагы икенче бер сөенечле тенденция – географиянең киңлеге. Башкортстан әле һаман «йолдызлар» белән тәэмин итеп тора. «Иң популяр җырчы» Радик Юльякшин, Әнвәр Нургалиев, «Ел ташкыны» булып килеп кергән Ләйлә һәм Рөстәм Галиевлар – шуннан. Әле болар «Ел җырчысы» Салават, Айдар Галимов, «Эстрада сәнгатенә зур өлеш керткән» Хәмдүнә Тимергалиева һәм «Алтын тавыш» иясе Филүс Каһиров исемнәре янына өстәгәндә. Мәскәүдән Радик Яруллин белән Айрат Сафин, Ульяновскидан Рамил Айметдинов – кыскасы, бу тенденция шоу-бизнестагы сәламәт көндәшлек турында сөйли.

Тамашаның ахырына кадәр Фирдүс Тямаевны көтеп тә, көтеп ала алмаган һәм аптырашта калган тамашачыларга шуны әйтәсе килә: бүген тавыш яздыручы лейбллар да, телеканаллар да, радиолар да йолдызлар иерархиясендә монополия була алмый. Алар, продюсер булып, йолдыз кабызган хәлдә дә, «беренче» дигән тамга суга алмый. Йолдыз булып кабыну өчен хәзерге заманда музыкантларга тавыш яздыручы лейбл да, радио һәм ТВда ротация дә, хәтта премия дә кирәкми: хәзер җырлаучылар белән тыңлаучылар арасында арадашчылар юк, интернет кына бар. Мәсәлән, үзенчә бер жанрда иҗат итүче Juna төркеме тантанада премия алган кайбер җырчылардан популяррактыр да әле, бәлки. ТМТВ премиясен алмаганнан гына Фирдүс популярлыгын югалтмас. Шушы ук сүзләрне Ришат Төхвәтуллин турында да әйтеп була. Шулай булгач, бүген кемне «йолдыз» дип атарга соң? Дистә еллар дәвамында унар көн зал тутырып тамашачы җыйган һәм тере тавышка җырлаган Салаватмы, әллә берничә ай эчендә миллионнарча тамашачыларның, шул исәптән, татар булмаганнарның да, йөрәген яулаган Эльмира Кәлимуллинамы? Ә бәлки, инстаграмда көн саен миллион лайк җыя торган блогердыр?

Димәк, хәзерге заманда «йолдыз» – чагыштырмача төшенчә. Йолдызлар сүнәргә дә мөмкин, ә мәңә шәхесләр кала. ТМТВ премиясен тапшыру тантанасында моны аңлап, сыйфатка йөз тотулары сизелә иде.

Фотолар «ТатМузТВ» телеканалыннан алынды

PRESSA.RU




БӨЕКЛӘР ҺӘМ БӘЕТЛӘР

Роза
КАМАЛЕТДИНОВА

Казандагы бу музей – зур тарихлы, бай мирасханәләрнең берсе. Максим Горький музее 1940 елның 19 мартында ачыла. Хәзер ул А. М. Горький һәм Ф. И. Шаляпинның әдәби-мемориаль музее дип йөртелә. Максим Горький белән дөнья күләмендә танылу алган опера җырчысы – якташыбыз Федор Иванович Шаляпин музее бер түбә астында. Бөтен дөньяга танылган бөек әдип «тәнем белән – Түбән Новгородта, ә рухым белән мин Казанда тудым», дигән икән, бу арттыру түгел. Катмарлы да, гыйбрәтле дә тормыш юлы узган Алексей Пешковның күңел күзе нәкъ менә Казанда ачылса, гаҗәпме?! Аңа 16 яшь. Дөньяны танып белү чоры.

Гыйбрәтле язмышлар шаһиты экспонатлар кинәт телгә килер дә, бөекләргә кагылышлы өр-яңа сәхифәләр ачылыр төсле. Бер үк сукмаклардан йөрсәләр дә, ике даһи ул чорда берсен-берсе белми-танымый әле. Әмма Казан турындагы якты хатирә-истәлекләр якынайтачак, гомерлек дуслар итәчәк аларны. Малай чагыннан хорда җырлап осталыгын чарлаган, йөз елга бер тапкыр (бәлки берәүгә генә!) бирелә торган гаҗәеп таланты белән меңләгән тамашачыны гашыйк иткән Шаляпинның кабатланмас тавышын ишетергә теләп, Казандагы бу музейга килүчеләр бихисап. Быел 16 мартта Максим Горькийның тууына – 150, 13 февральдә Федор Шаляпинның тууына 145 ел булды.



Флора Фәрит кызы Мирзина белән музейның баш сакчысы бүлмәсендә әңгәмә корып утырабыз. «Главный хранитель» атамасын бик үк өнәп бетерми икән ул, өлкән фәнни хезмәткәр дисәк дөресрәк булыр, дип исәпли.

Әгәр мәктәптә укытса, укучыларын әдәбиятка гашыйк итә торган талантлы педогог булыр иде Флора Фәрит кызы. Чөнки холкы шундый – чын күңелдән, эшен яратып, җиренә җиткереп башкара торган зыялы зат ул. Әмма студент кызның язмышы башка юлдан китә. Әнисе – мәдәният министрлыгында бухгалтер булып эшләүче Нәзирә ханым Мирзина – Горький музеенда вакытлыча гына эшләп торырга кеше эзләүләрен белеп, аңа бәхетен сынап карарга тәкъдим итә. Зыялы гаиләдә үскән кызыксынучан кызны яратып кабул итәләр.

– Татар телен яхшы беләсезме? – Мария Николаевна Елизарованың бу соравы кызны каушатып җибәрә.

– Сөйләшәм. Ә әдәби телне… – ди дә туктап кала. Шәһәрдә үскәннәрнең күбесе сыман, рус телендә аралашуны хуп күрә түгелме соң ул да?! – Әтиебез хәрби очучы иде. Байтак еллар чик буендагы калаларда яшәдек, – дип истәлекләр яңарта ул. – Миннән бер генә яшькә кече сеңлем Зарима белән әрмән, грузин, азәрбайҗан мәктәпләрендә белем алырга туры килде. Кайда яшәсәк, шул халыкларның телен өйрәндек. Азәрбайҗан мәктәбендә уку җиңелрәк, төрки тел, дин дә якын. Казанга кайткач, без укыган мәктәптә татар теле өстәмә дәрес буларак керә, теләгән кеше йөри, йөрмәгәне…

Әбиемнең, ана сөте белән кермәсә, тана сөте белән керми, дигәне күңелгә уелган. Ана сөте, ана теле, туган ил… бу сүзләрнең асыл мәгънәсен торып-торып аңлыйсың. Безнең нәсел – данлыклы нәсел. Дәү әтиебез заманында Дәүләт Думасына сайланган булган. 58 нче статья чәпәп, төрмәгә утырталар аны. 1939 елда вафат була. Әнине – ул чакта 7-8 яшәр ятим кызны – Торнаяз авылыннан авылдашлары Казанга алып килә, Печән базары янында калдырып китәләр. Нәни Апуш кичергәнне ул да кичерә. Бер туганы табып сыендыра үзен. Муса Җәлил, Сибгат Хәким, Усман Әлмиевлар укыган 13 нче мәктәптә укый. Дәү әниебез дә укымышлы абыстай иде. Әмма курку вөҗүденә шундый сеңеп калган… Еллар үткәч, бабайларга кагылышлы документларны табып, архивтан күчермәсен алып кайткан идем. Күз дә салмады дәү әни: «Ник алып кайттың? Нигә кирәк алар?» – дип, кул гына селтәде. Пенсиясе дә юк иде аның. Әмма ачлык күрмәдек. Гади генә ризыкны да тәмле, туклыклы итеп әзерләү серен белә иде ул. Кайгыртучан, тату, дус гаиләдә үсүебез үзе бәхет бит. Кыш көне әти безне йөрергә алып чыга. Йолдызларны танырга өйрәтә. Туган телеңне, гореф-гадәтләреңне белергә кирәклекне сеңдергәннәр алар. Дәү әнинең: «Мин үлгәч, сәдака бирүче дә булмас микәнни?» – дигәне күңелне өтте: «Ә без?» – дидем. Гомерләр үткәч, Харитоновлар басмаханәсендә чыккан «Коръән»не табып, ничек сөенгәнемне белсәгез! Тукайның «Пар ат»ын тиз генә ятлый алмадым. Өйрәнми ятмыйм, дип төн ката утырганым истә әле. Икенче дәрестә укытучыбыз Фәрит абый: «Йә Мирзина, өйрәндеңме?» – ди. Сөйләп бирдем. «Булдырдың, хәтереңә салып куй, татар теле ашатыр әле үзеңне!» – дигәне кызык тоелды. Сүз асылын аңлар өчен вакыт кирәк…

«Яшь ленинчы» газетасында бер җәй курьер булып эшләвем истә. Венера Ихсанова, Рәйсә Яхина, Марс Шабаев, Хәмзә Зарипов, Зоммер Гыйләҗевның студентны бала-чагага санамый җылы аралашулары хәтердә.

Мария Николаевна Елизарова иң беренче көннән аны үз канаты астына ала. Татарча беләсеңме, дип соравы да юкка булмаган. Күп тә үтми, авылдан килгән балаларга музейны күрсәтү, экскурсия үткәрүне йөклиләр аңа.

Тормыш сукмагы аны музей дигән серле дөньяга алып керә.

Күз курка, кул эшли, дия иде дәү әниләре – хак икән. Татарча кайбер сүз онытылса, русчасын әйтеп куя. Укытучылары татарчага тәрҗемә итә. Көлешә-көлешә, шундый якынаеп китәләр, бу очрашу ике якта да якты хисләр уята. Яшь белгечне «булдырдың!» дип мактаулары үз көченә ышаныч, егәр бирә. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Флора Фәрит кызы Горький һәм Шаляпин фанатлары белән йөзләгән очрашулар үткәрсә дә, һаман дулкынлана әле, даими эзләнә. Хәер, чал тарихның үзе, бөекләр эзе сакланган гаҗәеп бинада дулкынланмый булмыйдыр шул! Музей да җанлы кеше кебек: карау, яңарту, үзгәрешләр көтә. Гасырлар дәвамында халыкның күз алдында булган бина да искерә, туза.

– Кырыгынчы елдан бирле эшләп килгән бинага ярты гасыр элек – 1968 елда реконструкция ясалган. Мирасханәбез урнашкан бу йорт таушалган, нык тузган иде. Әдип ипи пешергән пекарня терәүләр белән терәтелгән. Кешедән оят, кулдан эш төште. Бәхеткә, Президент мәдәният өлкәсенә караган корылмаларны игътибар үзәгенә алган, сезгә килә, дигән хәбәр килеп иреште. Чыннан да, таңнан – иртәнге җиде дә юк иде әле – Рөстәм Миңнеханов Олеся Балтусова белән безгә килеп керде. Дикъкать белән бар нәрсәне күздән кичерде, Горький, Шаляпинга бәйләнешле сораулар бирде. Ничек кыюлыгым җиткәндер, «Фондта рус һәм татар язучыларының архивы, Әмирхан Еники, Ибраһим Нуруллин хатлары, әсбаплар да саклана бит. Ә музейның хәле аяныч. Бу хәл үзгәрерме? Бөтен өмет сездә, Рөстәм Нургалиевич!» – дип әйтеп салдым. «Өметләнегез!» – булды җавап. Өметләндек, көттек. Үзегез күрәсез, бүгенге көндә мирасханәбез гаҗәеп зәвыклы бинада. Президент быел да безгә килде. Балаларның мичтән ипи алганын, музей белән чынлап кызыксынуларын күреп, аның үзенең дә күзләре очкынланып китүен, ихласлыгын бәяләми мөмкин түгел иде. Түзмәдем: «Чын ир-егет Сез, сүзегез дә, эшегез дә хак!» – дидем. Ихлас соклануым да, безнең рәхмәтебез дә иде бу аңа.

– Фондта Еники, Нуруллин архивлары, дидегез…

PRESSA.RU

– Еникиның «Әйтелмәгән васыят»е үзе генә дә гаҗәеп хәзинә бит. Әдип картая, дөнья белән саубуллаша. Ә архивы кала. Әтисенең фронттан язган хатларын, фоторәсемнәрен, кулъязмаларын Резеда Әмирхановна китерде безгә. Ибраһим Нуруллин архивы белән дә шундыйрак хәл булды. Хатыны Розалина Мәрдановна ИЯЛИгә дә мөрәҗәгать итеп караган – акча юк дип алмаганнар. Безнең музей акча тапты, алдык. Ә архивта Горький белән Гаяз Исхакый арасындагы бәйләнешләр хакында кызыклы мәгълүмат бар. Исхакыйның бөек рус әдибенә язган 14 хаты Мәскәүдә – Максим Горький исемендәге Дөнья әдәбияты институтында саклана. Без гомер буе язучылар белән тыгыз элемтәдә идек. Кырлайдагы Габдулла Тукай музеен оештыруда Мария Николаевна Елизарова һәм минем дә өлешем зур булды дисәм, арттыру булмас. Текстларны татарчага тәрҗемә итү миңа йөкләнгән иде. Шикләнгән сүзләрне дәү әниемнән сорыйм. Аннан галимнәргә укытып, текстны раслатабыз. Мария Николаевна бизәү эшенә Лотфулла Фәттахов, Харис Якупов, Виктор Куделькин кебек рәссамнарны тартты. Бакый Урманче җәмәгате Флора Урманче белән аралашулар күңел офыкларын киңәйтте. Гомәр Бәшировнның «Намус» романы буенча күргәзмә оештырдым. Чал чәчләрен җилфердәтеп, музейга Хәсән Туфан килеп керер иде. Госман Бакир, Габдрахман Минский, Мирсәй Әмир, Илдар Юзеев, Нәби Дәүли, Зәки Нури чакырганны да көтми киләләр. Халык белән аралашалар. Ә Казанда туган, рус телендә иҗат итеп, татар әдәбиятында якты эз калдырган, Лондонда яшәп, Дәрдмәнд, Тукайны инглиз теленә тәрҗемә иткән Равил Бохараев үзе бер ачылмаган дөнья бит әле... Бервакыт Кишиневта иҗади очрашуларда булдым. Муса Җәлил иҗаты турында радиодан чыгыш ясаган идем. Бохараев шалтырата: «Чыгышыңны тыңладым. Ошаттым!» – ди. Рәхмәт, без бер дулкында икән, дидем. Горький аша дөнья әдәбиятына юл ачыла. Ни аяныч, хәзерге язучылар музейга юлны онытты.

Ә бит әдәбият, халык язмышы, үткәне, бүгенгесе – бөтенесе бер җепкә теркәлгән.


* * *

Алексей Пешковның әдәби мохиттә Горький тәхәллүсе белән танылуы очраклы хәлме? Кеше – горур яңгырый! Человек – это звучит гордо! – Аның исеме белән киң җиһанга таралган яңгыравык җөмләне күп буын шигарь итте. Ә бит «гордо» һәм «горько» арасындагы аерма – җир белән күк арасы. Үткен күзле Пешковның олуг язучы – Максим Горький булып өлгерүе өчен күргән-кичергәннәре роль уйнаган, әлбәттә. Әдипнең көче – гаҗәп дәрәҗәдә күзәтүчән булуында. Ике-өч җөмлә белән истә калырлык образ тудыра алуында.

Алешага өч яшь чагында вафат булган әтисе Максим Пешковның якты образы әдип күңелендә тере булып мәңге сакланачак. Яшьләй тол калган әнисе Варвара Васильевна исә – бәхетен, җылы таба алмый өзгәләнгән күбәләктәй җан – кабат кияүгә чыгып караса да, ирдән уңмый, бала тапкач үлә. Киң күңелле әбисе – шул фәкыйрь көнкүрештә дә ямь таба белүче, авырлыкларга бирешми торган Акулина Муратова аның өчен иң кадерле, якын сердәше, терәк һәм юаныч була. Иске чүпрәк-чапрак, сөяк-санак җыеп, шуны сатып тиеннәр юнәткән, кулларын кычу баскан, тома ятим малай фәкыйрьлеккә, кагу-сугуларга күнә, тик бер нәрсәгә – мәрхүм әтисе йә әнисе исемен кыстырып кыек сүз әйтүче булса, түзми, әйткәләшеп кенә калмый, сугышырга ук тотына. Саран бабасы Василий Каширин өчен күптән артык кашык инде ул. Әнисен күмеп, ике атна үтүгә: «Ну, Лексей, ты – не медаль, на шее у меня не место тебе, а иди-ка ты в люди...» – дип, аны өеннән чыгарып җибәрә. 11 яшендә үз көнен күрергә мәҗбүр Алексей тамак хакына кайда, кемгә генә ялланып эшләми: аяк киемнәре кибетендә – йомышчы, сызым сызучы ерак туганында – өйрәнчек. Чынлыкта – көнлекче, пароходта – савыт-саба, идән юучы, йөк ташучы да... Үсмернең китап яратуын күргән танышы – киң күңелле студент Николай Евреиновның, ышанып: «Син университетка керергә, укырга тиеш! Бездә яшәп торырсың!» – дигәненә алгысынып, 1884 елда ул Казанга килә. Ярлы-ятимнәрне югары уку йортына алмаска дигән карар булганмы – өмет акланмый, саллы ишекләр ачылмый. Ихтимал, университет белемен тормыш үзе бирәсе язмышына алдан язылгандыр. Баштарак ул Василий Семеновның крендель пекарнясында эшли. Тырыш, бай рухлы, әмма авыр эштән изелеп, мескен, эчкече, куркакка әйләнгән хокуксыз эшчеләр белән аралашу, гади кеше язмышы тетрәндерә аны. Сынау арты сынау узгач, хуҗа аңа чистарак эш тәкъдим итсә дә, кеше рухын кимсетә, рәнҗетә торган җирдә кала алмый ул. Андрей Деренков белән танышуы аң-фикерен үзгәртә. Аның яшерен китапханәсеннән фәлсәфи китаплар алып укый, аң-зиһене, күзе ачыла. Ипи-күмәч пешерүче, ягъни пекарь ярдәмчесе, чынлыкта – кулдашы була. Капчык-капчык он ташый, мич яга, күәс-күәс камыр баса, булка, ипи итеп әвәләп мичкә тыга. Пешкән күмәч, калачларны кәрзингә тутырып, сатарга чыгып китә. Университет студентларын сыйлый.

Халыкның холык-фигылен нечкә тоемлап, кайчак бер-ике җөмлә белән татарларга хөрмәтен белдергән олуг әдип «Минем университетларым» әсәрендә күңелсез, ямьсез чынбарлыктан качасы, яхшы күңелле, ягымлы кешеләр тора торган татар бистәсенә китәсе килүен тасвирлап: «...алар нindидер үзенә бертөрле, пакь тормыш белән яши; алар русча бик кызык, ватыпсындырып сөйләшә; биек манаралардан кичләрен мөәзиннәрнең мәчеткә чакырган сәер тавышлары яңгырый; татарларның бөтен тормышы башкача корылгандыр, ул миңа таныш түгел, мин белгән, миңа шатлык бирми торган тормышка охшамыйдыр дип уйлый идем», – дип яза. Әйе, ул татарларны ярата иде, дибез, Казанда шундый музей булуы белән горурланабыз.

КОНТАКТ ТА : ://syuyumbike



Ким Сонг Гон

Казан федераль университеты аспиранты, Көньяк Кореяның Пусан дәүләт университеты

Өйләнмәгән

Карьера: Көньяк Кореяда корея теле һәм әдәбияты укытучысы

Тормыш шигаре: «Башкаларны игътибар белән тыңларга, ихтирам итәргә кирәк. Һәркемнең дөньяга үз карашы».

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Тирамису – бик тәмле торт!

Мин кафеда утырып укырга яратам. Өй эшләрен дә шунда эшлим. Гадәттә, «Американо» яки «Латте» каһвәсе алам. Күптән түгел Бауман урамындагы кафеда утырганда күзем бер тортка төште. Ул «Тирамису» торты турында ишетеп белә идем, ләкин моңа кадәр татып караганым юк иде. Бу юлы шуны алдым да... кашык белән бер алып каптым. Тәме... могҗизага тиң иде!
Әлеге ризыкның тәменә ләззәтләнеп, кафеда озак утырдым ул көнне.

Очрашу урыны – Казан

Февраль урталарында кытай дусларым мине фатирларына ай календаре буенча Яңа ел каршыларга чакырдылар. Анда Россиядән, Көньяк Кореядан, Кытайдан, Япониядән, Тайваньнан килгән кунаклар җыелдык. Шундый халыкара очрашу килеп чыкты. Таныштык, сөйләштек, бик күңелле итеп утырдык. Дуслыгыбыз әле дә дәвам итә, күптән түгел бергәләп Черек күлгә чыктык. Казан безне очраштырды, таныштырды. Бәлки әле кавыштырыр да...

Олимпиада ышаныч уятты


Быел Көньяк Кореяның Пхёнчхан шәһәрендә Кышкы олимпиада узды. Безнең халык өчен шатлыгы күп булды аның. Бу Олимпиадага кадәр бездә спортның фигуралы шуу, тимераякта тизлеккә ярышу төрләре генә популяр иде. Быел исә моңа кадәр Кореяда киң таралмаган кёрлинг, бобслей, скелетон кебек спорт төрләренең дә үсеш мөмкинлекләре барлыгы ачыкланды – безнекеләр анда казанышларга иреште. Шул ук вакытта бездә Төньяк Корея командасы да катнашты. Бәлки, бу ярымутрауда тынычлык урнаштыруга үз өлешен кертер дип ышанасы килә.

сөендерде





көендерде




сөендерде





көендерде




сөендерде





көендерде



Кайгы тавышланып йөрми

Быел 1 гыйнвар көнне үк күз алдымда socially коточкыч хәл булды. Кичке эңгер-меңгер җиткәндә кибеткә китеп бара идем. Светофорда яшел ут янганны көтеп торам. Шул мизгелдә машина тәгәрмәчләренең кинәт сызгырып тукталуына башымны күтәреп карасам, бер әби тәгәрмәч астында калды. Ул кычкырырга да өлгермәде... Бөтен дөнья тавышсыз кинодагы сыман хәрәкәтләнә кебек тоелды. Тирәюнемдәге кешеләр дә тавыш-тын чыгармады. Бу әби дә берничә сәгать элек кенә якын кешеләрен бәйрәм белән котлагандыр, ә хәзер аңсыз ята, кара асфальт ярыкларына кан ага...
Минә шул мизгел күңелгә авыр хатирә булып кереп калды.

#bloodyFIFA2018 – хайваннар хэштегы

Универсиада авылында сукбай этләр һәм мәчеләр күбәеп китте. Шуларның берсе нәкъ мин яшәгән корпус тирәсендә йөри. Аңа махсус ашарга ала башладым. Кызганыч, ул мәчегә вакытлыча гына ярдәм итә алам. Тулай торакта яшәгәч, аны үземә ала алмыйм. Быел җәй көне Россиядә футбол буенча Дөнья чемпионаты узачак. Гадәттә, андый масштабтагы чараларга шәһәрләрне сукбайлардан арындыралар. Казандагы сукбай этләрне дә аулаячаклар дип ишеттем. Үтерерләрме, әллә приютларга урнаштырырлармы?

Дуслыкка өметләнгән идек

Мәскәүдә, Санкт-Петербургта, Казанда булганда ялгызым гына йөрергә яратам. Егет кеше буларак, курыкмыйм. Ә менә Кореядан килгән кызлар үзләре генә урамга чыкмаска тырыша, чөнки расистлар һөҗүменә юлыгу куркынычы бар. Еш кына яшь егетләр, сызгырып, төрле сүзләр әйтеп мыскыллап калалар. Берсенә ташлар атып калганнар хәтта, аягын авырттырып кайткан иде. Бервакыт Мәскәүдә бер милләттәшемне таныш түгел бабай бик рәнҗеткән. Ни өчен, дисезме? Төньяк Кореядан булмыйча, Көньяктагысыннан булганы өчен. Кореядан килгән кешеләр белән россиялеләр арасында дуслык кына булыр дип килгән идек бит без.

PRESSA.RU

Розалина Шаһиева шигырьләре – бөтенләй башка! Беркемнекенә охшамаган! Аларда ургылып торган хис, хикмәт тулы фәлсәфә, җете сурәт-төсләр, үзенә бер затлылык... Шәрык һәм Аурупа шигърияте калыплары иҗатына җай гына кереп утыра да үзгә бер дөньяда йөздерә... Сискәндерә. Сокландыра. Шаккаттыра.



Розалина
ШАҺИЕВА

ЯЗ ИСЕ

Гомер китабы

Кыл кебек нечкә хәрефләр
Түшәлгәннәр кәгазьгә...
Бөҗәк кебек кыймылдашып,
Чакыралар вәгазьгә!
Бер хәреф ай – күктән төшкән.
Берсе – таҗ кигән сылу.
Берсе – дулкын, берсе – упкын –
Ярсуланып, җан сыну?!

Шуларда гомер җепләрем –
Фирәзәдәй арузым!
Хуш исле агач төпләрем,
Көл тауларым, нигезем!
Даһиларым, Тукайларым,
Туган телем-гөлкәем,
Манаралы зур шәһәрем,
Моң чишмәсе – әнкәем!

Болыннарны кичүләрем,
Камылларга кагылып...
Яланаяк йөргәннәрем,
Әтиемә тагылып...
Бу дөнья – гомер китабын
Киләчәккә, мәңгегә
Хикмәт тулы сандыкларга
Салып калдырам сезгә!

Сагыну

Мәңге яшь күңелемдә
Мәңгелек җыр – авылым!
Алтын-алсу манаралар –
Тирмәләрем, богылым!..
Корт сарган корт бакчалары,
Умарталык, әремлек...
Синең җәйге гүзәллегең
Йөрәгемдә мәңгелек!
Түгәрәк күл, ат көтүе –
Күперең дөбердәве,
Алсу-кызыл сиерларның
Муенда кыңгыравы!
Җир йотканмы авылымны –
Бары түмгәкләр генә...
Түгәрәк күл өсләрендә
Ялгыз күбәләк кенә!
Күмелгән изге зират –
Кая карама – үлән!
Ник синең юкка чыгуың
Болай күңелне телә?!.

Уяныр әле буыннар,
Актарырлар камылны...
Тарих үтә шулай кайчак
Тамырларга кагылып!

Шулай күңел түрләрендә
Мәңге яшь бер сурәт!
Сары «канау», вак балыклар...
Өстә утыз күбәләк!

* * *

– Синең бакчаң – җәннәтең!
Күрмисеңме: кичләрен –
ияреп сиңа йөри бер пәри кыз –
күзләрен уйнатып,
иртән-кич, көн вә төн!..
– Ишетәмсең йолдыз аһәңен?
Кич җиткәч тәүгесе –
тишеп күкне чыга –
кабына тирә-як,
Тоймыйча сәбәбен!
Нур баса дөньяны,
Чишмәне, елганы...
Шәүләләр кабына,
кондызлар җылына...
Барча да йокыда...
Ә йолдыз шуыша,
елмая җай гына.
Шул мизгел коеңда –
пәриең тузгынган –
Ул «шып-шып» коена,
Бирешкән уена...
– Сине ерактан ефәк җеп белән –
уйлары – ефәге –
Курчактай урый ул,
нәкъ пәрәвез кебек,
төрә дә төрә...
Әвәли утында. Әзерли хөкемгә.
– Булырсың токтында!!!
Мәрхәмәт юк монда!..
Сөю ул ташкындай,
чыдасын баш кына! –
Ала да китә ул
Илһамлы тылсымга.
Юк киртә аңарга! –
Күгәрмә, каргама –
Язмышың китерде –
Бәлкем тагын бер кат
Татырсың татлы, хуш,
ялкынлы, агулы
Мәхәббәт сихерен!..

Яз!.. Яз!..

Әллә нинди көтелмәгән
ялкынсыну, җилкенсенү...
Әсир итә, назга төрә,
Күңелләрне «ду китерә»,
Бу дөньяның һәлакәте,
гүзәллеге нәзакәте,
Алга таба хәрәкәте,
Үзе ачы, үзе татлы,

Хорафатлы, мең канатлы –
Яз һәм сөю!!!

Яз!.. Яз!..
Күңелләрдә ташып тора,
Йөрәкләрне тоташтыра –
Ялкынсыну, җилкенсенү!
Күктән төшә,
Җирдә ташый –
Газиз башны ашый-ашый...
Явызлыкны төтен итә –
«Яртыларны» бөтен итә –
аттай башын чайкап килә,
Әллә җәһәт, әллә ташкын –
«Гомер ахыры» – яшәү башы»
«ялт-йолт» килгән йөзек кашы –
Яз һәм сөю!.. Яз һәм сөю!

* * *

Нинди дәрт, нинди моң
Иңдерәдер җиргә
Күкләрдән бу – шифа,
Онытылу!
Яз белән киләдер –
Күңелне өзәрлек
Яшәргә омтылу!
Мәңгелек, мәңгелек –
Дөньяны каплаган –
Бу сылу –
Яз исе... яз исе!
Җан тулы. Күк тулы –
Шигырьне, гомерне –
Язасы,
язасы, язасы!!!

* * *

Яз исе!..
Йолдызлар астында
Хикмәтле шәһәрем –
Яз исе, җир исе. Гөл исе!
Тынгысыз дәрт белән,
Җиңнәрне сызганып,
Бу илне төзисе. Төзисе!!!

Иделдә чайкалган шәһәрнең,
урамым!
Илһамым – дәрьялар гизәрлек!
Яшәсен дөньяда
Күңелне өзәрлек
күкләрдә йөзәрлек гүзәллек!

Бәрелә дулкыннар
Кашыма, башыма –
Яз исе, яз исе, яз исе!
Кәгазьне бөгәрлек
Күңелне иярләп –
Язасы, язасы, язасы!

Кечкенәдән үк әдәби мохиттә кайнап үссен дә, бабасы – язучы Аяз Гыйләҗев, әтисе – әдәбият галиме Искәндәр Гыйләҗев булсын да, университетта журналистика буенча укысын да... Иҗатка, шигърияткә ничек битараф калсын инде Миләүшә! Күңел нәүмизләнгәндә йә иләсләнгәндә, гашыйк булганда йә җанны уйлар айкаганда кичергәннәр кәгазьгә күчә икән. Шигырь булып, канатлы сүз булып...

Миләүшә
ЗАКИРОВА



КАРАГЫЗ КҮЗЛӘРЕМӘ...

* * *

Миллионлы шәһәремдә
Миллион йөз чагыла.
Шул йөзләрнең барчасыннан
Берсе бик якын миңа.

Меңәрләгән машиналар
Тыз да быз чабып тора.
Җанга уелган санлысын
Күзләрем табып тора.

Йөзәрләгән таш биналар,
Чатлары, почмаклары...
Һәркайсының бар күңелдә
Сакланырдай чаклары.

Бихисап исем-дәшүләр –
Ишетүем сак минем.
Берсен – бердәнберен генә
Күңелемдә саклыймын.

Миллионнан да, дистәдән дә
Табыла эзләгәне.
«Яратам!» – дип дәшсен иде
Өметем өзмәгәне...

* * *

Иркәләп, сыйпап,
Сөеп, назлап,
Күңелемнең кайсы кылларын
Тибрәттең син?
Җанымның кайсы авазларын
Таныдың син?

Көлеп, елап,
Күккә багышлап,
Йөрдем мин
Җир өстеннән,
Йөздем мин
Күл өстеннән.
Көйдем, яндым,
Бардым, таптым.
Югалтуның ни икәнен
Тагын татыдым.

Эзләндем, хафаландым,
Сабыр иткәч, аңладым:
Табышымның җимешен,
Тормышымның җисемен.

* * *

Карагыз күзләремә...
Ни күрәсез анда?

Хәйләкәр ялкыннар?
Йә салкын читләшү?
Масайган очкыннар?
Йә җылы килешү?

Мин монда түгел,
Мин ерак сездән.
Нәрсә уйлыйсыз – барыбер.
Махсус читләшәм сездән.

Күңел атылганда нишләмәк кирәк?
Ничек тыныч калырга?
Сезнең уй – хәмер, кәеф-сафа булса,
Минеке – башка дала.

Бүтән кеше калыбын алмыйм мин,
Тын гына күзлим.
Эчтән ачу, канәгатьсезлек яна да,
Хыялымнан башканы белмим.

PRESSA.RU



Кәрим
КАРА

БӘРЕЛЕШ

(Хикәя)

«Дөнья матур, шулай бит, Гөлүсә?» – «Әйе, Дамир». «Мин сине яратам, Гөлүсә!» – «Мин дә сине, Дамир». «Без бәхетле, әйеме, Гөлүсә?» – «Без бәхетле! Бу дөньяда бар кешеләр дә бәхетле. Кеше бу җиргә бәхетле булыр өчен килә...»

Кыз белән егет булып йөрү кызык икән ул. Киноларга, концертларга парлап барган буласың, караңгы почмакка сыенып, йолдызлар чутлап, үбешәсең-кочышасың да, зур эш кыргандай, өеңә кайтып йоклыйсың. Синең яшәешеңнең бер өлеше генә булып тора «ярату» дигән төшенчә. Анысы да әллә бар, әллә юк әле аның. Ияләшәсең инде ул кызга, холык-сыйфатларын белә башлыйсың. Кайчандыр шул сер тулы чибәркәйгә якын килергә дә батырчылыгың җитмәгәнен уйлап, үз-үзеңнән көләсең. Нәрсәгә дип йөрәк чыгардай булып каккандыр. Гап-гади кыз инде ул Гөлүсә, андыйлар авыл тулы.

Кендегең бәйләнмәгән лә озатып йөргән кызыңа. Бер-ике көн күрми торсаң да, күк гөмбәзе җимерелеп төшми. Кырыкмаса кырык төрле мавыктыргыч яклары бар дөньяның. Син яшь, син дәртле, көч-куәтең ташып тора, тирә-ягыңда якын дусларың, якыннарың, әти-әниең. Бүген иптәшләрең белән балыкка чыгып китәсең, иртәгесен кичкә кадәр узыштан печән чабасың. Бер машинага сигез егет кысылып утырып, районга килгән популяр җырчының концертын карап кайтасың. Ә Гөлүсә кайда булды икән ул кичне, эх, онытылган!.. «Ә мин урын өстендә чирләп яттым, Дамир. Син концертка баргансың бугай?» Кичер мине, кадерлем. Искә дә кереп чыкмады бит, ичмасам, онытылган...

Шаярып-көлеп кенә башланган эшләр, гадәттә, бик тә җитди тәмамлана. Башта сүз куш-кан буласың, аннан озата барасың, көтмәгәндә-уйламаганда кочакка килеп керә. Ә бердәнбер көнне бар вөҗүдең белән аңлыйсың: әнә шул почык борынлы, салам аяклы, чынаяктай зур күзле гел көләргә генә торган кызыкай сиңа сулар һава кебек кирәк. Ул янында булмаса, бу җирдә яшәп торуның да мәгънәсе юк, чурту матыр...

«Ә мин беренче озата килүеңдә үк сиңа кияүгә чыгачакмын дип юрап куйган идем...» Юкны сөйли, каян белсен ди ул киләчәкне? Мактанчыклык нәселләрендә бар аларның!

Ике ятып бер төшемә кергәне булмады Гөлүсәнең саранлыгы. Мине гаҗәпкә калдырып, яңадан-яңа сыйфатлары ачыла бара. Кибеткә керсә, туктатырмын димә: башта ике урый, җентекләп хакларын сораша, аласы әйберен иснәп, капшап карый, бер ала, бер куя, тагын урап килә. Йә Хода, барлык хатын-кызлар да шундыйрак буламы икән? Минем тезләрдә утырганда

һич тә андый булыр төсле түгел иде. «Саранлык түгел бу, акыллым, сакчыллык була, вак-төяккә акча чәчәргә яратмыйм мин. Хатының сакчыл булганга шатлан гына».

Бергә яши башлау кызык була икән ул. Гөлүсә һәрвакыт күз алдында. Йоклап киткәндә – караңгыда ул төсмерләнә, иртән күзләреңне ачсаң, тагын ул ята яныңда. Баштарак мин сискәнеп тә китә идем. Кинәт кенә: «Каян килеп кергән монда?» – дигән уй килә иде башка.

Без ул чакта гаилә тормышын шәһәр читендәге кечкенә бүлмәдә башлап җибәргән идек. Икебез дә иртән торабыз да эшкә йөгерәбез, кич җитсә, сәгатьләр буе автобуста селкенеп, шул кысан бүлмәбезгә кайтабыз.

Син ничектер, мин сиңа авыр өйрәндем. Бергә ашарга утыру да ниндидер кыенлыклар тудыра иде. Синең белән яши башлаганчы, өстәл янында ничек утыруым турында уйлап та караганым юк иде. Баксаң, мыш-мыш килеп, авыз чапылдатып чәйним икән, бертуктаусыз аякны селеккәлим, йә булмаса терсәкләремә таянып утырам. Ничек шулай ваемсыз булганмын икән?..

Безнең кысан гына бүлмәбез, Сталин заманыннан калып, урамга чыгып утырган тузган өйдә урнашкан иде. Әле шунысына да риза булып, ничек тә матурларга тырыша идек үз куышыбызны. Тәрәзә каршындагы баганадан ут нәкъ безнең иске диван өстенә төшә иде. Мин, әкрен генә кузгалып, терсәкләремә таянам да, онытылып, йоклаганыңа карап, хәйран калам. Уймактай борының, нәфис муең, алсуланып торган бит алмаларың, үпкәләгәндәй турсайган чия иреннәрең, сызылып киткән кашларың – барысы-барысы сихерле иде мине. Шундый гүзәллек буламы икәнни? Ә нигә бу фәрештәгә тиң зат минем янымда ята соң? Мин кем аңа? Нишләп мине сайлады? Бердәнбер көнне, ялгызымны калдырып, сихри канатларын кагып, зәңгәр киңлекләргә чыгып очмасмы?

Шуннан соң кара машина килде. Нигә шундый зур ул? Ярты күкне караңгылап, миңа якынлаша, давыл куптара, колак тондыргыч тавышлар чыгара. Ярабби, үзең коткар мине. Бу гыйфрит мине бер мизгелдә таптап-изеп китә бит. Тагын бер талпынса...

* * *

...Тагын саташа бугай, сестра! Тынычлан, Дамир, берни юк, мин янында, барысы да яхшы. Сестра! Бәлки, табиб чакырасыдыр? Ничек җаның түзеп карап торасың бердәнберең газапларын?..

Тынычлана бугай... тын алулары да тигезләнде... Йоклый, рәхмәт төшкере, әйе бит, сестра?

Юк, чәй эчәсем килми минем. Эчәсем дә, ашыйсым да килми. Ничә көннәр инде... Әни генә тиргәп ашарга мәҗбүр итә. Аяктан егылырмын дип курка. Хәзер миңа егылырга ярамый, көч күп кирәк булачак миңа...

Теге вакытта сөйләшеп бетермәгән идек дисеңме? Нәрсәдә тукталдык соң әле? Ә-ә-әйе... шуннан соң без ипотека алдык. Фатирдан фатирга күченеп йөрүләр тәмам бәгырьгә үтте. Нервыны нык талый чит бусагада йөрүләр. Түләп торырга җитәрлек акча эшли идек ирем белән. Фатирга түләү, беләсеңме, нәрсә ул? Үз кулларың белән хәләл акчаларыңны суга салу. Артыннан карап кына каласың – ага да китә. Нигә алай дисеңме? Менә уйлап кара, ай саен шыгырдап торган унбиш меңне хуҗаның кулына тапшырам. Ул бит сыпыра, Аллаһ әппәр! Шул акчаларны ипотекага түләп барсаң, бөтенләй икенче кәеф: күңел җырлый, өмет арта. Менә ипотеканың бер өлеше түләнде, тагын бераз кимеде, дип шатланасың. Чөнки үз куышың өчен түлисең. Берәр кайчан барыбер түләп бетерәчәксең, тулы хуҗасы булачаксың бу квадрат метрларның. Озак, әлбәттә. Менә безгә унбиш ел түләргә кирәк иде. Сәламәтме син, чирлеме, язмы урамда, әллә кышмы, эшлисеңме, әллә чыгарып ыргыттылармы эш урыныңнан, боларга банк битараф: чыгар да сал билгеле көнгә унбиш меңне.

Түләр идек лә, сау-таза булсаң, унбиш ел нәрсә ул? Кызыбыз бишенче классны тәмамлап калыр иде, ә кесәдә – фатирның синең исемгә язылган кәгазьләре. Әйтәм бит, түләр идек. Хәер, барыбер түләргә туры киләчәк. Минем агып чыккан күзем эшләргә комачауламас дип уйлыйм. Ике кулым исән-сау, мин тик тора белмим, тырышлыгым җитәрлек. Үземә яраклы берәр эш табылыр, язган булса. Әлегә эзләмим. Больничный түлиләр, эти-әниләргә рәхмәт, хәл кадәр ярдәм итәләр. Миңа Дамирны аякка бастырырга кирәк. Аннан соң эш турында уйларга булыр. Язганы шулдыр, ул ипотеканы да түләрбез без, тырышырбыз, тырмашырбыз... Юк, еламыйм, зарарланган күздән гел яшь килеп тора шулай.

Ул хәлдән соң Дамирга күренергә куркуларым, белсәң иде! Йөземнең яртысы сыдырылып кына төште бит ул кислотадан. Әле дә ничек җыерылып каткан, карарга куркыныч. Ул чакта бөтенләй кеше куркытыр кыяфәттә идем мин. Керде дә, күрде дә, бер сүз дәшми кочагына суырып алды. Шундый каты кысты: үләм дип торам. Мин елыйм, уралган бинтларны күз яшьләрем дымландыра, ул елый караватт тимеренә башын терәп. Шуннан...

* * *

Шуннан соң без ипотекага фатир алдык. Ул бәхетле көннәрне син дә хәтерлисеңдер, Гөлүсә? Минем хәтта атлап йөрүләрем үзгәрде, башны туры тотарга өйрәндем. Тегенди-мондый адәм түгел лә мин, хатыны, баласы, фатиры булган тулы хокуклы ир. Киләчәктә мине мавыктыргыч, серле, бәхет тулы гомер көтә. Бүгенгесенә дә разый идем мин, булганы бик җиткән; бераз алгарак китсәң инде, көнкүреш бөтенләй шатланып туймастай булыр иде. Килер андый көннәр. Ә әлегә кызчыгым, урындыкка басып, кулларын артка куеп, диванга кырын яткан әтисенә шигырь сөйли. Әнисе белән әтигә сиздерми генә өйрәнгәннәр, имеш. Ләйләнең өстендә Яңа елга кигән ак күлмәге. Әнисе шулай купшылаган аны бу тантаналы мизгелгә. Кызы артыннан һәр сүзне эчтән генә кабатлап тора, йөзендә дулкынлану...

Әминә елый үкеп...

Тубым суда дип...

Әти булу кайсы яктан карасаң да шәп нәрсә. Мондый артистларга учлар янып чыкканчы кул чабарга кирәк инде ул...

PRESSA.RU

Биш елдан артыграк без үз фатирыбызда яши идек. Кызыбыз Ләйләгә өч тулып китте. Гөлүсә белешкән: балалар бакчасына кабул итәргә ризалар икән. Тик автобус белән бөтенләй кире якка барасы. Минем кызны бакчага илтергә мөмкинлегем юк. Гөлүсә ничек өлгерер? Әле урамда көз, көннәр җылы тора. Салкын кышлар башланса ни хәл итәрсең?

Уйлаштык-уйлаштык та, машина алырга булдык. Кайсыбыз беренче әйтте икән ул сүзне? Яңасын алырга безнең хәлдән килми дә килми инде. Акчаларыбыз түләүләргә җитеп кенә бара. Балага нииндидер кием йә Гөлүсәгә итек, миңа джинсы алырга булсак, өч-дүрт ай алдан планлаштырабыз. Тамак ягын кысабыз.

Машиналы кеше башкалардан бер башка югарырак. Чыгып утыра киерелеп, гаиләсен төйи һәм китеп бара теләсә кайларга. Менә без дә баланы бакчага машинада илтер идек, авылга да ешрак кайтыр идек. Ә авыл бит ул оҗмах. Эссе ләүкәгә сузылып ятып, каен себеркесе белән чабынулары гына ни тора! Ә ите мул салынган токмачлы аш? «Ашагыз әле, ашагыз, тагын салам», – дип кыстап торган әни, еш-еш тамак кыргалап, дөнья хәлләре турында сүз кузгатмакчы булган әти...

Машина алу хыялыбызда да юк иде. Бер кайтканда авылдаш Рамил сүз арасында әйтеп куйды. Сату-алу белән эш йөрткән, елан аягын кискән кеше ул. Җирдә нык басып тора. Кызыл кирпечтән ике катлы йорт күтәрде авыл уртасында, кыйммәтле җиһазлар белән тутырды. Мунчасы ике катлы, бакчасы Мичурин картныкына тиң. Барысы биек койма белән уратып алынган. Яши рәхәтләнеп, алпавыт диярсең. Кайдан акча таба дигәндә, күзенә нәрсә күренә, барысын рәттән сата ул. Урман сата, терлек сата, баганада калган алюмин чыбыкларны салдырып сата, җиргә күмелеп онытылган тимер торбаларны казып чыгарып сата. Теләгең булса, табыла торгандыр сатар әйберләр дә. Аның холкы шундый – сатарга һәм табыш алырга!

Егет чагында йөрткән «семерка»сы бар иде аның.

– Утыра тузан җыеп, металлоломга тапшырырга жәл. Йөрерлеге бар әле аның, берәр илле мең биргән кеше булса, очырыр идем, – дип оеткы салды бу миңа.

Әти ике гаиләгә дип ел да үгез симертә. Дүрт-биш центнер авырлыкка җиткерә мәхлукны. Һәр елны кап яртысын мин алам. Ел буе иткә тилмермибез, тамак туйдырыр ризык була. Менә шул үз өлешемне Рамилгә тәкъдим итмәкче булдым мин. Ит ашамый да яшәп торырбыз. Бәрәңге бар, боткага өйрәнербез...

Кулга-кул бәрештек Рамил белән. Ул, кар төшкәч, иткә килергә булды, мин шактый келтерәгән машинаны капка төбенә кайтарып куйдым. Тимер-томырга кул ята минем, җан өрәм бу лайвага, язган булса...

* * *

Мин берни дә сизми калдым. Печтек кенә дә авырту тоймадым. Авыртмый икән лә ул. Узгынчы бер ир, аяктан егып, башым белән карга тыкты...

Машина алган идек без. Ләйләбезне бакчага йөртергә җайлы булыр дип. Ул якка файдасы булмады. Элекке эшемнән китеп, Ләйлә йөргән бакчага тәрбияче булып урнаштым. Акчага күпкә отылдым да соң, икенче яктан караганда, балам янымда, тамагыбыз шунда үтә. Нигә генә алганбыздыр инде кеше искесен? Әйбер алганда да, кешесенә карап алырга кирәк шул. Начар кешедән алсаң, тора-бара кыек ягы чыга. Шуны белдем мин.

Алган чакта, күз тимәсен, йөгереп кенә торды. Әле Дамирлар авылына кайтабыз, әле безнекеләрне барып күрәбез. Әти-әниләр оныкларын сөеп куаналар, ә без кишерен-суганын, бәрәңгесен-кәбестәсен, сөтен-каймагын тутырабыз машинага.

Тәмәкесен ташлый алмый җәфаланды Дамир. Мин дә минут саен игәүләп кенә тордым. Сәламәтлеккә зыян салуы гына җитмәгән, кесәгә дә нык суга бит ул. Көн дә йөз сум да йөз сум, Гани баймы әллә без?

Дамир тәмәкелек акчаны кичләрен таксовать итеп эшләргә җайлашты. Миңа ике-өч йөз кайтарып тоттыра, үзенә бераз кала. Начар түгел бит инде, килгән белән киткән бер түгел.

Ул көнне күңелем җилкенде дә җилкенде, бер сәбәпсез эчем пошты, елыйсым килеп тик торды. Хатын-кызларның була андый холыксызлыгы. Әмма бу көн бигрәк әллә нинди иде. Гадәте буенча, Дамир кичке аштан соң чыгып китәргә җыенды.

– Йөрмә, – дип каршы төштем. – Үзем бирермен тәмәкелек кенә. Ял ит, безнең янда бул, – дидем.

– Алырсың син каруннан акча, – дигән булды көлеп, аннан Ләйләне үз янына чакырды. – Кил әле, кызым, әтиеңне әп итеп озатып кал.

Чыгып китте шулай. Кулымнан эш төште. Кер үтүкләргә алындым, яраткан күлмәгемнең итәген яндырдым. Тәмам ачуым чыгып, Дамирга шалтыратып карыйм, алмый телефонын. Нәкъ шул чакларда бәрелешкәннәр инде алар. Өр-яңа «Мерседес» китереп бәрдергән аны буш урамда. Ул «Мерседес» унсигез миллион торган, имеш. Әйтергә куркыныч – унсигез миллион! Йокламый яткан төннәрдә юри генә санап карадым, бу кадәр акчаны без Дамир белән икәүләп күпме вакытта җыяр идек икән? Ашамый-эчми, беркая йөрми гел эшләп, гел акча җыеп – ничә ел эчендә? Икебезнең эш хакларын кушсак, төгәл утыз мең җыела. Әз дә кебек түгел. Ятам акшарланган түшәмгә карап, бармакларымны бөгә-бөгә исәплим. Бигрәк тә түгәрәк сан хасил булды, дөрес исәпләсәм. Илле ел!

* * *

Исемә төште, барысы да исемә төште. Соңга калдым. Шәһәр читендәге поселокка барып йөрергә туры килде ул көнне. Тәрәзәләрдә утлар сүнгән, халык йокыга талган. Көз күреме арада юл табадай ялтырап ята иде. Тыкрыктан зур тизлектә килеп чыккан машина минем арткы ишеккә бәрдерде. Мизгел эчендә вальс әйләнгәндәй түгәрәк ясады да, фонарь баганасын аударып, туктап калды. Аңа кадәр мин юл читендәге көрт өстенә чыгып очкан идем. Күпме җыенып йөрдем шул якның биген ремонтларга, тәки кул җитмәде. Әнә шул исән калырга сәбәп булды, ахрысы.



Рәсем: Наталья Васильева

Көч-хәл белән торып аякка бастым. Арка сөягенә меңнәрчә энәләр кадалган төсле тоелды, тубык башы да нык кына бәрелгән иде, ахрысы. Ялтырап торган кара «Мерседес» юлга аркылы туктап калган. 17-18 яшьләрдәге дүрт егет бамперы килеп төшкән машина тирәли әйләнгәләп йөриләр, ачык ишекләреннән, агарып, шардай кабарган куркынычсызлык мендәрләре күренә. Үземнең машинага күз салдым. Карарлыгы калмаган: арткы өлеше умырылып кереп киткән, фонарьга бәрелгән алгы як – гармун күрүге төсле. Ярый чыгып очканмын дип шатланасы гына. Тегеләр бәхәсләшә-сөйләшә миңа якынлаштылар. Берсе – машинамны, үземне телефонына төшереп алды.

– Синең, лузер, күзең чыкканмы әллә? Нигә әзрәк карап йөрмисең? – дип, бер каратут йөзлесе кулларын болгарга тотынды.

– Сез килеп мендегез бит минем машинага. Хәзер ГАИ чакырам, – дип, телефонны чыгардым. Кырыйда торганы ялт кына телефонны суырып алды кулдан.

– Миңа гаишниклар кирәкми, – дип, һаман үзенекен тукыды теге кара чутыр. – Бабамның бүләгеен онталкан ясадың. Беләсеңме күпме тора мондый машина? Ремонт өчен кимендә миллион ярым кирәк булачак. Праваң да юктыр әле синең...

Мин, аны-моны уйламый, документны кесәдән эзләп алдым. Теге яндагысы тагын җитез кыланып, праваны да үз кулларына күчерде.

– Бездә булып торыр хәзергә, – диде башлыклары. – Телефон номеры язып бирегез үзенә. Ремонт синең өстә. Миллион ярым. Өч көн вакыт сиңа, өч көннән соң кирәкле сумманы хәстәрләп шалтыратырсың.

Мин нәрсәләрдер әйтергә маташтым, үземнең хаклыгымны хакладым. Әмма тыңлаучы булмады. Телефон номеры язылган кәгазьне кулыма тоттырдылар да, машиналарын үкертеп, күздән югалдылар.

Телефонны кире биргәннәр иде тегеләр, ялгызым калган булсам да, юл хәрәкәте сакчыларына шалтыраттым. Нәрсә булганын бәйнә-бәйнә сөйләп бирдем. Шикләнеп кенә тыңладылар болар. Шаһитлар юк, якынтирәгә камера да эленмәгән.

– Син барысына үзең гаепле бугай, – диделәр соңыннан. – Ярый да страховкаң булса. Ә бу тимер калдыкларын эвакуатор чакыртып олактыр берәр яры.

Гөлүсәнең күз яшьләре, битәрләүләре җелегемне киптерде, тормышның яме китте. Шулай да машинаның яраксыз хәлгә килүен мин җиңел кичердем. Йөрисен йөргән иде инде, хакы да шул чаклы гына. Баш сау булса, яңасын алырмын берәр заман. Их, шуның белән генә бетсә икән күрәчәкләр...

Төнге сөйләшүне җитди кабул итмәгән идем. Үзләре килеп бәрелгәннәрен белеп торалар лабаса. Суд юлында йөртмәгәнгә рәхмәт әйтсеннәр. Әмма теге каратутлы егет мине эзләп тапты өч көннән соң. Проходной янында көтеп торган. Янында ике әзмәвер баскан.

PRESSA.RU

– Проблеманы хәл иттеңме? – ди бу. Мине иске танышы күреп, елмая үзе. – Синең турыда белештеләр егетләр, – дип, башы белән әзмәверләргә ымлый. – Фатирың барлыгын белдек. Ипотеканы түләргә дә түләргә икән. Анысы комачауламый, юристлар аңлаттылар. Иртәгә шалтыратасың, каршы алырлар үзеңне, бергәләп фатирыңны минем исемгә күчерерсез. Ярдәм итүче белгечләр булыр. Тәртәгә тибәргә уйлама, кызың, хатының барлыгын онытма. Мин алар турында да беләм. Тагын язып бирегез моңа номерны, йә югалткандыр. Үзенекен дә алыгыз, – дип фәрманнар бирде.

– Нигә алай сөйләшәсең минем белән? Закон дигән нәрсә бар, дөреслекне исбатларлар. Кем булдың ул кадәр? – дип катырак сөйләшергә булдым.

– Ментлар буйлап йөрергә киңәш итмәс идем, барыбер файдасы булмас. Кем дигәннән, мин – патша. Нурбәк Асаев дигән кеше. Ишеткәнең юк идеме? Патшаның һәр әмере кичекмәстән үтәлергә тиеш.

Кырт борылып китеп барды. Шул чакта гына күңелемә курку керде. Болар һич тә шаярып сөйләшми бит! Фатирны даулап йөрүләре көн кебек ачык. Күпме җанкыярлар бөтереләдер бу тау егете тирәсендә, кем белсен?

Әмма аларның кубызына биергә җыенмый идем мин. Шундый авырлыклар белән алган фатирымны, бер дә юкка бер адәм актыгына биреп куяргамы? Алай да саклык чаралары күрергә булдым. Хатыныма барысын аңлатып бирдем. Минем уемча, Гөлүсә бала белән беразга авылга әниләренә кайтып торырга тиеш иде.

– Нигә эш калдырып йөрим мин? – дип чәпчеп чыкты Гөлүсә. – Эштән язарга җүләрме әллә мин? Көн сорап, баланы иртәгә кайтарып куярмын.

Миңа дә бала ышанычлы урында булса, шул җиткән төсле тоелды.

Смена бетмәгән иде әле, телефоным шалтырады. «Хатыныңны авыр хәлдә безнең больницага китерделәр», – дип хәбәр итте кизү сестра. Күргәннәрем коточкыч иде. Гөлүсәнең кайтканын каравыллап торганнар да, берсе аның битенә кислота сипкән...

* * *

Артык зыяны булмады селтенең миңа. Вакытында кар белән ышку да ярдәм иткәндер. Куртканың киярлеге калмаган инде анысы, эреп кенә төшкән. Бит алмасы атна эчендә ямалды: итенә барып җитә алмаган зәһәре. Менә бер күзсез калдырды инде, нишлисең, күрәчәктер... Ул көнне Дамирны миңа якын да китермәделәр. Реанимациядән палатага күчергәч кенә керә алды ул. Минем баш-бит ак биләүдә, бер күз генә елтырый. Яраның әрнүләре үзәккә үтә. Ул бер сүз әйтмәде, мин дә әйтерлек хәлдә түгел идем. Ярый кызыбыз бу тетрәнүләрдән еракта иде...

* * *

Кич тагын шалтыраттылар. Монысы Нурбәк иде.

– Минем дустым синнән иртәдән кичкә кадәр хәбәр көткән дә үзе хакында исеңә төшерергә булган. Аңлагансыңдыр безнең шаярмаганны... Тагын өч көн уйларга вакыт сиңа. Аннан бар кәгазьләреңне алып кил. Кайда килергә өстәп хәбәр итәрбез. Яхшылап уйла...

Монда уйлыйсы-нитәсе түгел. Мине яклар, аралар кеше юк. Закон сакчылары да битараф минем кебекләргә, җәмгыятькә дә кирәгем шулкадәр генә. Канга-кан гына бу очракта. Гаиләмне, якыннарымны яклап басмасам, сукыр бер тиен минем бәям.

Иртәдән тагын больницага юлландым мин, эш кайгысы китте. Поликлиниканың залында утырганда берсеннән-берсе аяусызрак планнар кордым. Уйларымда гына Нурбәк белән күзгә-күз очраштым, аның кара каннарын агыздым, бугазын чәйнәп өздем, йөрәген суырып алдым. Йөрәгем гел үч алу нияте белән типте. Соңыннан нәрсә буласы башыма да кереп чыкмады. Төрмәгә озатсалар да, җанымны кыйсалар да, шатланып кабул итәчәкмен. Әмма дошманым аяк астында аунасын башта. Күңелемдә мондый тойгылар яралырга мөмкинлеген белми дә идем моңарчы...

* * *

Бик өзгәләнеп карап калдым Дамирым артыннан. Киребеткән ул, берәр уй күңеленә килсә, өзми дә куймый. Берәр күңелсезлеккә тарымасын дип курыктым.

Хатын-кыз күңеле сизгер бит ул. Уйлаганым юш килгән. Очрашкан ул дошманнары белән. Үзенчә үч алырга уйлагандыр инде. Андый башкисәрләр минем Дамир ише йомшак затларга ирек куямы? Мин чыгарга да өлгермәдем, дүртенче көнем идеме больницада, ирең не китерделәр, диде персоналдан берсе.

Менә хәзер мин йөрим аның янына. Карар җирен калдырмаганнар кабахәтләр, изгәннәр генә. Тернәкләнеп китә алса гына ярый инде. Теге бәндәләр дә терелгәнен көтәләр, дип сер сөйләделәр миңа. Аварияга эләккән машинаның хакын түләтергә. Шуңа кабергә кертми торулары, ди. Чукынып китсен лә фатиры. Авылга да кайтып китәргә булыр иде. Баш исән булсын. Тагын тынычсызлана башлады, җаныем. Нәрсәдер әйтәсе килә шикелле. Аның һәр әйткән сүзен аңлыйм, колагымны терим дә йөрәгенә... Безнең йөрәкләр бергә тибә бит.

* * *

«Усал кешеләр күп бу җирдә, Гөлүсә...» – «Күпләр икән шул, Дамирым, без белмәгәнбез генә». «Кара болыт булып кояшны каплаган кара эчле кешеләр, Гөлүсә». – «Кояш көн дә чыга, Дамирым, бервакыт таралырлар ул болытлар». – «Мин сине барыбер яратам, Гөлүсә, нинди булсаң да яратам...» – «Мин дә сине яратам, Дамирым...» – «Без бәхетле булырга тиеш, Гөлүсә, кызыбыз алдагы көннәрдә бәхетле булсын дисәк...» – «Без тырышырбыз бәхетле булырга, Дамир». – «Яхшылык күбрәк бу җирдә, Гөлүсә. Шулай булмаса, җир җимерелер иде күптәннән». – «Яхшылык өмет итик, Дамирым, яхшылык...»

Сезнең якларда ничегрәктер, безнең авылда читтә үлгәннәрне үз зиратыбызга кайтарып җирлиләр. Хәер, кайда да бер гадәттер инде.

ЯЗМЫШ ЫҢГЫРАШУЫ



Ләлә
КАМАЛИЕВА



Сугыш бара. Чернигов җирләре фашистлар кулында. Полина исемле украин кызы энесе белән бергә, кечкенә арба тартып, басуга йөри. Анда мал-туарга үлән, кайчак бодай башагы да табып була. Берзаман буш көлтәләр өеме янында ыңгырашкан тавыш ишетелә. Балалар, куркышып, тиз генә кире авылга йөгерә. Бу хәл турында әниләренә сөйлиләр. «Немецмы, безнекеме – барыбер кеше бит инде, алып кайтырга, ярдәм итәргә кирәк аңа. Тик бу турыда беркем белмәсен», – дип кисәтә әниләре. Төнлә белән Полиналар тагын басуга китә. Яралыны арбага салып өйләренә алып кайталар да базга яшерәләр. Исемен сорыйлар. «Вәдүт» дигән исем украиннар өчен сәер тоела, үзләренчә «Вася» дип йөртә башлыйлар.

Вәдүт ничек көлтә өеме астына килеп эләгә соң? Безнекеләр, Украинаның көньяк-көнчыгышын фашистлардан азат итеп, Чернигов ягына якынлаша. Каты сугышлар бара. Немецлар яралы солдатларны атып үтерә баралар, ә эшкә ярардай яшьләрне ат абзарына кертеп ябалар. Дошманның хәле мөшкел була, хәтта яралыларны сакларга сакчы да калдырмыйлар. Бернично әсир абзар астын казый да шуышып чыгып качалар. Вәдүт тә көч-хәл белән шул көлтәләр астына килеп җитә. Төннәр кыска, таң тиз ата. Тагын дошман кулына эләксәң, исән калу юк. Безнең армия якынлашу да Вәдүттә өмет уята.

Вәдүткә 25 яшь, Полинага да шул чама. Ике яшь йөрәк арасында мәхәббәт уты кабына. 1943 елның көзе якынлаша. Тик күңелдә аңлашылмый торган халәт. Беренчесе – шатлык: безнекеләр Чернигов өлкәсендә, икенчесе – аерылышу сагышы. Менә Анисимовка авылына да безнекеләр керә. Егет, сугыш беткәч Полинага өйләнергә вәгъдә биреп, хушлаша. Аны Горький шәһәрендәге госпитальгә озаталар. Аннан чыккач, тагын сугышка китә. Вәдүт картограф, автоматчы, авиация дивизиясендә яшерен часть начальнигы урынбасары булып хезмәт итә. 1946 елның көзендә генә, Берлиннан демобилизацияләнеп кайтышлый, Анисимовка авылына Полина янына керә. Тагын очрашу һәм тагын аерылышу. Вәдүт, Казанга кайтып, Полинага өйләнергә әнисеннән рөхсәт сорарга һәм кызны алып кайтырга хыяллана. Ләкин әнисе рөхсәт итми. 1930 елларда Яңа Сала авылыннан куылган мулла абыстае, әлбәттә инде, мондый никахка ризалык бирә алмый. Вәдүт ике ут арасында – әнисе сүзен тыңларгамы, кызга биргән вәгъдәсен үтәргәме? Беренче һәм соңгы мәхәббәтен, яраткан Полинасын, аңа биргән вәгъдәсен корбан итеп, анасына тугрылыклы булып кала шулай да. Ул – әнисенең исән калган бердәнбер улы бит! Дөрес, еллар узгач, Вәдүтнең әнисе үзенең сүзләренә үкенеп тә куя. Ләкин «поезд киткән» була инде.

Юк, китмәгән икән шул! 1985 елның җәендә «16 июльдә каршыла. 11 нче вагон. Полина.» дигән телеграмма килеп төшә. Вәдүт каршы ала, өенә алып кайта. Бер-берсенә карап, бер тын сүзсез утыралар. Полина апа, тезләнеп, аның аякларын кочаклап елый. Чал чәчле Вәдүт абый аны күтәреп торгызырга тырыша, яралы башы кинәт авыртып, үзе дә идәнгә сыгылып төшә. Бер мизгелгә бәхетле мәңгелек бәхетсез җаннар…

Полина апа Казанда өч көн кунак булып, киләсе җәйдә тагын кайтырга сүз биреп, китеп бара. Ләкин аларга кабат күрешү насыйп булмый. 1986 елда Чернобыльдәге авариядән соң поездлар йөрми башлый. Алдагы елда да күрешә алмыйлар – Вәдүт абый йөрәктән кинәт вафат була. Полина апа бу кайгылы хәбәрне ишеткәч, хат язып сала. Ул хатны укыганда күздән генә түгел, йөрәктән дә яшьләр тама. Аларның уллары туарга тиеш була, ләкин ул бала да җитлегеп туа алмый. Полинаны кияүгә сораучылар да була, ә ул бердәнбер мәхәббәтенә тугры кала. Ә бер елдан Полинаның да вафаты турында хәбәре килә.

Вәдүт абый Полина чигеп бүләк иткән сөлгеләрне комодында күз карасыдай саклады. Миңа бер сорау тынгы бирми. Ни өчен соң көлтә өеме астындагы ыңгырашуны нәкъ менә Полина ишеткән? Бәлки, бу аларның икесенең дә язмышлар ыңгырашуы булгандыр? Бәлки, аларга теге дөньяда гына кавышу мөмкин булгандыр?

Фотода: *Вәдүт абый Полина белән Анисимовка авылында. Украина. 1946 елның язы. Гаилә архивыннан.*

PRESSA.RU

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Журналны 1964 елдан бирле алдырам. Әле Дүшәмбедә яшәгәндә үк укый идек. Язмыш безне 1993 елда Таҗикстаннан Орел якларына китерде.

Гомер иткән җирләребезне калдырып китүебезгә гражданнар сугышы гаепле булды. Анда яшәгәндә дә яраткан журналымнан аерылмадым. Хәзерге вакытта Саратов өлкәсенең Маркс шәһәрендә яшим һәм бөтен шәһәргә берүзем «Сөембикә» журналын алдырам. Узган елның ноябрендә 78 яшемне тутырдым. Олыгаеп килсәм дә, илдәге вакыйгалар белән кызыксынып торам, сәяси хәлләрне уйлап борчылам, әмма барыннан да бигрәк мине Татарстанга һәм туган телемә бәйле проблемалар борчый. Телебезгә һөҗүм БДИ кертү белән үк башланды бит. Милли мәгарифнең киләчәге шактый уйландыра. Татарстанымдагы бу хәлләргә көенәм дә, аның уңышлары турында ишетсәм, сөенәм дә.

Дүшәмбедән Орел ягына качаклар сыйфатында күчеп килгәч, беренче мәлләрдә, ник монда кайттыгыз, Татарстанга түгел, дип аптырап сораучылар булды. «Алайга калса, Татарстанда да урыслар шактый күп, алар да үзләренең «Алтын бөҗра» территориясенә күчәргә тиеш буламы?» – дип, сорауларына сорау белән җавап бирә идем. Икенче яктан уйлап карасаң, Орел тирәләре дә минем тарихи ватаным. Элек безнең бабайлар яшәгән җирләр булган ул. Моның дәреслеген раслау өчен борынгы авылларның исемнәренә генә күз салыгыз. Халык арасында да татар фамилиясен йөртүчеләр күп. Әмма алар үзләре бу хакта уйланмый. Руслар белән якыннан аралашып яшәгәч, яхшы беләм: алар юмарт, киң күңелле халык.

Саф татар гаиләләренең, татар теле кирәкми, татар телен укытып, балаларыбызның вакытын сарыф итмәгез, дигән петициягә кул куюлары бик гарьләндерә. Хурлык бит бу! Үзләрен хөрмәт иткән бер генә милләт вәкиле дә үз телен кирәксезләр рәтенә кертми. Күбрәк телләр белгән саен, яхшырак бит инде. Әмма тел өйрәтү өчен дәреслекләр кулай, аңлаешлы, гади булырга тиеш. Үземнең оныгым Саратовтагы татар гимназиясендә укыды. Татар телен укыту методикасының никадәр катлаулы булуын күреп, шаклар каттым. Бу дәреслекләр белән укып, беркем дә сөйләшергә өйрәнмәячәк. Хәзер мин яшәгән Маркс шәһәрендә фәкать өлкән буын кешеләре генә татарча белә. Ә менә чит илләрдә туып-үскән татарларның үз телләрен югалтмаулары мине һәрчак сокландырды.

Татар халкының яңа талантлары хәзер рус телендә язып таныла. Әлегә кадәр халкыбызның батырлыгын гәүдәләндергән фильмнарның да булмавы кызганыч. Хәтта Бөек Ватан сугышында катнашкан каһарманнарыбыз турында да фильмнар юк бит. Югыйсә рейхстагка Җиңү байрагын да беренче булып татар кешесе кадаганын беләбез. Иван IV һәм Ермакка һәйкәл булып та, Казанны саклап шәһид китүчеләргә һәйкәл юклыгы да бик гаҗәп.

Асия КОТЛЫЗАМАНОВА.
Саратов өлкәсе, Маркс шәһәре.



Кеше тормышындагы иң авыр, иң газаплы хәлләрнең берсе – әниең белән мәңгегә хушлашудыр.

Без дә әниебезне 87 яшендә бакыйлыкка озаттык. Үлемтекләрен барлаганда, аның безгә дип язган бәхилләшү хаты килеп чыкты.

Әниебез Сәкинә Кама Тамагы районының Балтач авылы кызы иде. Шушында туып, шушында гомер кичерде. Без дә шушында үстек.

37 яшендә биш бала белән тол калды ул. Олы апага – 12 яшь, энебез Азатка 3 кенә ай иде. Безне – дүрт кызын һәм төпчеге Азатны кеше алдында ким-хур итми үстерде. Әни назын, яратуны да туйганчы бирде, эшкә, тормыш көтәргә өйрәтте. Әтиләре юклыгын сизмәсеннәр дип, алны-ялны белмичә эшләде.

Югары уку йортларын бетермәсәк тә, тормышта һәрберебез үз урынын тапты.

Энебез Азатның гына гомере кыска булды. Әнинең төп таянычы, нәсел дәвамчыбыз 26 яшендә, чәчү беткән көнне фаҗигале төстә вафат булды. Ул алдынгы тракторчы иде. Киленебез Гүзәлия ике бала белән тол калды. Кызларының берсенә – 4 яшь, икенчесенә 4 ай гына иде әле. Әни белән Гүзәлия (ул да шушы авыл кызы) гомер буе бергә яшәделәр, шатлыкны да, кайгыны да бергә кичерделәр. Сеңлебез кебек булды Гүзәлия.

Әнине сагынган саен, безгә атап язган хатын алып укыйм. Соңгы әманәте, соңгы васыяте, безгә соңгы кат ачылуы булган ул аның.

«Олыгаеп, хәтер югалтмыйча
Матур үттем тормыш юлларын.
Үз иткәнгә – соңгы хатым,
Чын дөресен яза кулларым.
37 яшьтә тол калдым мин,
Төкермәдем дошман алдында.
Чын дошманга чәй эчердем, дуслар,
Керфек какмый өстәл артында.
Мин егылдым, киптем, сүрелдем.
Нәфрәт уты дөрләп, терелдем.
Тол хатын дип көлмәсеннәр өчен,
Кабат авыр эшкә җигелдем.
Теш-тырнагым белән тырышып,
Ару-талу белми эшләдем.
Кирәк икән – телне алга җәйдем,
Кирәкмәсә, телне тешләдем.
Уйлап баксаң, минем тормыш юлы
Кырмыскадай эшләп үтте гел.
Ак алъяпкыч ябып йөргән чаклар
Бүгенгедәй минем истә гел.
Кирәк булса, йонын эрләдем,
Күлмәк-итәк тектем дусларга.
Кирәккәндә ташка кадак кактым,
Сер бирмәдем усал дошманга.
Горур булып, тап төшерми генә
Үттем кебек тормыш юлларын.
Бер дә тапсыз үтмәгәндер бәлки
Тол хатынның тормыш юллары.
Бәхетсез мин, диеп әйтә алмыйм,
Күңелләрем китек булса да.
Мин бәхетле, диеп китәм, дуслар,
Соңгы тамырларым корса да.
Китәм инде, соңгы хатым минем,
Соңгы тапкыр каләм кулымда.
Начар иде диеп сөйләмәссез,
Искә алып минем турыда.
Риза булып китәм, тормыш юлым
Артык кырыс булып үтсә дә.
Теге җирдә җавап табармын кук,
Газраилләр җәбер итсә дә.
Дус иткән, чынлап үз иткәнгә –
Соңгы хатым, соңгы сәламем.
Китәм инде, менә соңгы тапкыр
Кулларыма алдым каләмем.
Алла боерса, әле ахирәттә дә
Ак алъяпкыч бәйләп йөрермен.
Сәкинә исемемне югалтмыйча,
Оҗмахка да атлап керермен...

Бәхил булыгыз, өстемдә еламагыз. Яшь гомерем авыр үтсә дә, и-и Азат улым яши алмады, дип яшәдем мин. Ашарга утырсам, йокларга ятсам да: «Әй улым, син ашыйсы ризыкларны мин ашыйм бит, син йоклыйсы урында мин ятам бит», – дип елый идем. Баргач, очрашырбыз, бәлки.

Балалар, әгәр дә тагын күрә алмасам, барыгыз да бәхил булыгыз, бәхетле булыгыз».

Рәшидә НАСРЕТДИНОВА.
Буа шәһәре.



Илебез Бөек Җиңү бәйрәмен каршылый. Ни кызганыч, Ватан азатлыгы өчен җиңү яулап кайткан солдатларыбыз сафлары гына елдан-ел сирәгәя инде. Калмия авыл җирлегендә дә икәү генә калды алар.

Җамалетдинов Акмалетдин Җамалетдин улы 1926 елда Калмия авылында туып, өч класс белем ала, бик яшьли колхозда төрле эшләрдә эшли башлый. Армиягә 1943 елда алына. Илдә әле кайнар сугыш бара. Акмалетдин агага японнарга каршы сугышырга туры килә. Шул китүдән Ерак Көнчыгышта җиде ел хезмәт итеп, Харвии, Мутчии шәһәрләрен азат итүдә катнаша. Сахалинны азат итүдә дә аның өлеше бар. Бөек Җиңүне Калмия егете Сахалинда каршылый.

1950 елда туган авылына исән-сау әйләнеп кайтып, калган гомерен колхоз эшенә багышлый. Ун ел умартачы була. 1951 елда Мәфтуха апа белән тормыш корып, алты бала үстерәләр.

Ике ел элек 90 яшен тутырган Акмалетдин ага Бөек Җиңүнең юбилей медальләре, Бөек Ватан сугышының II дәрәҗә ордены, Японияне җиңгән өчен медальләре белән бүләкләнгән.

Икенче ветеранцыбыз – Миңнегәрәев Миңнемулла Гәрәй улы (фотода) 1927 елның 28 мартында Калмия авылында туа. Аның да бар белеме шул өч класс кына була. Укыйсы килмәгәннән түгел, мөмкинлеге булмаганнан.


1944 елны алалар аны сугышка. Өч аен Новочеркасскида хезмәт итә. Аннары Сталинградка эләгә, немец әсирләрен саклый. Бөек Җиңү көнен дә Сталинградта каршылый. Сугыш тәмамланса да, туган авылына тиз генә кайту насыйп булмый әле, сугыш җимерекләрен торгызуда катнаша. Ул да барлыгы җиде ел хезмәт итеп, Калмиягә 1951 елны гына әйләнеп кайта ала. Кайткач, колхозда тракторда эшли. 1979 елдан лаеклы ялга чыкканчы умартачы булып эшли. Миңнемулла абый да узган ел 90 яшьлеген бәйрәм итте. Аның да Бөек җиңүнең юбилей медальләре, «Германиядә җиңгән өчен» медале бар.

Бөек Җиңү бәйрәме якынайган көннәрдә аларның күңел хатирәләре кабат яңара. Сугыш тәннәрен генә түгел, җаннарын да яралаган агайларыбыз бүген дә ул дәһшәтле көннәрне сөйләгәндә яу кырында мәңгелеккә ятып калган иптәшләрен күз алдына китерә, аларны тирән ихтирам белән искә ала.

Энҗе ГАЛИӘХМӘТОВА.
Тукай районы. Калмия авылы.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA.RU



ГАШЫЙК БУЛДЫК! ГОАГА!



Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА

Һиндстанга очабыз!

Һиндстанга сәяхәт башлыча минем идея булганга, самолет трапыннан төшкәндә үк эчемнән тәкрарларга керештем: «Әйдә, Гоа, сынатма!» Бу гаҗәеп урынга ял итәргә килүчеләрне алдан ук кисәтеп куярга телим: аэропорттан ял урынына илтүче юл матур манзаралар белән күзне иркәләми. Сукбай этләр, чүп-чар, тукталышларда сәер кешеләр өере (гәрчә инде төннең икенче яртысы булса да), ташландык йортлар – кәеф котылгысыз рәвештә нульгә төшеп бетә. Кунакханәгә илтер юлда бер-беребезгә ләм-мим берни эндәшмичә бардык-бардык та, алдагы 10 көнгә безгә дип тәгаенләнгән йортка, ниһаять, кереп урнаштык. Ирем Нариман кара коелган. Күреп торам – теләге ничек тә булса тизрәк өйгә ычкыну. Минем дә кәефем әллә ни күтәренке түгел, шулай да Гоадан кайткан дусларның авыз суларын корытып сөйләүләре әкият түгелдер дип ышанасы килә бит.

Гоада пляж сезоны ноябрьдә башлана һәм май башында, яңгырлар вакыты килеп җиткәч кенә тәмамлана. Әмма Гоага апрельдә очарга да мөмкин – нәкъ менә бу айда анда манго сезоны башлана. Миңа апрельдә Гоа манголарын алып кайтканнары булды. Ышаныгыз, бу тәгам белән сыйланыр өчен генә дә очарга була анда!

Гоадагы ял итү формаларын өйрәнсәк, ике лагерьда торучыларны аерып карарга мөмкин: беренчеләре мопедтан башка монда бернишләп тә булмый дигән карашны яклаca, икенчеләре, бинт белән уралган туристларны күреп, бу куркыныч транспорт чарасына якын да килмәскә өнди. Без беренчеләр исемлеген тутырырга карар кылдык һәм мопедны сайлавыбызга сөенеп бетә алмадык. Дөрес, юллардагы трафик коточкыч тизлеккә корылган – зур-зур автобуслар янәшәдән генә колакны ярып кычкыртып уза, юл хәрәкәте сул яклы, юлдагылар олы бер кырмыска күчен хәтерләтә. Шулай да, берничә көн йөргәннән соң, мондагы кагыйдәләрне ваемлый, тәртипләргә көйләнә башлыйсың. Әйе, хәтәр итеп кистереп узып китәргә дә мөмкиннәр сине, юл уртасында кискен туктап калырга да, мондагы җирле халык, әнә шулай тукталып, үзара гәп сатып торырга ярата. Ачуың кабара башлаcа, сине шунда ук индусларның иркен, якты елмаюы тынычландыра. Авария ситуациясе китереп чыгарса да, ул шулкадәр тыныч елмая ки – син дә аңа ияреп елмайганыңны сизми дә каласың.

Байкны арендага алу урыннары шактый күп, бердәнбер шарты – 100 долларны алдан түләп кую. Бераз сатулашып, тәүлегенә 300 сумга гына арендалау бәхетенә дә ирешергә мөмкин.

Байкка утырудан катгый баш тартучылар өчен әйбәт альтернатива бар – автобуслар. Гоаның теләсә кайсы почмагына барып җитәргә мөмкин. Дөрес, еш кына кучеп утырырга кирәк була, әмма шулай кызыграк та. Автобуска кергәч, кая юл тотуыңны кычкырып





■ «Гаҗәепләр» җитәрлек – пляж яисә юл буйлап тыныч кына йөреп торучы сыерлар; сари кигән ханымнар вә туташлар; бер-берсе белән узышучы, сигналлары колакны ярган машиналар һәм автобуслар; тузанга күмелеп утыручы җәтә төсләрдәге борынгы йортлар; бормаланып, диңгезгә алып төшүче тар урамнар.

әйтергә кирәк, шулай иткән очракта, син анда, һичшиксез, барып җитәчәксең. Индуслар юл күрсәтергә, ярдәм итәргә, хәтта озатып куярга да һәрчак шат.

Без, инде югарыда әйткәнемчә, байкны сайладык. Анда җилдерүнең ни дәрәҗәдә тәэсирләргә бай булуын сүз белән генә аңлатып булмый. Барасың шулай юл буйлап, ә тирәягыңда төсләр һәм исләр тантанасы. Гади генә итеп әйтсәк, бу – гоалыларның җан халәте була инде.

Һиндстан үзенең «зәһәр» тәмләткечләре белән дан тота, әмма кафега кергәч, «Ноу спайси» (тәмләткечләрне артык күп салмагыз) дисәгез, сезгә уртача тәмләтелгән ризык китерәләр. Шулай ук менә дигән альтернатива – Европа кухнясы бар.

Нәрсәләрне авыз итеп карарга соң? Үземә ошаганнарын сезгә дә тәкъдим итәм. Бирияни (бу без ияләшкән пылауга охшаган ризык), чизи гарлик нан (сыр һәм сарымсак кушып ясалган көлчә, соңгысын һәр кафеда ашап карагыз, чөнки һәрберсендә ул – үзенә бертөрле), диңгез продуктлары, яңа гына сыгылган соклар.

Кеше күп җыелган кафены сайласагыз, ялгышмассыз – анда ризык та тәмле булачак, кәефегез дә күтәрелер. Нигездә, туристлар күп җыела торган урыннарда чекның уртача бәясе 1000 сумны тәшкил итә. Шулай да җирле халык сүзенә колак салсагыз, экономияләргә мөмкин: алар ике кешегә 500 сумга гына менә дигән итеп ашарлык урыннарны күрсәтәчәк.

Бу сәяхәтнең азагында Гоаны сайлавыбыз белән шулкадәр бәхетле идек – хәтта кайтасыбыз да килмәде.

Пляжда ята торган урыннары белән бергә кафесы да булган шаклар бихисап. Шунда гына капкалап та алырга мөмкин, шуңа туристлар шакларга күпләп урнаша. Ә аннан, әйберләреңне калдырып, рәхәтләнеп йөзеп тә килә аласың. Телефон, сумкаңны калдырып, менә шулай диңгездә кинәнеп ятарга була дип башыма да китерә алмый идем. Җитмәсә, кеше мыжлап торган пляжда! Ялгышканмын ла...

Урамдагы ризык – монысы бөтенләй аерым тема. Җирле халык әзерләп сата торган гамбургерлар, кукуруза, төрле азык-төлек белән тулы арбаларга адым саен юлыгасың. Мәсәлән, лайм сыгып, тозлап әзерләнгән кукурузаны ашап карарга була, ул чыннан да искиткеч, ләкин кайбер экзотик ризыкларга ышанып ябырылмаска киңәш итәр идем.

Фото: автор

PRESSA.RU



■ Байк – яшьләр транспорты, диючеләр хаклы түгел, аны урта һәм олы яшьтәгеләр дә бик яратып куллана.

■ Шулай итеп, креветкаларны лайм согы, лимонлы борыч һәм тозда тотып, маринадлап алганнан соң, күмер белән бераз матавыкланып, ниһаять, искиткеч тәмле ризыкны әзерләдек тә.



Гоаның һәрбер кафесында диярлек без ияләшкән ризыкны табарга була.

Диңгез продуктлары һәрбер шакта һәм кафеда тәкъдим ителсә дә, без үзебез пикник оештыру идеясе белән яндык. Нариманны әле Казанда ук креветкалардан шашлык әзерләү белән кызыктыра башлаган идем. Күз алдына гына китерегез: Гоада яр буенда учакта креветкалар кыздырабыз. Хәтта үзебез белән рәшәткә дә алып килдек...

Креветкаларны табу әллә ни кыен булмады: Мапуса шәһәрендә менә дигән балык базары бар. Без аннан 550 сумга гына бер кило «патша креветкаларын» сатып алдык. Ә менә күмер табу авыррак икән. Җирле халыктан сәгать буе сораша торгач, теләгебезгә ирештек тәки. Идеаль урынын да таптык: Кече Вагатор пляжы мондый исәр планнар өчен менә дигән икән! Байкның тагын бер уңай ягы – җаның теләгән урында җаның теләгәнчә итеп пикниклар оештыра аласың.

Язмамда Чапорадагы Джус үзәге (яңа сыгылган соклар үзәге) турында искә алмасам, нидер җитмәс кебек. Гоага ял итәргә барсагыз, анда сугылмый калмагыз, бер генә тапкыр булса да. Анда байкта да барып җитәргә мөмкин, автобуста да. Схеманы хәтерлисез, шулай бит: керәсез дә, кая эләгергә теләвегезне кычкырып әйтәсез. Монда искиткеч күләмдә төрледән-төрле соклар сайларга мөмкин: манго, маракуйя, ананас, бакча җиләге, кара һәм яшел виноград, банан... Сокларның кушылмаларын да авыз итә аласыз. Шулай ук сөт коктейле белән, ласси, җиләк-җимештән ясалган фирма салатын да тәкъдим итәчәкләр. Монда кемне генә очратмыйсың – хиппилар да, төрле илләрдән килгән туристлар да, рәссам индуслар да, сәүдә белән шөгыльләнүчеләр дә, шулай ук гәп корырга җыелган халык та. Кафе соңгы еллар эчендә чын мәгънәсендә күмәкләп җыелу урынына әверелгән. Андагы атмосфера – искиткеч! Без анда дүрт тапкыр бардык.

Гоа штатын ял урыны итеп сайласагыз, шунда ук берничә мәсьәләне хәл итәргә кирәк булачак. Беренчесе – көньяк Гоамы, әллә төньяк Гоамы? Көньяктагысында пляжлар чистарак, ял да тынычрак, кунакханәләр шәбрәк. Төньяктагысында пляжлар кайтышрак, алардагы ком ак түгел, әмма чүп-чар азрак, күңел ачу чаралары күбрәк, бәяләр түбәнрәк, ә кайбер кунакханәләр кайтып йоклар өчен генә хәстәрләнгән. Актив ял төрен якынрак күргәнгә, без төньяк Гоага тукталдык. Чиратта – пляж һәм, билгеле инде, аңа якынрак булган кунакханәне сайлау. Юлга җыенганда, төрле форумнардагы мәгълүматны укып, чагыштырып карап, тәмам пошаманга төшкән идек, шуңа да, баргач, безгә кадәр танышларыбыз тукталган кунакханәне сайларга булдык.

Һәм ялгышмадык: Кандолим шәһәре – ял өчен менә дигән урын. Әмма «бер урында бер көн дә туктальп тормыйбыз» дигән девизга тугры калып, без Гоаның барлык яр буе шәһәр-авылларында булып чыктык. Алга таба сезгә төньяк Гоадагы иң кызыклы урыннарның исемлеген тәкъдим итәм. Калангут шәһәрендә туристлар бик күп, шулай ук индуслар да шактый. Соңгылары Һиндстанның төрле почмакларыннан агыла, шуңа да пляжларда халык мыжлап тора. Кандолимда исә туристлар кимрәк, ул ял өчен дә затлырак урын санала. Багада индуслар бик күп, алар бирегә ял көннәрен уздырырга килә. Сәүдә кайный, төнге күңел ачулар гаять шау-шулы. Анджуна авылы – нәкъ менә шушында 60-70 нче елларда беренче хиппилар килеп урнашкан булган. Хәзер инде хиппилар ул кадәр күп түгел, шулай да формаль булмаган публика шунда ук күзгә ташлана. Чәршәмбе көннәрендә биредә «хәерчеләр базары» эшли, ул Флимаркет дип атала. Кайчандыр бу базарда беренче хиппилар үзләренең хендмейд-товарларын тәкъдим иткән, бүген исә бу искиткеч зур базар, һәм биредә җаның теләгәннең барысын да табарга мөмкин...

Әгәр сез тыныч ялны кулайрак күрәсез икән, Вагатор, Морджим, Ашвем һәм Мандрем пляжларын сайларга киңәш итәм. Безгә иң ошаганы Мандрем булды, биредә пальмалар белән наратлар аралашып үсә, туристлар аз, тыныч һәм иркен.

Гоа экскурсияләр белән әллә ни дан тотмый. Әмма әлеге штатның хозурлыгы экскурсияләргә бәйле түгел, ул – ял өчен менә дигән урын. Шулай да бер-ике эскурсиягә чыгып керү комачауламас.

Туроператорлар, гадәттә, экскурсияләрнең ике төрен тәкъдим итә – бюджет төрен һәм бюджет



Тәмләткечләр белән шыплап тулган сәүдә урыны да бар – рәхәтләнеп сатып ал җаның теләгәнне! Дөрес, бәяләр югарырак, әмма бу урынны ышанычлы, диләр.

Һиндстанда филләрне эксплуатацияләү тыела, әмма биредә – плантациядә аларга утырып йөрергә, филләр белән бергә су керергә рөхсәт итәләр.



түгелен. Миңа калса, Гоа буенча күзәтү экскурсиясенә, һичшиксез, барып кайтырга кирәк. Бу экскурсия Гоаның башкаласы Панаджины, Борынгы Гоаны һәм тәмләткечләр плантациясен караудан гыйбарәт. Маршрут Борынгы Гоадагы Шантадурга храмыннан башланып китә. «Шанта» «тынычлык» дигәнне аңлатса, «дурга» «көч» дигән сүз. Храм исеме бу ике сүз кушылудан ясалган.

Индуизм – безгә шактый ерак, ят, каршылыклы тоелган дин. Әмма бу гыйбадәтханәдә булганнан соң, аның асылына ныграк төшенәсең. Без Джатра дигән бәйрәм көненә туры килдек, храм эчендәге йолаларны үз күзебез белән күрү бәхетенә ирештек. Әйтүләре буенча, мондый чакта гыйбадәтханәгә туристларны бик кертмиләр икән, әмма безгә рөхсәт иттеләр. Шантадурга исемле курчакны коендырып-киендерүдән гыйбарәт иде бу йола. Соңыннан сөйләделәр: аңа кадәр әлеге курчакны төн буена затлы итеп бизәлгән җиде катлы арбада йөрткәләр икән. Мондагы храмнарда Аллалар дип исәпләнгән курчаклар бихисап. Руханилар карап-тәрбияләп тора аларны.

Алга таба маршрут буенча безне католик храмнарга алып киттеләр – Изге Екатерина соборы белән Бом Жесус базилигы хозурына. Христиан динен тотучылар сан ягыннан биредә икенче урында тора булып чыкты.

Храмнарны караганнан соң, рус телендә сөйләүче һинд экскурсоводы безне плантацияләргә алып китте. Туристлар өчен хәстәрләнгән махсус паркта бу илдә үскән барлык тәмләткечләр дә тупланган булып чыкты. Экскурсоводыбыз, тегеләр яки бу яфракны өзә дә безгә күрсәтә: «Таныйсызмы?» – ди. Өйдәге кухняда дәфнә яфрагын да, куркума белән кызыл борычны да гел кулланасак та, бер генә тәмләткечне дә таный алмадык.

Маршрут Гоа башкаласы Панаджида тәгәлләнә. Безгә бу шәһәрдә өч сәгать йөрергә мөмкинлек бирделәр. Шәһәрнең атмосферасына күмелер өчен кирәк иде бу. Панаджида безне кибетләр, Изге Мариянең Ару Балага узуы (непорочного зачатия Девы Марии) соборы һәм португал кварталы җәлеп итте. Кайчандыр Португалиядән килгән колонизаторлар төзегән йортларны карап йөрдек. Болар – тар гына урамнарда урнашкан җете төсләргә буялган ике катлы ыспай өйләр. Бу урынны Португалиянең үзен хәтерләтә, диләр.

Мәчеткә дә кереп чыктык. Гоадагы халыкның 10% ы мөселманнар булып чыкты. Көтелмәгәнчә яхшы кәеф бүләк итте бу хәбәр.

Гоага очканда бу илне, аның кешеләрен, атмосферасын йә чын күңелдән яратачагыма, йә, киресенчә, тизрәк онытырга тырышачагыма ышанып бардым. Хәзер исә

Монда һәркем җанына якын булган нәрсә дә булса таба ала.

анда уздырган көннәрем искә төшкән саен, җанымны бәхетле тойгылар биләп ала. Гоага гашыйк булмау мөмкин түгел! Әйе, кунакханәләрдәге сервис яхшырак та була алыр иде, билгеле, чүп-чар да кәефне төшерә, пляжлар да кардай ак түгел. Әмма урынның атмосферасы бу факторлардан, пунктлардан гына тормый. Байкта тар урамнардан барган мизгелләр һаман-һаман искә төшә: кояш, кинәнеп, сине назында коендыра, төсләрдән күз камаша, хуш исләрдән тәмам исерәсең, ә инде тирә-юньдәге тавышлардан бөтенләй яңадан тугандай буласың. Әнә шулай итеп үз нирванаңа юл ачыла...

Гоада, һичшиксез, кирәк

- Анджунадагы Флимаркетта булырга;
- Панаджидагы португал кварталында йөрергә;
- Фортларга барырга: аннан диңгезгә искиткеч гүзәл манзара ачыла;
- ризыкларыннан авыз итәргә;
- күз явын алырдай кояш баю күренешләренә сокланырга;
- Апрордагы төнге шимбә базарын барып күрергә;
- Чапоре үзәгендәге Джус үзәкне күрергә;
- җаның һәм тәнең белән рәхәтләнеп ял итәргә!

PRESSA.RU

16+

ЧЫН МӘХӘББӘТ МЕНӘ НИШЛӘТӘ!



Илшат ӘМИНОВ, «Татарстан–Яңа гасыр» телерадиокомпаниясенең генераль директоры; гаилә стажы – 33 ел; бер кыз әтисе.

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән?
Сүзне аларга бирик.

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Башта күзләренә! Күзләр – күңел көзгесе, диләр: күзләренә карыйсың да, каршыңда утырган кешенең күңелендә ниләр барын күрәсең. Гомумән, хатын-кызның бөтен матурлыгы күзләрендә чагыла. Миңа шулай тоела.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Аларның барысына да бер кимчелек хас – һәрвакыт күп сөйләшәләр. Моны гафу итәргә, дөресрәге, ничек бар, шулай кабул итәргә кирәк. Табигать шулай яралткан инде аларны... Без, ир-атлар, хатын-кызны бик игътибар белән, башка нәрсәләргә бүленмичә тыңларга тиешбез. Чөнки ул һәрвакыт бик мөһим нәрсә турында гына сөйли – аңа шулай тоела... Тыңларга һәм ишетергә! Югыйсә эшләр харап. «Нишләп син мине ишетмисең?» – дип, бик еш битәрли алар безне. Уйланып китеп, әңгәмәнең башын оныткан чаклар да булгалый шул...

3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Хыянәт өчен, билгеле. Монда җавап бер генә була ала. Хәер, кешелек мөнәсәбәтләрендә дә шулай ул... Хатын-кыз хыянәтне күп вакыт кичерә, диләр. Ышанмыйм! Гафу иткән кыяфәт кенә ясый ул, чынлыкта – кичерми. Бу яра аның күңел түреннән китми, ул барыбер шуның белән яши, үз-үзен ашый. Аерылышмау әле бернәрсә турында да сөйләми бу очракта. Гаилә ул – социаль институт: ике кешенең юридик яктан рәсмиләштерелгән мөнәсәбәтләре генә. Ниндидер уртак малмөлкәткә, күчемсез милеккә ия булу, уртак балалар... Ә йөрәк – башка. Аны кануннарга буйсындыра алмыйсың. Әйе, кемдер кичерәдер дә, бәлки, әмма кичермәүчеләр күбрәк. Хыянәт – җан тынычлыгын ала, кешене эчтән җимерә. Авыр сорау бу...

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсы якынрак?

– Хатын-кызлар катлаулы затлар, минем аларның йә алиһә генә, йә хуҗабикә генә булганын очратканым да юк. Бүгенге дөнья зур тизлек белән үзгәрә. Мин үзебезнең эштә дә бик кызык хатын-кыз характерларын күрәм. Алар дөньяга бөтенләй бүтәнчә карый. Әле менә берсенең ире белән аерылганын ишеттем. «Ни өчен?» – дип сорыйм. «Ул миңа кызык түгел хәзер», – дип җавап бирә. «Ничек инде кызык түгел, өч балагыз бар бит», – дим. «Ә ул үсүдән туктады, күңелсез аның белән», – ди... Минем үзем өчен яңа күренеш бу. Янәшәсендә ир-ат кына түгел, бертуктамый рухи үсештә булган шәхес тә кирәк хәзер хатын-кызга.

5 Ир кеше өчен хатыны аңа дус та була аламы?

– Хатыныма: «Син минем иң якын дустым!» – дигән чакларда, ул моңа үпкәли. «Юк, мин дустың түгел, яраткан хатын-кызың!» – дип каршы төшә. «Минем өчен бу ике төшенчә арасында аерма бик зур, – ди ул. – Әнә дусларың... алар – башка, мин – башка», – ди. Мин, билгеле, аны аңлап бетермим... Хатын-кызның берсе дә дуслыкка гына риза түгелдер, алар бездән соклану, ярату көтә...

6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме?

– Билгеле, хәтерлим. Колхозга эшкә баргач булды ул... Тәкъдимне мин аңа шигъри юллар белән җиткердем. Калын бер дәфтәр тулы шигырьләр язып бирдем. Үзенә шуның кадәр шигырь багышлаган ир-аттан нинди хатын-кыз баш тартсын – ризалашты... Без аның белән беренче курста ук таныштык, бер группада укыдык. Өйләнешүебез исә бишенче курста гына булды.

Без беренче курска укырга кергәндә аның буе 175 сантиметр иде, ә минеке 168 сантиметр гына. Моның минем өчен нинди фаҗига булганын аңлыйсыздыр... Әни шул чакта миңа «Литературная газета»да чыккан бер мәкалә табып алып килде. «Перекладина»да асылынып торып, 10 сантиметрга үскән бер малай турында иде ул. Мин дә нәкъ ике ел асылынып тордым һәм 10 сантиметрга үстем. Булачак хатынымны да узып киттем! Дустым Альберт белән һәр көнне тулай торак янындагы мәктәпнең спорт

мәйданчыгына чыга идек. 30 яшькә кадәр – сөякләр тәмам ныгыганчы «үсәргә» була икән әле шулай. 10 сантиметр аз түгел инде ул – кайчак 1 сантиметр да бик мөһим. Үсәр өчен сәбәбем бар иде бит минем... Менә чын мәхәббәт нишләтә! (*Көлә.*) Юк, группадашлар берсе дә бу хакта белмәде: дустым Альберт та әни генә белде.

Мәскәүдә аспирантурада укыганда да хатыныма шигырь белән хатлар яздым әле – тәҗрибә зур минем! Өч ел аерым яшәдек бит.

7 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый, диләр. Шулаймы?

– Юк, юк, болар бер-берсенә берничек тә бәйләнмәгән. Гомер юлдашыңны ничек сайлаганыңны берничек тә аңлатып булмый аны... Әни белән хатыным уртак телне тиз таптылар. Әти белән генә катлаулырак булды – ул килененең татар булуын теләгән иде. Ә әниләр исә һәрвакыт безнең яклы бит, алар сине аңлый, син яраткан кешене дә кабул итә. Башка хатын-кызлардан әни кеше шул ягы белән аерыла да... Әнием бик позитив, ул мине: «Син – иң яхшысы!» – дип үстерде. Яшүсмер чакта тышкы кыяфәтем белән канәгать булмау проблемаларын мин дә кичердем. «И-и улым, ир кеше маймылдан аз гына матуррак булса, шул җитә. Ә син күпкә матуррак!» – дия иде ул. Моны ишеткәч, әлбәттә, тынычланам. Үз-үземә ышанычымны үстерә белде ул минем.

8 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Нигәдер тискәре менә... Иске стереотиплар кешеседер инде мин. Табигый түгел кебек тоела ул миңа. Хатын-кыз киләчәктә үзен генә түгел, булачак гаиләсен, балаларын тәэмин итәчәк кешене эзли. Ул сайлап алырга, ә без үзебезне тәкъдим итәргә тиеш.

9 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Ни гаҗәп – юмор хисе! Барысы да юмордан башлана. Әгәр хатын-кызны елмайта, көлдерә алдың икән, ярты юлны уздың дип сана! Кешедә юмор хисе булу аның акыллылыгын күрсәтә. Ә хатын-кыз, әйткәнемчә, иң беренче чиратта акыллы ир-атны эзли. Тормышта нәрсәгәдер ирешү өчен аның, иң беренче чиратта, акыллы булырга тиешлеген белә ул. Әлбәттә, тагын – ышанычлыны, көчлене, таяныч булырдайны эзли...

10 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу, чынлап та, шулаймы?

– Юк, алай түгел. Мин менә үземнең хатынымны бик чибәр дип саныйм, һәм бу мине куркытмады! Монда табигатьнең башка принцибы эшли: аның күңелен яулау никадәр авыр булса, ул сиңа шулкадәр кадерлерәк...

11 Ир-ат һәм хатын-кыз логикасы дигән төшенчә бар. Сезнеңчә, алар бер-берсеннән нәрсә белән аерыла?

– Ир-ат белән хатын-кызның фикер сөрешләре үк төрле аларның. Шуңа да бергә – 20, инде аннан да күбрәк ел яшәүләренә карамастан, еш кына бер-берсен аңламыйлар. «Когнитивный диссонанс» моментлары була. Яраткан гыйбарәм бу минем... Ир-ат белән хатын-кыз бер үк сүзләргә кайчак төрле мәгънә салалар. Һәм сукыр белән чукракның сөйләшүе башлана... Мондый очракта да бер генә юл кала: аңламасаң да, кабул итәргә кирәк. Югыйсә һәртөрле аңлашылмаучанлык конфликт белән тәгәлләнәчәк. Барыбер аңлашып булмаганын белгән килеш, сүзне нигә купертергә? Аннан ни үзгәрә? «Әйдә, оныттык та алга таба киттек», – дияргә бик җиңел түгел, әлбәттә. Әмма һәр гаиләне шушы коткара ала. Тагын – түземлелек. Бер-берсезне үзгәртә башласак, аның ахыры беркайчан да хәерле булып бетми – шуңа күрә түзәргә генә кала. Ике якта да түземлелек җитмәсә, гаилә яшәп китә алмый.

12 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез ачыгып, арыпталып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән.

– «Кайткан җиремә өстәлдә кайнар ризык көтсен», – дигәнем булмады. Моны беркайчан да беренче урынга куймадым. Нигә? Белмим... Шулай тәрбияләнгәнмендер дисәм, безнең өйдә башка тәртипләр иде. Иртән торам, үземә ботка пешерәм, кич кайтам, нәрсә бар – шуны ашыйм. Дәгъва белдергәнем юк: хатыным да бит өйдә генә утырмый, эшли. Төрле гаиләләр бар, билгеле. Мәсәлән, бер танышыма хатыны иртән токмач басып кисә. Һәр көнне! Яңа пешкән шулпада! Ә ул ир иртәнге җидедә инде эшкә чыгып китә... Һәр ашаган саен ике-өч төрле ризык әзерләүчеләр, ял саен өчпочмак-бәлеш, гөбәдия пешерүчеләр бар. Минем үземә бу кирәкми. Минем өчен бу мөһим түгел. Кыскасы, һәр гаиләнең үз әттәхияте.

13 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан.

– Бездә киресенчә: хатыным һәрвакыт алданрак җыена. Ә мин... мин гел нәрсәдер югалтам, өй буенча нидер эзлим. Йә сәгатемне, йә телефонымны... «Әнә күзлегең шунда ята», – ди ул миңа. Ярты көн эзләп тә тапмаган булам инде мин ул күзлекне... «Ә менә бу әйбер кайда?» – дип сорыйм. «Шунда», – дип җавап бирә ул. (Хатын-кыз һәрвакыт бөтен нәрсәнең кайда ятканын белә ул! Ничекләр белә – аңламыйм. Аптырыйм хәтта... Әмма гаилә өчен бик кирәкле сыйфаты ул аның!) «Әйберләреңне теләсә кайда ташлап йөрмә», – ди. «Ташламыйм, кайда туры килә, шунда калдырып кына торам», – дим. Нишләтәсең, иҗат кешесе шундый буладыр инде...

14 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша...

– Мин үзем моңардан проблема ясамыйм. Ә хатын-кыз менә бүләкне бик уйлап сайлый һәм синнән дә шуны таләп итә. Ул бүләк, һичшиксез, аның хатын-кыз икәнен искәртергә тиеш дип саный ул. Моны күптән аңладым. Бер тапкыр бик ялгыштым мин: хатынымның туган көненә кышкы тәгәрмәчләр наборы белән бергә дисклар бүләк иттем. Бүлмә уртасына өеп куйдым, матур итеп ленталар белән бәйләдем... «Нәрсә, син миңа дисклар бүләк итәргә җыенасыңмы? Алар бит миңа болай да кирәк иде, – диде ул аптырап. – Һичьюгы чәчәк бәйләме алырга идең». Тәгәрмәч тә бүләк булдымы, дип, чынчынлап үпкәләде. Алай икән... дидем. Хуҗалыкка болай да кирәк әйберне бүләк итәргә ярамый аларга: кухня комбайны, кер юу машинасы, кәстрүлләр... Хәер, кыйммәтле бүләкләр яратмыйлар дип тә әйтә алмыйм – яраталар.



Тулысынча сайтыбыздан укыгыз:
www.syuyumbike.ru

PRESSA.RU

ЯШЬ КАЛУ – СЫГЫЛМАЛЫ БУЛУ!

Иртә белән караваттан ватылып торасың кебек. Әйтерсең йоклаганда юрган түгел, таш плитә ябынгансың. Душ та тиешенчә ярдәм итми. Тормыш чүплегенә шуышып бару тойгысыннан кайнар каһвә дә коткармый. «Элек мин мондый түгел идем бит!» – дип уфтанып туйгач, баш миендә «Фитнеска язылып карарга мы соң...» – дигән фикер баш калкыта. Сәламәтлеккә һәм энергиягә таба беренче адым бу! Каршы якка шуышыр вакыт!

Җәмәгать! Берәр спорт комплексына язылсагыз, андагы табиб, тренерлар, яшегезгә, сәламәтлегегезгә карап, сезгә кайсы фитнес төреннән башларга, кайсы тренажерга игътибар итәргә, ничә тапкыр бассейнны урап чыгарга кирәклеген әйтер. Шуларны башкарасы кала. Интернеттан карап та шөгыльләнергә була анысы, әмма иң элек мәсьәләне җентекләп өйрәнегез. Хата белән башкарылган күнегү файда түгел, зыян китерә!

Фитнесның берничә төрен шәрехләп китик. Алар күп.

ЙОГА Җитди авырулары булмаган барлык кешегә файда гына китерә. Буыннарны тиз арада сыгылмалы итә. Берникадәр вакыттан соң нәрсә ашаганыгызга да игътибар итә башларсыз. Файдасыз ризыклардан баш тарту, уйларыңны чистарту, үзеңә, тирә-юньгә башка күз белән карау – физик һәм психик сәламәтлеккә илтә.

Бу – мөһим

- Утырдык, аякларны алга суздык. Кул белән аяк бармакларына үреләбез. Аякка башта эч, аннары күкрәк белән ятабыз. Бармакларны түшәмгә каратабыз. Пружина сыман селкенмибез – ярамый! Сулышны авыздан чыгарып, тагын бер-ике сантиметрга иеләбез. Арка туры булырга тиеш – бөкрәймибез.
- «Күбәләк»: ятып, тезләрне ян-якка салабыз, аяк үкчәләрен бер-берсенә тидерәбез. Сулышны авыз белән чыгарганда, аякның эчке ягы мускуллары киеренкелеген бетереп, тезне идәнгә яткырырга тырышабыз. Билне идәнгә кысабыз.
- Тренировкага 2-3 сәгать кала, углевод (карабодай, солы боткасы) белән аксымлы (пешкән тавык ите яки балык) ризык ашарга кирәк. Тренировкадан соң да ач тормагыз, чөнки аннары майлыга яки баллыга ябырылачаксыз. Бер стакан су эчеп, ярты сәгать ял итеп алыгыз да тамак ялгагыз. Кабат шул ук аксым, углевод.
- Тренировка вакытында кечкенә йотымнар белән су эчеп алыгыз.
- Тренажерларда үз фитнес-планың буенча шөгыльләнергә кирәк. Уйламыйча гына берсеннән икенчесенә сикереп йөрүдән файда юк. Кардиокүнегүләр, көчне арттыручы күнегүләр, тартылу – барысы да булырга тиеш.

ПИЛАТЕС Әлеге фитнес төре стресска каршы юнәлгән. Гәүдәне төз итәм дисәгез, пилатес – сезнеке. Остеохондроз, остеопорозларның профилактикасы булган пилатес йөкле һәм инде бала тапкан ханымнарга да ошар. Ябыгырга телисезме? Дөрес килдегез – «ныклык каркасы» дип танылган пилатес арка һәм эч мускулларын ныгыта. Тукلануны да тәртипкә китерсәгез, буй-сыныгыз төз булыр, әмма мускул массасы артмас, нәфис булырсыз.

Йөз ел элек уйлап табылган пилатес әле дә бик популяр. Күнегүләр салмак башкарыла, травмалар куркынычы бик түбән. Ул барлык мускулларны тоярга өйрәтер. Пилатесны ирләр дә читләтеп узмый!

Стретчинг (тартылу) – буыннарны, сеңерләрне тарттыру. Әгәр дә яшь калырга телисез икән, әлеге фитнес төрен үз итегез. Стретчинг йөрәк мускулын, арка, буыннарны ныгыта. Гәүдәгез төз булыр. Психик киеренкелектән арыну чарасы да әле ул! Тренажерларда тир түккәннән соң тартылырга кирәк – онытмагыз.

КАЛЛАНЕТИКА Мускулларны тарттыру һәм кыскартуга юнәлдерелгән статик күнегүләрнең комплексы җиңелләрдән түгел. Калланетика – йогадан алынган 29 статик күнегүдән гыйбарәт. Әлеге күнегүләрне башкарганда барлык мускуллар эшли. Матдәләр алмашуы көчәя. Муен, арка, умыртка авырткан кешеләргә ярдәм итәрдәй фитнес төре. Әмма спорт белән дуслашуны калланетикадан башламагыз. Башта җиңелрәк төрләрне сайлагыз, сәламәтлек юлына ныгытып басыгыз, югыйсә калланетиканы ерып чыгуыгыз икеле. Табиб белән киңәшләшеп кенә!

ШЕЙПИНГ – гәүдә формасын үзгәртүгә корылган ритмик гимнастика. Сикерәсе, йөгерәсе – күңелле!

Аэробика – йөрү, йөгерү, сикерүдән, сыгылмалылыкны арттыручы күнегүләрдән тора. Ул да төрләргә бүленә – сәламәтләндерүче, спортив, степ-аэробика, фитбол-аэробика һәм башкалар.

MIND & BODY ПРОГРАММАСЫ – артык майны «яндыра», сыгылмалылыкны арттыра, координация, тонус, балансны тәртипкә сала. Умыртка, буыннар белән проблемасы булган һәм актив күнегүләр ясарга ярамый торган кешеләргә кирәкле фитнес төре. Артык көч түкмичә генә селкенәсең дә ябыгасың. Шәп.

БОДИФЛЕКС – диафрагма белән сулыш алуга нигезләнгән программа организмның иң ерак почмакларын кислород белән баета. Сулыш аласың да кисәк чыгарасың. Артык килограммнар китә, мускуллар тонусы яхшыра, ябыкканда тирең дә салмак җыела – җыерылып калмый.

Урыныгыздан торып фитнес залга атылмаган булсагыз, тагын мәгълүмат бирик әле.

Утыз яшьлекләр

Бу яшьтә төрле авырулар баш калкыта башлый. Организм тиз арый. Тренировка вакытында пульс минутына 152 тибүдән артмаска тиеш.


Кырык яшьтән узганнар

Матдәләр алмашу процессы тагын да начарая, сеңерләр эластиклыгын югалта бара, гормональ үзгәрешләр күзәтелә. 40–50 яшьлекләрнең төп бурычы – мускул массасын саклау, тазармау, тарттырылу, буыннарны хәрәкәтчел итү. Күнегүләр вакытында пульсның минутына 144 тибештән артмавын тикшереп торыгыз.

Илле яшьлекләр

Эстроген гормоны кими. Сөякләр йомшый – остеопороз авыруы куркынычы яный. Вестибуляр аппарат та начар эшли башлый. Фигураны яхшыртуга юнәлдерелгән күнегүләрдән тыш, йөрәкне, координацияне, сөякләрне ныгыту мөһим. Пульс – минутына 120 тибеш.

Фитнес белән шөгыльләнә башлагач, бу хакта дусларыгызга да сөйләгез. Сезгә алар да кушылыр. Бергә күңеллерәк булыр. Өйгә кечкенә генә тренажер сатып алсагыз була, мисал өчен, мини-степпер. Кино караганда чәй эчеп утырганчы, атлау файдалырак. Махсус келәм, матур спорт киеме дә кәефегезне күтәрер!
«Шпагатка утырдым әле!» дигән хатларыгызны көтеп калабыз!



Инфографика: Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА

PRESSA.RU



Рафаэль ШӘВӘЛИЕВ,
Республика клиник балалар хастаханәсенең баш табибы

АЛЛЕРГИЯДӘН КАЧЫП БУЛАМЫ?

Бүген Россиядә һәр дүртенче бала аллергиядән интегә. Андыйларның елдан-ел арта баруына генетика да, әйләнә-тирә мохитнең пычрануы да, азык-төлекнең составы үзгәрү дә, башка сәбәпләр дә «гаепле».

Аллергиянең нигезендә катлаулы иммунологик механизмнар ята. Кайбер матдәләр менә шул механизмнарны эшләтеп җибәрә, нәтиҗәдә, балада аллергия барлыкка килә дә инде. Азык-төлек тә, өй тузанында яши торган талпан да, хайван кавыгы да, үсемлек серкәсе дә, күгәрек гөмбәсе дә, бөҗәкләр дә, дарулар да аллерген була ала.

Балада аллергия икәнлеге ачыклангач, беренче эш итеп, ул яши торган мохитне аллергеннардан арындырабыз. Бүлмә гөлләре, тузан җыя торган җиһазлар, китаплар, картиналар, шкафта тезелеп торган сувенирлар, келәмнәр, авыр пәрдәләр, йорт хайваннары белән хушлашырга туры киләчәк. Баланың бүлмәсен, шкафларын көн саен дымлы чүпрәк белән сөртеп чыгабыз, җыештырганда бала өйдән чыгып торсын. Көнкүреш химиясен баладан ераккарак яшереп кую хәерле. Өйгә һава дымландыргыч һәм кондиционер кую мөмкинлеге булса бик әйбәт.

Аллергияне ярсытучы тузан талпаның иң киң таралган төрләре – D.pteronyssinus, D.farinae һәм башкалар. Алар урамда дымлы һава булганда (сентябрь-октябрь, февраль-март) үрчи. Тузан талпанына каршы көрәштә гипоаллерген урын-җир, паразитларга каршы препаратлар, махсус фильтрлы тузан суырткычлар ярдәмгә килә.

Күгәрек гөмбәсеннән котылу өчен, өйдә чамадан тыш дымлылык булмауны тәэмин итегез: су торбаларын даими тикшереп торыгыз, душ кабинкаларын өч айга бер тапкыр хлорлы сыеклык белән юыгыз. Җиһазларны буйыйсы булганда, күгәрек алмый торган буяулар алырга киңәш ителә. Бүлмә гөлләрен киметергә яисә бөтенләй бетерергә, вентиляция системасын тикшереп торырга, сөлгеләрне ванна бүлмәсендә киптерергә, өйдә яшелчә һәм җиләк-җимеш сакламаска туры килер.

Россиянең урта полосасында үсемлекләр чәчәк атуның өч сезоны бар: апрель-май – агачлар, май-июль – болын чәчәкләре, июль-август – чүп үләннәре. Зур һәм хуш исле чәчәкләр түгел, ваклары аллергия бирә. Алар чәчәк атканда шәһәр читенә чыкмаска, тәрәзәне ачмаска, бүлмәне кондиционер ярдәмендә җилләтергә тырышыгыз. Бит-кулны башны еш юу, өйне дымлы чүпрәк белән сөрткәләп чыгу да бик мөһим. Мөмкинлеге булганнарга климатны алыштырып тору вариантын да карарга була. Үсемлек серкәсенә аллергия билгеле бер төрдәге ризыкларны үзләштергәндә дә кыенлыклар тудыра. Мәсәлән, агач серкәсе – чикләвек, төшле җиләк-җимеш, кишер, петрушка, зонтиклылар семьялыгыннан булган үсемлекләр, тәмләткечләрне; болын чәчәкләре – ипи, квас, солы ярмасы, каһвә, цитруслылар, бал, җир һәм каен җиләкләрен; кавын, карбыз, ташкабак, баклажан, горчица, көнбагыш һәм көнбагыш мае, хәлвә, майонезны чүп үләннәре «яратып бетерми».

Ризыкка аллергия, гадәттә, 3 яшькә кадәр була, аннан соң күпчелек очракта бөтенләй бетә.

Бер балага яраган әйбер икенчесенә ярамаска мөмкин. Шуңа күрә балада аллергия билгеләрен күзәтеп, көндәлек алып барырга онытмагыз!

Рөхсәт ителә

- итләрдән – күркә, куян, тавык (педиатр белән киңәшеп), ат, бәрән ите;
- боткалардан – карабодай, солы, дөге, тары, борчак боткалары;
- яшелчәдән – ташкабак, кәбестә кыяр, бәрәңге (крахмалга аллергия булганда, бәрәңгене 12 сәгатькә суга салып калдырырга һәм яхшылап юганнан соң гына пешерергә), топинамбур, сельдерей, яшел һәм башлы суган, петрушка, укроп;
- җиләк-җимештән – яшел алма, яшел груша, ак карлыган, ак һәм сары черешня;
- эчемлекләрдән – сыек кына яшел чәй, ак чәй (ароматизатор һәм башка өстәмәләр кушылган булмасын), газсыз минераль су, кипкән җиләк-җимеш яки рөхсәт ителгән җимешләрдән кайнатылган компот.

Аллергия бирә:

- Бодай онынннан пешерелгән ризыклар;
- үрдәк, каз, сыер итләре;
- тавык йомыркасы;
- сыер сөте, сыр;
- балык һәм диңгез ризыклары;
- җете төстәге яшелчә һәм җиләк-җимеш (аеруча цитруслылар, киви, ананас);
- гөмбә;
- туңдырма;
- шоколад;
- чикләвек (аеруча арахис);
- гөлҗимеш;
- бал.



БАШ АВЫРТУДАН ОСТЕОПАТ КОТКАРА

Баш авыртуның сәбәпләре дә, төрләре дә шактый. Иң төп сәбәпләрнең берсе – кан әйләнеше бозылу. Муендагы беренче умыртка сөяге блокадалана, нәтиҗәдә, аның аша кан узу кыенлаша, һәм кеше баш авыртуларыннан интегә башлый. Шулар хакында «Остеопат» медицина үзәге вертеброневрологы, остеопат Равил ГАЛИЕВ сөйли.

Бер тапкыр гына булса да башы авыртмаган кеше юктыр ул. Статистика күрсәткәнчә, таралуы ягыннан баш авырту, салкын тиюдән генә калышып, дөньяда икенче урында тора.

Европа федерациясе халыкара классификация булдырган, анда 13 төп группа һәм 162 төрдәге баш авыртуы кергән. Әле бу исемлекне дә тулы дип әйтеп булмый.

Шулай киң таралган булса да, баш авырту «мөстәкыйль» чир булып саналмый, башка авырулар вакытында барлыкка килә торган симптом «гына» булып йөри. Иң киң таралган баш авыртулары – нерв, акыл һәм мускул көчәнеше, спастик баш авыру (мускулларның көзән җыерып кыскаруы аркасында барлыкка килгән спазмнар) һәм мигрень белән бәйлеләре. Кайвакыт ул авыртуга түзеп булмый – башны читкә алып куеп торасы килә хәтта. Менә шундый чакта остеопат ярдәм итә дә.

Остеопатия кеше организмын өч берлектән торган система итеп карый: мускул-скелет, баш һәм арка миен әйләндереп алган мембрана эчендәге краниосакраль система (ягъни кешенең скелетын, умыртка баганасын, төгәлрәк итеп әйтсәк, баш сөяген оча башы сөяге белән бәйләүче сеңерләр) һәм вегетатив система. Әлеге системаларның берсенең генә булса да эшчәнлеге бозылса, чылбыр буенча башкалары да зарарлана. Нәтиҗәдә, остеопатик тайпылыш барлыкка килә.

Остеопатиянең өстенлекләре

- Дәвалау зыянсыз һәм авырттырмый. Табиб сугу яки төртү кебек хәрәкәтләр ясамый.
- Остеопатия ярдәмендә баш авыртуны дәвалауда яшь чикләүләре юк: олы яшьтәгеләрне дә, хәтта балаларны да дәваларга мөмкин.
- Остеопат баш авыртуыннан гына коткарып калмый, авыртуның башлангыч сәбәбен ачыкларга һәм аны тулысынча дәваларга да ярдәм итә.
- Остеопатия комплекслы дәвалау методикасы булып санала, шуңа күрә остеопат баш авыртуны гына бетерәм дип тотынса да, дәваланудан соң организмдагы бөтен системаларның эшчәнлеге яхшыра.
- Остеопатия сеансы һәр кешегә индивидуаль билгеләнә, шуңа күрә нәтиҗәле дә.
- Остеопатия иммунитетны активлаштыра, кан әйләнешен җайга сала, күзәнәкләрнең кислород белән туенуын тәэмин итә, шул сәбәпле, бөтен организмның сәламәтләнүе күзәтелә.
- Остеопат коррекциясе кешенең стресска каршы торучанлыгын ныгыта, бу исә нервлар какшау, депрессия, борчылу һ. б. сәбәпләр аркасында баш авырту барлыкка килмәсен өчен бик мөһим.
- Остеопатия баш авыртканда хәлне җиңеләйтеп кенә калмый, авыртуның кабатлануыннан да саклый.
- Остеопатия – баш авыртудан дәвалау чарасы гына түгел, бик яхшы профилактик чара да әле.

КИҢӘШ

- Башның еш авыртуы мендәрне дөрес сайламау аркасында да булырга мөмкин. Бик таза булмаган кеше һәрвакыт эченә ятып йокласа, аның мендәре бик юка булырга тиеш. (Мендәре калын булса, муен бөгеләчәк һәм кан тамырлары тагын да күбрәк «ябылачак».) Ябык кеше эченә ятып йокларга гадәтләнгән булса, бөтенләй мендәрсез йокласа да әйбәт. Мендәр аңа яны белән ятканда гына кирәк.
- Әгәр кеше машина йөртә һәм аны гел баш авыртулары борчый икән, баш артына махсус мендәр куярга кирәк. Кинәт туктаганда, кинәт кузгалып киткәндә ул муенны кискен тартылудан саклаячак.
- Башы сызлап интеккән кешегә йөзү белән шөгыльләнергә тәкъдим иткәннәр икән, йөзә белмәсә, тренерсыз суга керергә ярамый. Дөрес йөзмәү авыртуны көчәйтәчәк кенә.
- Гимнастика ясаган вакытта, башны алга, уңга яки сулга борырга гына тырышырга кирәк.

Остеопатия күзлегеннән караганда, баш авыртуны дәвалау – күпкырлы эш. Гадәти генә баш авырту кебек тоелса да, аны дәвалау өчен организмның сөяк, нерв, кан һәм башка системаларын да тәртипкә китерергә кирәк. Шуңа күрә остеопатия билгеле бер ноктадагы (бу очракта – баштагы) чирне генә дәвалап калмый, аның чыганагын да ачыкларга ярдәм итә, шул чыганакны дәвалый.

Остеопат – сизгер куллары ярдәмендә чирне тоеп алучы табиб. Ул фасция (органнарны, кан тамырларын, нервларны тоташтырып торучы тышчада), мускул, кан тамырлары, сөякләрдәге кечкенә генә үзгәрешләрне дә куллары ярдәмендә тоя һәм шул ук куллары ярдәмендә дәвалый да. Остеопат билгеләгән диагноз ниндидер кыйммәтле аппаратлар куйган диагнозга караганда төгәлрәк тә булырга мөмкин. Табибның сизгер куллары диагностик приборлар «күрмәгән» бик кечкенә тайпылышларны да тоярга, «тотып алырга» сәләтле.

Реклама хокукында. Остеопатка мөрәҗәгать итәр алдыннан табиб белән киңәшләшү кирәк.

PRESSA.RU



Өмеҗе – Барда татарлары телендә кура җиләге дигән сүз. Мондый бәлешне дә фәкать Барда якларында гына пешерәләр. Ә безгә аны Пермь кызы, яшь җырчы Чулпан ЙОСЫПОВА пешереп күрсәтәчәк.
Хәтерләсәгез, татар эстрадасына «Кыр казлары» җыры белән килеп кергән иде ул. Җыр-моң белән яшәгән әнисеннән күчкән бу талантын үстерү өчен, мәктәпне тәмамлауга ук туп-туры Казанга, мәдәният мәркәзенә юл тота Чулпан. Хыялы – фәкать җырчы гына булу. Казан дәүләт университетының музыка факультетын тәмамлый, берара театр училищесында вокал дәресләре бирә. Тамашачы аны тәүге тапкыр «Сандугач керде күңелгә» конкурсында күрә. Бүген инде Чулпан үзен тулысы белән иҗатка багышлаган. Аның бүтәннәрне кабатламас үз репертуары, үз тамашачысы бар. Әле тагын бер хыялы көтә – элеккеге ретро җырларга яңа сулыш өрү. Сәхнәдән бушауга ул тизрәк гаиләсенә, улы Солтан янына ашыга. Өйдә туры килгән сирәк минутларында тәмле камыр ашлары пешереп, якыннарын сыйлаудан ямь таба. Ул тәкъдим иткән бәлешне вакыт ягы бик чамалы булганда да пешереп өлгертеп була. Аңа нибары 20 минут вакыт кирәк.

ӨМЕҖЕ БӘЛЕШЕ



Кирәк:

- 3 йомырка;
- 120 г атланмай;
- 0,5 стакан шикәр комы;
- 2 стакан он;
- 300 г кура җиләге;
- 0,5 бал кашыгы чәй содасы һәм аш серкәсе;

крем өчен:

- 0,5 стакан кибет каймагы һәм 0,5 стакан шикәр комы.

Эш барышы:

■ тирән савытка йомырка сытып, бүлмә температурасында йомшартылган атланмай, шикәр комы салып, кашык белән бик яхшылап туглыйбыз.
■ Шушы сыеклыкка ярты бал кашыгы аш серкәсендә сүндерелгән чәй содасы кушабыз.
■ 2 стакан он салып, төерләре калмаслык итеп туглыйбыз. Камыр куе каймак кебек булырга тиеш.



Фото: Ксения Богданова

Камырны төбе майлы табага бушатып, кашык белән өстен тигезлибез.
■ Камырга батыра төшеп, өстенә кура җиләге тезеп чыгабыз. Кура җиләге урынына төше алынган чия яки кара карлыган да тәмле була.
■ Бәлешне 30 минутка 180–200 градус кызулыктагы мичкә тыгабыз.
■ Ул пешкән арада ярты стакан кибет каймагына ярты стакан шикәр комы туглап, крем әзерләп куябыз. Шикәр комы эреп бетәргә тиеш. Бер чеметем генә ванилин да куша аласыз.
■ Бәлешне мичтән алуга, өстеннән крем агызабыз. Чак кына аның бәлешкә сеңеп китkәнен көтәбез дә, матур итеп кисеп, табынга чыгарабыз.
■ Матурлык өчен өстенә уылган шоколад сибәргә, бөтнек яфрагы белән бизәргә мөмкин.
Чәйләрегез тәмле булсын!

Рушания Галиевадан

ТӘБИКМӘК



Кирәк:
- 3 йомырка;
- 1 л сөт;
- 1 бал кашыгы коры чүпрә;
- 1 бал кашыгы тоз;
- 3 аш кашыгы үсемлек мае;
- 1 аш кашыгы шикәр комы;
- 1 бал кашыгы чәй содасы;
- кирәгенчә он;
- кайнап торган су һәм майлар өчен атланмай.

Эш барышы:
■ Сөтне җылытып, аңа шикәр комы, тоз, чүпрә, үсемлек мае кушып, бераз куерак итеп камыр туглыйбыз.
■ Камыр күпереп менгәч, чәй содасы салып, камырга шаулап торган кайнар су агызабыз һәм кашык белән тиз-тиз болгатабыз. Камыр коймак камыры куелыгында булырга тиеш.
■ Пешергәндә беренче ике табаны майлыйбыз, калганнары өчен табаны майлыйсы түгел.
■ Тәбикмәкләрне пешереп бетергәч, һәрберсен эретелгән атланмай белән майлап чыгабыз.

PRESSA.RU



Май ул – чисталык ае. Ишегаллары, бакчаларда гына түгел, өйдә дә чисталык урнаштыра торган ай. Эш җитәрлек: тәрәзәләр юасы, гөлләрне коендырасы... Ялт итеп торган тәрәзәләргә ап-ак челтәрләр эләсе...

ТӘРӘЗӘҢ КӨЛЕП ТОРСЫН

Тәрәзәне рамыннан юа башларга кирәк. Порошоклы су иң шәп ысул түгел, чөнки ул буяуны тоныкландыра. Башка чара булмаса, кер сабыны белән юарга мөмкин.

Тәрәзә юу өчен махсус сыеклыклар алганда, составында силикон булганын сайларга тырышыгыз. Силикон тәрәзәләрне тиз пычранудан саклый.

Чүпрәк урынына губка куллансагыз, яхшырак. Чүпрәктән пыялада вак җепселләр кала. Микрофибрадан булган тастымал да кулай. Капрон колготки яки бумази тукыма да тәрәзәдә эз калдырмый. Кул җитмәстәй урыннарны юу өчен сабы озынная торган махсус җайланмалар да бар.

Тәрәзәләр чисталыгы белән озаграк балкысын дисәгез, юганнан соң, пыяланы глицерин, нашатырь спирты салынган су белән сөртегез.

Тәрәзәне соңгы кат чайкаткан суга бераз гына аш серкәсе өстәсәгез, пыяла ялтырап торыр. Өстәвенә, серкә исен чебен-черки дә яратмый.

Көлеп торган тәрәзәләргә ап-ак пәрдәләр кирәк. Әмма җәй буе кояш күзендә булган челтәрләрнең бер-ике елдан аклыгы югала, төсе китә. Пәрдәләрне агартуның гади генә берничә ысулын тәкъдим итәбез.

Кайсы ысулны куллансагыз да, башта пәрдәне урамда яхшылап селкергә кирәк. Икенчедән, юа торган суыгыз җылымса гына булсын. Кайнар суда юганнан соң, синтетик тукымадан тегелгән пәрдәне агартуы кыен.

Тоз белән агарту

Бер табак суда бер уч кер порошогы һәм 3-5 аш кашыгы эре тоз эретеп, пәрдәне төнгелеккә чылатып калдырыгыз. Иртән сыгып алып, бер-ике кат чиста суда чайкагыз. Бик керләнгәнен җылымса суда тагын бер кат юып алыгыз.

Синька белән агарту

Юган һәм ныгытып чайкаган пәрдәләрне 1 чәй кашыгы синька салынган 10 литр җылы суда чайкап киптерегез. Автомат машинада юасагыз, деликатлы режимны сайлап, кондиционер бүлеменә синька савытының бөкесе белән 1–1,5 бөке сыек синька салыгыз. Кибетләрдә синьканың автомат машиналар өчен дигәне сатыла.

Зеленка белән агарту

1 стакан җылы суга 5-10 тамчы зеленка тамызып, бер-ике минут болгаткалап торыгыз. Зеленка төпкә утырмаса, әзер дигән сүз. Әзер эремәне 10 литр җылы суга салып, пәрдәне 5-10 минутка батырыгыз. Берничә тапкыр әйләндергәләгәннән соң, сыгып алыгыз.

Водород перекисе һәм нашатырь спирты белән агарту

60 градус кайнарлыктагы бер табак суга 1 аш кашыгы нашатырь спирты һәм 2-3 аш кашыгы 3 процентлы водород перекисе салыгыз. Пәрдәләрне шушы суга ярты сәгатькә батырыгыз. Аннары сыгып алып, чайкагыз. Бу ысул фәкать киҗемамык тукымадан тегелгән пәрдәләр өчен генә!

Ә инде бик нык саргайган челтәрне башта чылаталар, аннары порошоклы су белән юып чайкыйлар. Шуннан соң нашатырь спирты белән водород перекисендә агарткач, бер кат тозлы суда чайкарга, иң соңыннан крахмалларга кирәк.

БЕЗ — ТӨРЛЕ-ТӨРЛЕ

Сезнең белән мин –
Гөлназ СӘФӘРОВА!
Иртәме-соңмы, һәр хатын-кыз үзендә җитешсезлекләр күрә башлый. Кемдер тазардым дип зарлана, кемгәдер, киресенчә, берничә килограмм җитеп бетми – бер сүз белән әйткәндә, һәр хатын-кыз үзен иң матуры итеп күрергә тели! Ләкин… күпләр, моңа зур акчалар кирәк, бездән булмас инде, дип кул селти, үз-үзләренә ышанмыйча яши башлый! Хатын-кызлар!!! Үзеңә ышанып, көзгегә туры карап, «мин матур» дип әйтер өчен алай күп тә кирәкми.
Бүген сезгә кием турында сөйләрмен. Дөрес сайланган кием фигураның җитешсезлекләрен яшереп, сезне яшәртеп күрсәтергә сәләтле! Матур, килешле кием кыйммәт була дигән гыйбарәне дә башыгыздан чыгарып ташлагыз. Хәзерге вакытта масс-маркетлар кулай бәядән бик күп заманча киемнәр тәкъдим итә. Кемгә нинди төс, нинди тукыма, нинди стиль килешкәнен сөйли башлаганчы, башта фигурагызның тибына ачыклык кертик.
Стилистлар һәм дизайнерлар фигураның дүрт төрен аерып чыгара.






«ӨЧПОЧМАК», ЯГЪНИ «ГРУША». «Өчпочмак» фигуралы хатын-кызларга чалбар-итәкләр сайлау аеруча авыр. Чөнки аларның җилкәләре, билләре – тар, ә аскы өлешләре киң була. Ерактан мондый фигура грушаны хәтерләтә.
Әлеге тип фигуралы хатын-кызлар пиджак-чалбар сайлый алмый интегә, чөнки гәүдәләренең өске һәм аскы өлеше үлчәме буенча бер-берсеннән нык аерылып тора.
Мондый тип хатын-кызларга гәүдәләренең өске өлешенә ачык төстәге кофталар сайларга киңәш ителә, буй-буй сызыклы булса, тагын да яхшырак. Билләре күтәртелгән чалбар-итәкләр дә фигураны җыйнаграк күрсәтә. Ә менә киң футболка-кофталар, сыланып торган ефәк күлмәкләр кию, калын каешлар тагу килешми.



«ТҮГӘРӘК», ЯГЪНИ «АЛМА». Гәүдә төзелеше «тһ1үгәрәк» тибына караган хатын-кызларның бил һәм күкрәк тирәли үлчәмнәре бер чама була. Формасы буенча мондый тип фигура түгәрәкне хәтерләтә.
Түгәрәк әле ул таза дигән сүз түгел, мондый тип фигуралы хатын-кызларның аяк-куллары, гадәттә, ябык була.
Шуңа күрә төп акцентны нәкъ менә кул-аякларга ясарга киңәш итәбез дә. Мондый очракта сезгә сыланып торган чалбар, күлмәкләр бөтенләй килешмәячәк. Биек үкчәле туфлиләргә, киңәеп киткән күлмәкләргә, туры балаклы чалбарга, озынча мәрҗәннәргә өстенлек ясау отышлы булыр.
Мондый тип фигуралы хатын-кызларга каешлар, муенлы свитерлар кию катгый тыела!



«ТУРЫПОЧМАКЛЫК». Мондый фигура җилкә, бил һәм янбаш үлчәмнәренең бертигез булуыннан гыйбарәт. Гадәттә, подиумнардагы модельләрдә очрый.
Әгәр фигурагыз турыпочмаклыкны хәтерләтә икән, сезгә спорт белән ныклабрак шөгыльләнергә һәм дөрес тукланырга киңәш ителә.
Нәрсә кияргә?
«Турыпочмаклык» тибындагы фигуралы хатын-кызлар, билләренә акцент ясап, киң каешлар тага ала. Киң «oversize» киемнәр өстеннән буылган билбаулар да отышлы күренәчәк. Күлмәкләр сайлаганда тездән чак кына түбән озынлыкка өстенлек бирергә кирәк.
Коко Шанель, экстравагант Жаклин Кеннеди, элегант принцесса Диананың да фигуралары шушы типка кергән.



«КОМ СӘГАТЕ». Монысы – фигураның идеаль тибы: җилкә киңлеге белән янбаш киңлеге бер үлчәмдә, ә бил – нәзек. Сигезле силуэтлы хатын-кызларга бөтен нәрсә дә диярлек килешә.
Сыланып торган күлмәкләр, ефәк тукымалар, лосиналар – барысы да гәүдәгә ятып торачак. Тагын да матуррак күренер өчен, билегезнең нечкәлеген ассызыкларга онытмагыз!



PRESSA.RU

Яхшы уңышның сере – яхшы туфрак. Без моны бик яхшы беләбез, шуңа да казыйбыз, ашлыйбыз. Әмма... еш кына уңышны җыярга өлгерми дә калабыз. Мәсәлән, помидорны, борычны. Көтмәгәндә генә бер томан төшә дә бар тырышлыкны юк итә дә куя. Ә бит гаеп томанда түгел, ә туфракта. Дөресрәге, анда чир китереп чыгара торган гөмбәләрдә. Барыннан да бигрәк, бакчачыларны фитофтора чире аптырата. Көзен уфтанмас өчен көрәшне менә хәзердән, җиргә орлык салганчы ук башлыйк.



Фото: www.pixabay

ТУФРАККА ДӘВА КИРӘК

■ Бәрәңге һәм помидор утыртасы җиргә иртә язда 1-3 процентлы бакыр купоросы эремәсе сибеп чыгыгыз. Җирне казыгач, тагын бер тапкыр «Фитоспорин М» эремәсе бөркергә кирәк.

■ Фитофтора бакча җиләген дә зарарлый. Җиләклекне химик матдәләр белән эшкәртү зарарлы. Монда инде «Алирин»ише биологик чаралар ярдәмендә эшкәртәләр.

■ Составында бакыр булган эремәләр сиптергәннән соң, бу түтәлдәге яшелчәләрне кимендә бер ай кулланмый торалар. Шуңа күрә химик матдәләрне иртә язда, бакчага керү мөмкинлеге туу белән сиптерергә тырышыгыз. Биологик препаратлар кулланганда андый тыю юк, аларны теләсә кайчан кулланырга була.

■ Узган елдан бакчада калган чүп-чар да фитофтора тарата. Көздән бакчадагы барлык чүп-чарны түгегез яки яндырыгыз. Теплицага аерым игътибар бирегез, анда да узган елгы помидор сабаклары өелеп калырга тиеш түгел.

■ Язын теплицаның өске туфрак катламын яңага алыштырсаң, бигрәк тә яхшы. Ишек-тәрәзәләрен ныгытып ябып, күкерт шашкасы яндыру да яхшы нәтиҗә бирә.

■ Бәрәңге һәм помидорны туфракка утыртыр алдыннан «Фитоспорин» эремәсе белән эшкәртегез.

■ Орлыклык бәрәңгене көздән үк яшелләндереп калдырсаң – ышанычлырак. Кояш нуры – бәрәңге бүлбесендәге гөмбәчекләргә каршы иң яхшы чара.

■ Үсемлекләрнең төбен үлән яки вакланган печән белән каплау да яхшы нәтиҗә бирә. Фитофторага артык җәелергә ирек бирми ул.

Фитофторага каршы халык арасында популяр һәм нәтиҗәле ике ысулны да әйтеп китик әле.

■ Помидорларны бакчага күчереп утыртып, бераз ныгуга ук, беренче яфрагы астыннан үсемлек сабагын бакыр чыбык белән үтәли тишәргә кирәк. Бакыр чыбыкны тартып алмыйбыз, сабакта килеш калдырабыз.

■ Помидор куаклары фитофтора белән зарарланса да, җыеп алынган уңышны коткарып калырга мөмкин әле. 1 литр кефир яки оеган сөтне ике литр су белән сыеклап, помидорларны берәр сәгатькә шушында батырырга кирәк. Аннары алып юарга һәм киптерергә. Берничә тапкыр кабатларга. Фитофтора гөмбәсе эчкә үк үтмәгән булса, нәтиҗәсе бик яхшы.

Лилия ГӘРӘЕВА әзерләде.

Рөхсәт ителә

Яшелчәләр яхшы үссен, мул уңыш бирсен өчен, чәчү әйләнешен саклау мөһим. Кайсы яшелчәләрдән соң ниндиләрен утыртырга ярый?

■ Борчак, фасоль – бәрәңге, кәбестә, помидор, кишер, чөгендер, суган, кыяр, кабак;
■ кәбестә – бәрәңге, помидор, кишер, чөгендер, кыяр, аш тәмләткеч үләннәр;
■ кабак, ташкабак, патиссон – бәрәңге, кишер, чөгендер, кәбестә, суган, помидор;
■ бәрәңге – кәбестә, борчак, кишер, чөгендер, кыяр, кабак;
■ суган – кәбестә, кыяр, бәрәңге, помидор, борчак, аш тәмләткеч үләннәр;
■ кишер, чөгендер, петрушка, сельдерей – кәбестә, бәрәңге, кыяр, помидор, суган;
■ редис, шалкан, гәрәнкә (брюква) – кыяр, помидор, борыч, бәрәңге, суган;
■ кыяр – аш тәмләткеч үләннәр, помидор, борыч, баклажан, бәрәңге, суган, борчак, шпинат, кәбестә, кишер, чөгендер;
■ помидор, борыч, баклажан, бәрәңге – борчак, кишер, редис, кәбестә, сарымсак, суган;
■ аш тәмләткеч үләннәр – кыяр, бәрәңге, кәбестә, кишер, сельдерей, редис;
■ сарымсак – бәрәңге, кишер, чөгендер, кыяр, помидор, борыч, кәбестә, борчак.


Кучкар. Җәйнең беренче ае – тормышыгыздагы иң гармонияле, иң тыныч айларның берсе. Көнелдәге тынычлык, тормышның калган өлкәләренә дә үтеп кереп, хыялларны тормышка ашыра башлауда беренче адым булачак.


Үгезбозау. Уңышлы ай. Бар да үз көенә, ничек планлаштырылган булса, шулай барыр. Айның беренче яртысында үзегезгә зур файда бирәчәк нindидер гамәл кылырга мөмкинсез. Тиң ярыгызны очрату форсаты да зур.


Игезәкләр. Көчегезнең артуын тоярсыз. Тормышыгыз кызыклы һәм мавыктыргыч булыр. Уңыш үкчәгезгә бастырып килә. Керем алырсыз, аны тагын да арттыру җае чыгар.


Кысла. Эшегез рухи дә, матди дә канәгатьлек китерер. Айның беренче көненнән үк нindидер илаһи көчнең ниятләрегезне чынга ашырырга ярдәмен тоярсыз. Сизгерлегегез искиткеч, әллә нинди шөбһәле эшләр дә сезнең файдага булачак.


Арыслан. Тормышыгызның вакыйгаларга, яңалыкларга бай чорына керәсез. Күп очракта төптән уйлап эш итү һәм салкын канлылык таләп ителәчәк. Нindидер кызыклы һәм файдалы тәкъдим булыр.


Сөмбелә. Күңелегезгә хуш килердәй вак-төяк мәшәкатьләр көтелә. Вакыйгаларны ашыктырмасагыз, максатыгызга ирешү әллә ни авырлык тудырмас. Күңел сизгерлегегез һәр эштә ярдәм итәр.


Бизмән. Уңышка ирешим дисәгез, планнарыгызны беркемгә дә белдерми торыгыз. Ай башында иң яшерен хыялларыгызны тормышка ашыру өчен яхшы форсат чыгарга тора. Финанс ягыннан тотрыклылык көтелә.


Чаян. Егәрегез ташып тора. Сездәге уңай энергия тирә-юньдәгеләргә дә йогачак. Әмма бу айга җитди эшләрне планлаштырмый торыгыз, планеталарның тәэсире бигүк уңай түгел.


Укчы. Тормышыгыздагы иң уңышлы ай булмаса да, язмыш сезне кыерсытмас. Кеше сүзенә колак салмый, үз юлыгызда булсагыз, эшегезнең яхшы нәтиҗәсен күрерсез. Ә иң куанычлысы: ниһаять, сезгә дә әйбәт ял тияр.


Кәҗәмөгез. Тормышның моңарчы күрмәгән яки дөрес бәяләмәгән якларын да ачарсыз. Сизгерлегегез бик көчле. Корган планнарыгызга язмыш бераз үзгәрешләр кертергә мөмкин. Ничек кенә булса да, уңыш сезнең якта булыр.


Сукояр. Нәрсәгә генә алынсагыз да, яхшы нәтиҗәгә ирешерсез. Бу үзегезгә булган ышанычны ныгытыр, яңа эш башларга этәргеч бирер. Өстәвенә, киләчәктә ярдәм итәрдәй кеше очрар. Ул элеккеге дустыгыз да булырга мөмкин.


Балык. Якыннарыгыз сезне танымас, моңарчы тыныч кына яшәгән Балыклар кызыклы идеяләр, яңа фикерләр белән шаккаттырачак. Бу айда башлаган эшләр уңышлы төгәлләнә. Шәхси өлкәдә, эштә, сәламәтлек буенча бар да яхшы.

Май да кабынган йолдызлар

Татарстан



Флёра Сафиуллина (24.05.1938–6.12.2011) – **галимә, татар теле белгече, филология фәннәре докторы, профессор. Татарстанның атказанган укытучысы һәм фән эшлеклесе.**

Тукай районы Теләнче-Тамак авылында туа. Казан дәүләт университетын тәмамлый. 1961–1992 елларда университетның татар теле кафедрасында – башта ассистент, аннары доцент, 1992–2011 елларда татар телен укыту кафедрасы мөдире булып эшли. 2000 елда «Татар әдәби теленең синтаксик төзелеше үсеше (XX гасыр)» темасына докторлык диссертациясе яклый. Флёра Садрый кызы бик күп укытучыларның, язучы, мөхәррир, журналист, тәрҗемәче, галимнәрнең остазы. Синтаксис, тел белеме, чагыштырма грамматика, тел тарихы буенча студентларга лекцияләр укыган галим. 400 дән артык фәнни хезмәтләр, монография, дәреслек, 10 сүзлек авторы.

Россия



Елена Майорова (30.05.1958–23.08.1997) – **Россиянең атказанган артисты.**

Көньяк Сахалинда туа. Кечкенәдән театр студиясендә шөгыльләнә, унынчыны тәмамлап, башкалага – театр институтларын яуларга юл тота. Әмма берсендә дә конкурстан узмый. Мәскәүдә калыр өчен бер ел төзелеш училищесында укый. ГИТИСка 1976 елда барыбер керә ул – Олег Табаков курсында укый. 1983 елдан МХАТта эшли. Киноэкраннарга беренче тапкыр «Вам и не снилось...» фильмында чыга. Ә танылу «34-й скорый» фильмы аша килә аңа. «Макаров» һәм «Затерянный в Сибири» фильмнарында уйнаган рольләре бик уңышлы санала. Кыска гына гомере эчендә кырыклап фильмда уйнарга өлгерә. Гомере фаҗигале өзелә – өстенә керосин түгелеп, ут каба. Үз-үзенә ут төрткән диган фараз да бар.

Чит илләр



Кайли Миноуг (28.05.1968) – **җырчы һәм актриса.**

Австралиянең Мельбурн шәһәрендә туып-үсә. Үзе дә биюче булган әниләре балаларын кечкенәдән бию һәм музыка түгәрәкләренә йөртә. Кайли экраннарга беренче тапкыр 9 яшендә чыга. 1980 нче еллар уртасында ук инде «Соседи» сериалында уйнап, популярлык казана. Җырчы буларак танылу аңа 1987 елда килә. Тагын бер елдан тәүге альбомы дөнья күрә. Дөнья буйлап 80 миллион артык җыр язмасы сатыла. 2008 елда аңа Принц Чарльз Британия империясе орденын тапшыра. Шул ук елны Франциянең Сәнгать һәм әдәбият орденына лаек була.

2005 елдан бирле яман шеш авыруы белән көрәшә.

Фото: www.mega-stars.ru /www.randrs.ru/

PRESSA.RU





РӘССАМ-ХӘЗИНӘ

Дөньяның иң атаклы сәясәтчеләренең берсе Сильвио Берлускони: «Һәркем үз кесәсендә Кояш йөртергә, башкаларга аны бүләк итәргә тиеш», – ди. Һәр көн кояш нурларын өләшүчеләр бездә дә бар. Янәшәбездә шундыйларның берсе – рәссам Әнвәр Сәйфетдинов. Ул якты төсләрдән торган картиналары белән күп еллар инде сокландыра. Портретларындагы образларда эчке матурлык бар.


Җанындагы тирән кичерешләрен шигъри юллар белән теркәве дә башка рәссамнардан аерып тора. Алар – бик югары дәрәҗәдә! «Шигырьләрне мин билгесез бер дустыма дип яздым... Һәрвакыт кешеләр арасында булачагымны алдан белдем, бу хакта хыялландым, шушы максатка таба бардым. Язмый башлавымның сәбәбе – бар энергетикамны һәм вакытымны тулысы белән үз эченә алучы бу ике юнәлешнең бары берсен генә сайларга кирәк иде. Мин сынлы сәнгатьне сайладым», – ди Әнвәр. Киндерләрендә, портретлардан кала, табигать күренешләре, натюрмортлар, могҗизалы әкият иле... Әнисе портреты – шәхси күргәзмәләренең иң түрендә. «Ана – ул үз баласы өчен һәрчак мәдәният! – ди ул. – Халкың өчен рухи кыйммәтләр калдырырга теләсәң, бу бары тик әниләрнең игелекләре нигезендә генә мөмкин. Минем әнием – чишмә башым, беренче үрнәгем, дустым, игелекле эшләремнең булышчысы». Әнвәрнең әнисе Роза Гомәр кызы да улы белән чиксез горурлана. «Кечкенә чакта рәсемнәр ясарга сәләтем бар иде, әмма бу һөнәрне сайлап алырга мөмкинлегем булмады. Бар хыял-өметләремне улыма багладым. Күп укыды, тырышып иҗат итә...» Әнвәрнең булганлыгын язган картиналары, агачтан уйган сыннары, үзенчәлекле фотолары раслый. «Аның «Борынгы Казан» циклы буенча узган гасырларга сәфәр кылабыз», – ди иҗатын ошатучылар. Аларның бер ише әле бары тик болытлардан гына торган этюдларына кадәр мөкиббән. Болытларны ничек сурәтләвенә карап, рәссамның язу осталыгын да сынап карарга мөмкин, дип дәлилли ул үзе. «Чөнки алар һәрвакыт хәрәкәттә, үзгәрештә... Табигать аша без Җиһанны тагын да ныграк яратабыз. Җирдә кешеләр нинди җан халәте белән яшәсә, күктәге болытлар да шундый була. Күк йөзенең чиста көзгесе ялтырап торсын өчен, Җир-анабызны кадерләп сакларга тиешбез», – ди. Ул – ачык һәм киң күңелле шәхес. Кирәк булса, башкаларга Леонардо да Винчиның «алтын кисеме»н дә аңлатып бирергә, иҗади әсәр язарга өйрәтергә дә алына ала. Глобаль мәсьәләләр, сынлы сәнгать темаларына әңгәмәләр корырга ярата.


Әнисе Роза Гомәр кызы әйтүенчә, Җирдә игелекле бала туачагын аңа Күкләр алдан ук белгерткән. «Кызыбыз Наилә бераз үскәч, икенче балабызны көтеп йөрим. Бервакыт аның турында көне буе уйландым һәм шул төндә төш күрдем: сандык өстендә утырам. Шулчак тавыш ишетелде: «Син сандык өстендә... хәзинә белән утырасың».

Әнвәр Сәйфетдиновның югары профессионализмы аны рәссам-хәзинә дип атарга мөмкинлек бирә. Һәм ул үзе дә күпсанлы шәхси күргәзмәләре белән моны һәрдаим раслап килә. «Минем өчен киндер каршындагы һәркем матур!» – дигән сүзләре шигарь кебек яңгырый. Ул сурәтләгән хатын-кыз җанлана, сулыш ала кебек тоелачак әле безгә. Әмма иң мөһиме – рәссамның нияте: «Җирдә рәссам булу – ул зур җаваплылык. Иҗатымның бары тик Яктылыкка хезмәт итүен телим!» – ди Әнвәр Камил улы.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА







ӘНВӘР СӘЙФЕТДИНОВ



ЛИЦЕНЗИЯ ЛО-16-01-006616 ОТ 19 ФЕВРАЛЯ 2018
ЛИЦЕНЗИЯ ЛО-16-01-006617 ОТ 19 ФЕВРАЛЯ 2018



ОСТЕОПАТИЯ
ДЕТСКАЯ НЕВРОЛОГИЯ
НЕВРОЛОГИЯ



РЕКЛАМА

тел. +7 (962) 559-02-56

Адреса клиник:
ул. Фатыха Амирхана, 18/41. ул. Дубравная, 1/104

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА